ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№06 (377)
ИЮНЬ 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ВАТАНГА МӘХӘББӘТ БӘЙРӘМЕ

№06 (377)
ИЮНЬ 2023

16+

Редакция:
420066, Россия, ТР,
Казан, Декабристлар ур.,
2 тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН

БАРЫ ТИК ТАТАРСТАНДА...

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» Халыкара икътисадый форумы дөньяга тагын бер мәртәбә Татарстанда нинди гаҗәеп әйберләр барлыгын һәм булачагын күрсәтте. Әйе, бары тик Татарстанда гына булганнарны!

Биредә ислам дөньясы вәкилләре җыела, ил өчен мөһим бурычлар хәл ителә – мәсәлән, егерме беренче гасырның агымдагы дистә елының иң зур геосәяси проекты – «Төньяк–Көньяк» транспорт коридорын ачу, аны үстерү турында фикер алышу. Бу, мөгаен, Казан форумының төп темасы булгандыр.

Татарстанда тагын Ту-214 пассажир лайнерларын җыялар. Ул илдә беренчеләрдән булып Көнбатыш «Боинг» һәм «Эйрбас»ларын алыштырачак. Ту-124 очкычын җыяр өчен импортны алыштыру таләп ителми, чөнки кирәкле бар нәрсә – деталь, узел һәм двигательләрдән алып авионикага кадәр – Россиядә җитештерелә.

Татарстанда тагын Россиянең дүрт легендар елгасы бергә кушыла. Нократ та, Агыйдел дә Чулман елгасына коя. Чулман белән Идел исә бергә кушыла. Дүрт елга кушылган урынны бер көндә күреп кайту мөмкинлеге бары тик Татарстанда гына бар.

Татарстанда тагын республикада яшәүче халыклар телләрендә үз аккаунтларын алып бара алырлык көчле блогерлар үстерәләр. Моның өчен ТҮЛӘҮСЕЗ махсус мәктәп эшли!

Татарстанда тагын Ватанга мәхәббәт һәм тугрылык бәйрәме – Россия көнен киң колач белән билгеләп үтәләр. Республикада яшәүче 173 милләт халкын уртак язмыш берләштерә. Мариларның Семык бәйрәме, русларның Каравоны, татарларның Сабан туе, удмуртларның Гырон быдтоны, чувашларның Уявы һәм мордваларның Валда шинясе төрле халыкларга дус-тату яшәргә ярдәм итә.

Сезнең редакция.

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Юрий Блинов, Илдус Заһидуллин, Ксения Сёмина, Әхмәт Шакиров
Фотографлар: Александр Ефремов, Рамил Гали, Анна Арахамия
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова, Игорь Глушков
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов. Фото: Татарстан Рәисенең рәсми сайты

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Россия, ТР, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С–1449
Басарга кул куелды: 14.06.2023
Басмадан чыкты: 20.06.2023

Коммерция директоры:
Рашит Хәйретдинов, тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Гөлназ Яруллина, тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЫЛЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Россия, ТР, Казан, Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **1026 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 102 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

барысы тик Татарстанда

ФӘЙЗУЛЛА КОЧАГЫНДАГЫ АСИЯ, МӘРЬЯМ ҺӘМ МАРУСЯ

Бервакыт Фәйзулла Туишев концертында булганнан соң, атаклы дрессировщик Владимир Дуров аңа: «Төлкеләрем һәм мәчеләремнең сезнең кулларыгыздагы гармуннар кебек тыңлаучан булуын телим» дип язган. Беренче татар профессиональ гармунчысының чыгышлары чыннан да күңелле цирк тамашаларына охшаган була. Концерт барышында Туишев гармуннары белән тылсымчыдай идарә итә, бер гармунны икенчесенә, икенчесен өченчесенә алыштыра. Шул ук вакытта көйләр бер мизгелгә дә өзелеп тормый, маэстро кулындагы гармунның зурлыгына карап, гаҗәеп төсмерләргә бай көйләр агыла. Фәйзулла Туишев кулында уенчыкка охшаган, шырпы тартмасыдай кечкенә гармун да, зур концерт гармуны да гүя җанлана. Гармунчы революциягә кадәр үк гастрольләр белән бөтен илне әйләнеп чыга, дөньякүләм танылуга ирешә, аны Япония, Кытай, Корея, Көньяк Америка тамашачылары алкышлый. Фәйзулла гармуннарын җыеп бара. Аларның һәркайсына хатын-кыз исеме бирә. Коллекциядә Асия дә, Мәрьям дә, Маруся да бар. Туишевның 17 гармуны Татарстанның Милли музеенда саклана.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. «Төньяк–Көньяк»: якты киләчәккә юл
Ни өчен яңа транспорт коридоры Сүәеш каналыннан шәбрәк булачак

6. KazanForum: вакыйгалар һәм саннар
Татарстанда ни өчен бөтен дөнья җыелды

8. Күкне яулау
Ту 214 – барысы да үзебездә эшләнгән

12. Акыллы шәһәр өчен һава транспорты
Иннополиска конвертоплан нигә кирәк

28. Нократ белән Агыйделдән Чулман белән Иделгә кадәр
Россиянең дүрт елгасы кайда кушыла

32. Таныш булыгыз: фикер лидерлары
Татарстанда шәп блогерларны ничек үстерәләр

игелекле эшләр

36. 300 ел элек кебек
Каравон ничек туа һәм яңара

40. Семык кайда, җәй шунда
Мариларның теләкләре нигә чыңга аша

44. Урман хуҗасы аюга хөрмәт,
яисә Балтай бабай ничек халык бәйрәмен «уйлап тапкан»

45. Бәхет өчен күп кирәкми
Кино сәнгате мәктәбе җитәкчесе илһамны кайдан ала

46. Безнең кунакханәдә
«Сәламәтлек – физик, психик яктан сау булу ул»

мәңгелек кыйммәтләр

54. Хәбәрсез югалганнарны табу
Хәтирә Мәрданшина Бөек Ватан сугышы солдатларын ничек «кайтара»

62. Көчле рухлылар
Наталья Авдеева үзенчәлекле балаларга ни рәвешле булыша

68. Китап киштәсе
«Затлы чыбыркы хуҗасы»

72. Тарихи сәхифә
Беренче татар революционеры Хөсәен Ямашев

80. Татарстан авыллары
Кармыш: күмәк көч тау күчерә

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: archive.gov.tatarstan.ru

Акыллы гамәлләр

31.05

Виктор Золотов, РФ Милли гвардиясе гаскәрләре Федераль хезмәте директоры – Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләре баш командующие, армия генералы:

– Башка төбәкләрдәге кебек үк, Татарстан халкы да Ватанны саклау эшендә бердәмлек күрсәтте. Нәкъ менә Татарстанда беренче ирекле батальоннар оештырылды. Биредә республика хакимияте беренчеләрдән булып азат ителгән территорияләрдә тыныч тормышны торгызуга юнәлдерелгән гуманитар проект һәм инициативаларга үзәкләштерелгән ярдәм оештырды.

01.06

Евгений Дитрих, «Дәүләт транспорт лизинг компаниясе» АҖ генераль директоры, – Казанда, «Татарстан Республикасы флоты» АҖ суднолар компаниясенә яңа теплоходлар тапшыру тантанасында:

– Бүгенге көндә илебездә суднолар төзү эше технологияләрнең югары дәрәҗәсен көтүдә торган яңа проектларга мохтаҗ. Бу яктан Татарстан да искәрмә түгел. Нәкъ менә монда, Яшел Үзән заводында, сыекландырылган табигый газ белән йөрүче беренче пассажир пароходы төзелә. Татарстан белән Дәүләт транспорт лизинг компаниясе арасындагы хезмәттәшлекнең тарихы бик озын. Бу хезмәттәшлек быел Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган һәм төрле максатлар өчен 260 тан артык граждан судносы төзүне көтүдә торган суднолар төзелешен үстерү программасын үтәргә мөмкинлек бирер, дип ышанабыз.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр



25.05

Гөлшат Нугайбәкова, татар милли костюмы коллекционеры һәм реконструкторы, – «Яшәү сәнгате» мәдәни-агарту үзәгендә очрашуда:

– Мин балаларыбызга Кытай эрзацлары гына калуын теләмим. Алай булырга тиеш түгел. Безнең һәрберебездә уникаль әйберләр булырга, алар балаларыбызга, оныкларыбызга күчәргә тиеш. Һәркемнең зур гардеробында борынгы әйберләр саклана торган киштә, стенасында әби-бабаларының фотолары эленгән урын булсын. Алар безгә элек тормышның нинди булганын истән чыгармаска булышыр.

Фото: tatar-inform, kremlin.ru, kpfu.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәләр/

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстанда ничек бөтен дөнья җыелды

Татарстанда ничек иң яхшы самолет төзелә

Татарстанда ничек инновацияле территорияләр ачыла

Татарстанда ничек Россиянең өч елгасы кушыла

Татарстанда ничек шәп блогерларны тәрбиялиләр

«ТӨНЬЯК–КӨНЬЯК»: САНКЦИЯЛӘРДӘН АЗАТ ЮЛ

Әскәр Сабиров

Безнең гасырның агымдагы дистә елының иң зур геосәяси проекты. «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum 2023» Халыкара икътисадый форумында катнашучылар «Төньяк–Көньяк» транспорт коридорын шулай дип атады. Әлеге юлны алга таба үстерү турында фикер алышулар, мөгаен, Казан форумының төп темасы булгандыр.

Россия Федерациясе вице-премьеры Марат Хөснуллин, форум нәтиҗәләрен шәрехләп, болай диде: «Төньяк–Көньяк» транспорт коридорын үстерүгә Фарсы култыгы илләре (Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Бәхрәйн, Әмән, Күвәйт), Азәрбайҗан һәм Үзәк Азиянең барлык дәүләтләре – Төрекмәнстан, Таҗикстан, Үзбәкстан, Казахстан, Кыргызстан җитди кызыксыну күрсәтте... Гаҗәп түгел, чөнки әлеге маршрут Россиянең Европа өлешеннән Иран аша Фарсы култыгы илләренә, Һиндстанга, Пакыстанга, Кытайга, Көньяк-Көнчыгыш Азиягә һәм кире юнәлештә йөкләр китерү мөмкинлеге генә түгел ул. Сүәеш каналы белән чагыштырганда, яңа транспорт коридоры буенча йөк китерүләрне ике-өч мәртәбәгә тизләтергә мөмкин, чөнки «Төньяк-Көньяк» юлы ике тапкырга кыскарак. Ә тизрәк дигән еш кына арзанракны аңлата, җитмәсә, бу очракта санкцияләр басымы да юк».

МАРШРУТЛАР БЕРНИЧӘ, МАКСАТ – БЕР

«Төньяк–Көньяк» халыкара транспорт коридоры кичә генә пәйда булмаган. Россия, Иран һәм Һиндстан кебек илләр әлеге юл буенча хәрәкәтне ачу турында рәсми беркетмәне 2002 елда ук имзалаган. Юл башта Каспий диңгезе аша гына үтә. Ләкин контейнерларны поездлардан паромнарга һәм киргә төяү эшне катлауландыра, шуның аркасында даими элементләр әкренләп РФ һәм Иран арасындагы участок белән генә чикләнә башлый.

Бүген исә «Төньяк–Көньяк» коридоры бердәй әһәмиятле берничә маршруттан гыйбарәт, һәм анда катнашырга теләүче илләр саны да күбәйде – алар хәзер 13. Транскаспий маршруты Россиянең Әстерхан һәм Оля портлары һәм Иран портлары аша үтә. Икенчесе, Көнчыгыш маршруты, Казахстан, Үзбәкстан һәм Төрекмәнстан аша уза. Өченчесе, шулай ук Көнчыгыш юлы, Үзбәкстанга кермичә, Казахстан һәм Төрекмәнстан аша салынган. Тагын берсе – Көнбатыш юлы – коры җир буенча Азәрбайҗанга килә.

Маршрутларның төрле вариантлары аерым илләрнең мәнфәгатьләрен исәпкә ала һәм, дәүләтләр арасында фикер каршылыклары килеп чыга калганда да, йөкләрне өзлексез китерүне гарантияли. Безнең өчен Көнбатыш варианты, ягъни Азәрбайҗан аша Иранга баручысы җитди кызыксыну уята. Бигрәк тә Казан форумы ачылу алдыннан булган вакыйгадан соң. 17 майда Россия һәм Иран хөкүмәтләре үз президентлары катнашында (видеоэлемтә буенча) Решт (Иран) – Астара (Азәрбайҗан) тимер юлының 162 км лы участогын төзү турында килешүгә кул куйдылар. Глобаль инфраструктура проектының бер өлеше булган юл 2025 елга төзелеп бетәргә тиеш. Әлеге участок юлның җитешмәгән өлеше, ул салынуга пазл төзелеп бетәчәк. Йөкләрне тимер юлдан башка китерү мөмкинлеге барлыкка киләчәк. Мәсәлән, Санкт-Петербургтан, Мәскәүдән яисә Казаннан Иранның Фарсы култыгындагы Бендер-Аббас портына кадәр.

КҮППОЛЯРЛЫ ДӨНЬЯНЫҢ БЕР ӨЛЕШЕ

Эшлекле басмаларның берсе, килешү Татарстан форумында имзаланды дип, нәтиҗә ясарга ашыкты, гәрчә болай әйтү дөрес үк булмаса да. Сөйләшүләр бер генә ай бармады. Проект, аерым алганда, узган елгы очрашу барышында ике ил президенты тарафыннан

Марат Хөснуллин, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары:
– Россия өчен транспорт коридорларын үстерү илебез Президенты Владимир Путин куйган өстенлекле бурычларның берсе булып тора. Каспий төбәге, Көньяк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия, Фарсы култыгы илләре юнәлешендәге маршрутлар Россия Федерациясе өчен һәрвакыт өстенлекле санала.

Фото: tatar-inform.ru

да тикшерелде. Икенче яктан, «Төньяк–Көньяк» транспорт коридорын үстерү мәсьәләсе нәкъ менә Казанда узган форумнарда күп тапкырлар игътибар үзәгендә булды, бу хакта, сүз уңаеннан, пленар утырыш барышында Татарстан Рәисе дә искә алып үтте.

«Казан форумы кысаларында «Төньяк–Көньяк» коридорын үстерү мәсьәләләре буенча фикер алышуларны оештыру күркәм традициягә әверелде, һәм бүген без аның нәтиҗәләрен күрәбез», – дип басым ясады Рөстәм Миңнеханов. Чынлыкта әлеге мәйданчыкларның төп кыйммәте дә шунда: иртәме-соңмы мондый аралашу, фикер алышу, сөйләшүләр конкрет килешүләр һәм контрактлар рәвешендә файдалы нәтиҗәләр бирүче критик массаны барлыкка китерә.

Бүгенге конкрет шартларда «Төньяк–Көньяк» проектын тиз арада тормышка ашыру никадәр мөһим соң? Бу сорауга җавапны форумдагы чыгышында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенең беренче урынбасары Андрей Белоусов бирде, дип уйлыйм.

«Төньяк–Көньяк» коридоры – XXI гасырның агымдагы дистә еллыгының иң зур геосәяси һәм геоикътисадый инфраструктура проекты, аны санкцияләр белән бәйләү бөтенләй дөрес түгел, – дип билгеләп үтте ул. – Проект күпполярлы дөньяны формалашу процессының һәм көч үзәкләрен күчерү буенча фундаменталь тенденцияләрнең бер өлеше булып тора».

> **Тани бин Әхмәт Әл-Зәйди, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең тышкы сәүдә дәүләт министры:**
> –Яңа «Төньяк–Көньяк» коридоры – иң перспективалы проектларның берсе. Бу безнең өчен төп проект. Ул безнең базарны үстерергә һәм хәзерге вакытта күзәтелгән глобальләшүгә протест кысаларында башка илләр белән хезмәттәшлек итәргә мөмкинлек бирәчәк. Без бу проектны гамәлгә кертү потенциалын күрәбез. Ул Берләшкән Гарәп Әмирлекләре компаниясенең барлык булган маршрутларын берләштерергә мөмкинлек бирәчәк һәм бу проектка кушылырга әзер.

МАКСАТ – ЕЛЫНА 100 МЛН ТОННА ЙӨК

Әгәр глобаль гомумиләштерүләрдән проектны тулысынча гамәлгә ашырырга вәгъдә итүче конкрет өстенлекләргә күчсәк, Россия транспорт академиясе президенты Александр Мишарин сүзләренчә, Европа, Россия һәм Урта Азия илләреннән Фарсы култыгы портларына сузылган гарантияләнгән транспорт коридоры киләчәктә елына 100 млн тоннадан артык йөк китерергә мөмкинлек бирәчәк.

Әлбәттә, моның өчен әлегә булмаган Решт – Астара тимер юл участогын төзү белән бергә, бөтен логистика инфраструктурасын, илләр арасында үткәрү пунктларын камилләштерергә дә кирәк булачак, партнерлар арасында яңа дәрәҗәдәге хезмәттәшлек таләп ителәчәк. Озак уйларга вакыт юк: Марат Хөснуллин сүзләренә караганда, «Төньяк–Көньяк» юнәлешендә йөк әйләнеше 2025 елга ике мәртәбәгә артып, 30 млн тоннага, ә 2030 елга 35 млн тоннага җитәргә тиеш.

Партнерлар арасындагы хезмәттәшлекнең яңа дәрәҗәсе турында сөйләгәндә, форумда катнашучылар, аерым алганда, Россиядән Азәрбайҗанга, аннан Россиягә авыл хуҗалыгы продукциясен ташу вакытында тупланган тәҗрибәне активрак кулланырга тәкъдим итте. Бу – «Агроэкспресс» юлы, ягъни «яшел коридор» аша контейнер ташуларның тизләтелгән сервисы. Бу ысулның уңышына китергән мәҗбүри компонентлар арасында тимер юллар гына түгел, ә заманча логистика үзәкләре дә бар. Исегезгә төшерәбез: аларның берсен ТР Яшел Үзән районы территориясендә ачу турындагы Меморандумга узган елгы Казан форумында кул куелган иде.

Мондый сервисларга ихтыяҗ Евразия икътисадый берлеге белән иркле сәүдәгә яңа илләр кушылуга бәйле рәвештә артачак, дип фаразлана. Бүген бездә Иран белән иркле сәүдә турында килешү бар. Шундый ук сөйләшүләр, дип билгеләп үтте форумда Рөстәм Миңнеханов, Евразия икътисадый берлеге һәм Һиндстан арасында алып барыла, шулай ук Көньяк Азия һәм Фарсы култыгының башка илләрендә дә кызыксыну бар.

Татарстан Рәисе тагын бер ресурсны искә алды. Аның сүзләренчә, «Төньяк–Көньяк» коридорын киң транспорт маршрутлары белән тоташтыруның зур потенциалы бар». Шуңа бәйле рәвештә төзелә торган М-12 Мәскәү–Казан магистраленең дә, аны алга таба үстерүнең дә роле арта. Шулай итеп, илләр һәм төбәкләрнең ике як өчен дә файдалы үзара эшчәнлегенә яңа импульс бирә алган макрорегиональ транспорт-логистика системасы формалаша.

Бүген транспорт коридорының төп маршрутларында зур төзелеш җәелдерелгән. Әстерхан, Дербент һәм Хасавюртны урап узу юлы, яңа «Дербент» тимер юл үткәрү пункты төзелә, Әстерхан өлкәсендә һәм Дагыстан Республикасында Каспий бассейны портлары үсә. Шулай да юнәлеш үсешенә комачаулаучы каршылыклар шактый. Бу хәл ителмәгән икътисадый һәм техник проблемалар гына түгел, ә илләр арасында тотрыклы булмаган мөнәсәбәтләргә бәйле сәяси мәсьәләләр, шулай ук куркынычсызлыкны тәэмин итү сораулары һәм башка тоткарлык факторлары бар, дип ассызыклады Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан яңа проектны гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә, әлеге халыкара системага урнашырга әзер, дип белдерде ТР Рәисе.

«РОССИЯ — ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ: KAZANFORUM»

«Казан Экспо» ХКҮ
18–19 май

ФОРУМ КӨННӘРЕНДӘ ИМЗАЛАНДЫ:

130 килешү һәм меморандум.

ФОРУМ ПРОГРАММАСЫНДА

200 дән артык чара узды.

KAZANFORUM КАТНАШУЧЫЛАРЫ:

16 223 кеше

85 илдән

84 РФ төбәгеннән

пленар утырыш темасы:

«ЫШАНЫЧ ИКЪТИСАДЫ: РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ҺӘМ ИХО ИЛЛӘРЕ ПАРТНЕРЛЫГЫ»

АЗӘРБАЙҖАН, ИРАН, МАЛАЙЗИЯ, ТАҖИКСТАН, ТӨРКИЯ ҺӘМ ҮЗБӘКСТАН –

иң күпсанлы делегация әлеге илләрдән килде.

ФОРУМДА КАТНАШТЫЛАР:

45 дипломатия миссиясе

37 гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илче.

МАРАТ ХӨСНУЛЛИН, РФ ХӨКҮМӘТЕ РӘИСЕ УРЫНБАСАРЫ:
«Форумнан алынган тәэсирләр бик уңай, чара бик вәкиллекле булды. Мин аның составын карадым. Якын Көнчыгышның барлык илләреннән диярлек дәрәҗәле делегацияләр килде. KazanForum Россия һәм ислам дөньясы илләренең үзара хезмәттәшлегенә этәргеч бирер, дип ышанам».

Фото: pais.tatarstan.ru, tatar-inform.ru

XIV ХАЛЫКАРА ИКЪТИСАДЫЙ ФОРУМЫ: САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ, ТАТАРСТАН РӘИСЕ:
«KazanForum – илебезнең ислам дөньясына якынаю урыны. Бүген без бер-беребезгә таба тагын бер адым ясадык».

6 ике яклы конференция узды:

«РОССИЯ–ТӨРКИЯ», «РОССИЯ–МИСЫР», «РОССИЯ–АЗӘРБАЙҖАН», «РОССИЯ–ҮЗБӘКСТАН», «РОССИЯ–МАЛАЙЗИЯ», «РОССИЯ–ИРАН»

KazanForum мәйданчыгында узган **ИСЛАМ ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ ОЕШМАСЫ ИЛЛӘРЕНЕҢ ЯШЬ ДИПЛОМАТЛАРЫ ФОРУМЫ**

23 ДӘҮЛӘТ.ВӘКИЛЕН җыйды.

Төп тема дөньяның күпполярлы чорында халыкара мөнәсәбәтләрне тикшерү булды

RUSSIA HALAL EXPO -

форум кысаларында узган әлеге күргәзмәдә

11 ил, шул исәптән **ИРАН, ТӨРКИЯ, БЕРЛӘШКӘН ГАРӘП ӘМИРЛЕКЛӘРЕ** катнашты

RUSSIA HALAL MARKET

халыкара ярминкәсендә

400 дән артык хәләл продукция җитештерүче катнашты

ӘХМӘТ СЕНГЕНДА, ИХО ГЕНЕРАЛЬ СЕКРЕТАРЕ УРЫНБАСАРЫ:
«Мондый масштабтагы форумны үткәрү – Россия һәм ИХО илләре арасында ныклы элемтәләрнең дәлиле. Бу инвестицияләрнең перспективасы турында фикер алышу, хезмәттәшлек итү мөмкинлеге. 2021 елда Россия һәм ИХО илләре арасында сәүдә әйләнеше 113,3 млрд доллар тәшкил итте».

КАЗАН КИРМӘНЕ БАЛКЫШЫ

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» Халыкара икътисадый форумында катнашучылар һәм казанлылар «Кремль балкышы» белән хозурланды. Казан кирмәненең Преображенская һәм Тайницкая манаралары, Кабул итү урыннары диварлары борынгы тарихларын күрсәтте. Мультимедиа инсталляцияләре тамашачыны таң калдырды. Яктылык фестивале өч көн дәвам итте.

Фото: tatar-inform.ru



«ИЗГЕ БОЛГАР ҖЫЕНЫ – 2023»

21 майда KazanForum-2023 форумында катнашучылар Идел буе Болгарстанында ислам динен кабул итүнең 1101 еллыгына багышланган «Изге Болгар җыены»нда кунак булды. Тантанада 20 меңләп кеше катнашты.

Кунакларны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов сәламләде.

«Бүген бездә бәйрәм, тантана. Былтыр без ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгын билгеләп үттек. Быел инде юбилейга тагын бер ел өстәлде. Бу юлы яңа чаралар уздырабыз, Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) һәм аның сәхабәләренең ядкәрләрен алып килделәр, – диде Миңнеханов. – Мин хәтта бу изге ядкәрләрне тотып карау бәхетенә дә ирештем. Без ел саен яз көне биредә җыелабыз. Болгар – безнең асылыбыз ул. Болгар яшәгәндә, безнең динебез дә, телебез дә, гореф-гадәтләребез дә яшәячәк».

«Изге Болгар җыены» ел саен бөтен илебездән дистәләрчә мең кешене җәлеп итә һәм чит илләрдәге милләттәшләребезне: Россия Федерациясе субъектлары делегатларын; Россия Федерациясе, якын һәм ерак чит илләр мөселманнары диния нәзарәтләре вәкилләрен; илнең төрле почмаклары һәм мөселман дөньясы вәкилләрен үзендә җыя. Быел да алар Җәмигъ мәчете янындагы өйлә намазында катнашты.

Аннары исә кунакларга мәдәни-агарту программасы күрсәтелде. Болгар цивилизациясе музеенда «Татар язуы тарихы» дигән интерактив мәйданчык эшләде, анда кунаклар урта гасырлардагы татар язуы, каләме, каллиграфиясе үзенчәлекләре турында мәгълүмат алды. Осталык дәресендә үз исемнәрен гарәпчә язарга өйрәнделәр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.), аның гаилә әгъзалары һәм сәхабәләренең ядкәрләрен – дөньяның төрле ислам үзәкләрендә җыелган чын реликвияләрне үз күзләре белән күрделәр.

Фото: tatar-inform.ru



редкая кухня



Фото: Алсу Шакирова, en.wikipedia.org, anupskitchen.com, shelkoviyput.ru, azerbaijangid.ru

ХАЛЫК АШЛАРЫ ТАРИХНЫ АЧА

Татьяна Вафина

«Татарстан» редакция кухнясы «бик» сүзенә бай урын ул: бик тәмле, бик милли, бик кызыклы, бик үзенчәлекле! Май аенда Казанда узган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum-2023» Халыкара икътисадый форумы көннәрендә нәкъ шулай килеп чыкты да. Форумда катнашучы биш ил – Төркия, Азәрбайҗан, Үзбәкстан, Иран һәм Алжир вәкилләре Татарстанның төрле рестораннарында үз милли ризыкларын тәкъдим итте.

«Кулинария аша без дөнья халыкларының мәдәниятен һәм тарихын өйрәнәбез», – диде «Татинтер Ресторантс» генераль директоры Зөфәр Гаязов, «Татарстан»ны ислам илләренең милли ризыклары фестиваленә чакыргандa.

АЛЖИР:
ЛИНДА ТАБУШТАН ЧАХЧУХА ДФЕР

Линда Табуш – Алжирның иң дәрәҗәле аш-су остасы. 1975 елдан Франциядә үз ресторанында эшләгән. Алжирдагы баш ашчылар арасында уздырылган төрле конкурсларда күп тапкырлар җиңү яулаган. Бу юлы ул Алжирның традицион кайнар ризыгы – чахчуха дфер әзерли. Әлеге ашамлыкны көтүчеләр уйлап тапкан дип санала, эштән соң салкын төндә өйләренә кайткач, аларга тамак туярлык итеп ашап, җылынырга кирәк булган.

– Бүген бу ризык төрле тантана-бәйрәмнәрдә бигрәк тә популяр, – ди Линда, – шуңа күрә без аның белән Казанда «Гусь» ресторанының кунакларын сыйларга булдык. Ризыкның ике төре бар: чахчуха бискрия, чахчуха дфер. Без хуш ислерәк булган икенче вариант – чахчуха дферны әзерлибез. Ул ругаг дип аталган түгәрәк кабартманың вакланган кисәкләреннән һәм маркадан гыйбарәт. Марка дигәне томалап пешерелгән ит була. Чахчуха дфер өчен тагын помидор, ногыт (нут), суган һәм Алжир тәмләткечләре – әнеч, рас әл-ханут, галангал, лаванда һәм әче кызыл борыч та таләп ителә. Боларны мин үлчәп-нитеп тормыйм, чамалап салам: кунаклар никадәр күбрәк булса, ингредиентлары да шулкадәр күбрәк кирәк.

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- помидор;
- суган;
- ит (бүген тавык алабыз, сарык яки сыер ите дә ярый);
- ногыт (нут);
- сарымсак;
- Алжир тәмләткечләре

Чахчуха дфер пешкән арада, Алжир кухнясында безнең татар чәкчәгенә охшаган ризык барлыгын белдек.

– Фритюрда кыздырылган, аннары бал белән катырылган камыр шарчыклары ул, – дип аңлата Линда. – Бездә бу десертны «криуш» дип атыйлар.

АЗӘРБАЙҖАН:
ТАҺИР ӘМИРАСЛАНОВТАН «МӘХӘББӘТ КУХНЯСЫ»

«Татар утары» ресторанында азәрбайҗан кухнясын берьюлы ике танылган аш-су остасы тәкъдим итә. Болар – күренекле баш ашчылар гына түгел, ә азәрбайҗан тәм-томнарын китаплар һәм блогларда мәңгеләштерүче бөек кулинар язучылар да. Бөтендөнья ислам кулинариясе берләшмәсе президенты, язучы – «кулинар клептоман» Таһир Әмираслановның биредәге азәрбайҗан десертлары арасында тезелеп яткан аш-су китаплары авыздан су китерерлек тышлыклары белән кызыктырып тора.

Кунаклар арасында телевидение алып баручысы һәм видеоблогер, нигездә үзбәк һәм азәрбайҗан кухнясына багышланган аш-су китаплары авторы Сталик Ханкишиев та бар.

Төшке аш бик төрле һәм көй-моңлы булырга охшый. Сталик тар дип аталган милли уен коралының кылларын тарткалый... Менюда тулма да, мангал-салат та, яшел тәмләткечле, сырлы кутаблар да, довга ашы да, сарык итеннән люля-кебаб та, шуша-пылау да, шашлык та, шекербур да бар... Кыскасы, барысы да нәкъ азәрбайҗаннардагыча – мул ит, яшелчә, тәмләткечләр һәм матур музыка...

– Азәрбайҗан кухнясы ит, яшелчә һәм балык ризыкларының күплеге белән аерылып тора, – ди Таһир Әмирасланов. – Һәм ризык һәрвакыт төрле тәмләткечләр һәм яшел үләннәр белән баетыла. Берсеннән-берсе тәмлерәк азәрбайҗан ризыкларын әзерләү өчен рецептлар бик күп. Мәсәлән, үземнең чираттагы китабымны туплаганда, тулманың өч йөздән артык төрен таптым. Бүген безнең менюда әнә шул рецептларның берсе буенча әзерләнгән тулма!

Таһир Идрис оглы Әмирасланов татлы сый итеп безгә үзенең «Кухня любви» китабын тоттырды – гаилә корырга һәм балалар үстерергә теләгән гашыйклар һәм инде ярәшкән кешеләр өчен аш-су китабы ул. Аны укып чыгар өчен,

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- нәзакәтле сыйларга мәхәббәт (чөнки «нәзакәтле сый-ризык булмаган җирдә нәфис мәхәббәткә урын юк»);
- «тәмсез кәҗә итенә төрле хуш исле үсемлекләр белән кыргый болан ите тәмен кертә» белү (чөнки «исләр кешене җәлеп тә итә, күңелен дә кайтара ала»);
- ризыкны, табынны матур итеп бизәү һәм тәкъдим итү (чөнки «ризык ачлык тойгысын канәгатьләндереп кенә калмыйча, хатын-кыз кебек матур да булырга тиеш»);
- тәмне таный-аера белү (чөнки «үбешү – тәмләп сыйланганнан соң ләззәтләнү ул»);
- ашар алдыннан догалар уку (чөнки «дога кылганнан соң, барлык психик авырлыклар һәм авыр уй-фикерләр тарала»)

– Дегустациядән соң барыгыз да үзен гашыйк итеп тоячак, – дип вәгъдә итә «Кухня любви» авторы журналистларга.

Нишлисең, безнең журналист халкына нинди генә сынаулар узарга туры килми!

Кунаклар арасында видеоблогер һәм телевидение алып баручысы Сталик Ханкишиев та бар.



ҮЗБӘКСТАН:
АКБАР УМАРОВТАН ДУСЛЫК ПЫЛАВЫ

Чын үзбәк пылавыннан авыз итәр өчен, без Milli ресторанына юл тоттык. Андагы казан тирәсендә баш ашчы, Үзбәкстан аш-су осталары ассоциациясе, WICS хәләл комиссиясе рәисе Акбар Умаров җитәкчелегендәге команда инде мәш килә иде.

– Пылау – үзбәкләрнең төп ризыгы. 2016 елда ул ЮНЕСКОның матди булмаган мирасы исемлегенә кертелде, – дип мәгълүмат бирде безгә Акбар Умаров. – Һәм без таныштыру-таныту текстын әзерләгәндә, анда пылауны барлык милләтләрне, бөтен җәмгыятьне берләштерә торган ризык буларак тасвирладык. Бу ризыкны әзерләү күп кенә хәйрия чаралары белән бәйләнгән. Бала тугач, мөмкин кадәр күбрәк кешене бушлай ашату максатында, бик күп пылау пешерәләр. Яңа кеше туу турында һәркем белсен өчен!

Кеше өйләнә икән, туйда һичшиксез пылау булачак, анда да тагын бик күп кешене сыйлаячаклар. Бу гаиләдә бәхетлеләр ике кешегә артканлыгын бөтен халык белсен өчен. Аларга күп-күп игелек теләсеннәр өчен!

Кеше үлгәч тә, пылау пешерәләр – бу кешене яхшы сүз белән искә алсыннар өчен.

Берәрсе ашчылыкка укырга килсә, аны беренче эш итеп пылау пешерергә өйрәтәләр. Чөнки кеше әлеге һөнәр аша тормышта үз урынын таба, гаиләсен ашата, кәсебен киләчәк буыннарга тапшыра.

Нинди генә компания җыелса да, пылау ашыйлар. Берәр зур җыен-кичәгә әзерләнәләр икән, әүвәл барлык мәсьәләләрне хәл итә, эш-вазыйфаларны бүлешә торган киңәшмә җыела. Бу вакытта баш шәфрәк эшләсен өчен, табынга һичшиксез пылау чыгарыла.

Ягъни пылауны тик торганнан гына, сәбәпсез генә пешермиләр, ә нәрсәдер хөрмәтенә пешерәләр. Хәтта, әйтик, ике кеше талашса да, пылау әзерләнә – бер табында пылау ашап, бер-берсен гафу итсеннәр өчен. Пылау берләштерә, пылау дуслаштыра. Пылау рецептлары бик күп, әмма без бүген классик үзбәк пылавын пешерәчәкбез. Моның өчен,

БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- ит (сарык ите) – 1 кг;
- озынча дөге – 500 г;
- зира – 1 аш кашыгы;
- суган – 4 баш;
- кишер – 1 кг;
- сарымсак – 2 баш;
- үсемлек мае – 300 мл;
- киптерелгән кызыл борыч – 2 данә;
- киптерелгән барбарис – 1 аш кашыгы;
- кориандр орлыгы – 1 чәй кашыгы.

– Тәмлеме? – дип кызыксына Акбар әфәнде, безгә өсти-өсти салып. – Пылауны ашап туеп булмый, тагын бераз, тагын бераз кабып куясы килә.

...Әмма, «ЮНЕСКОның матди булмаган мирасы» пешерелгән казанның зурлыгын һәм үзебезнең мөмкинлекләребезне чамалап фикер йөрткәндә, без бүген кешелек тарихында пылау ашап туйган тәүге инсаннар булырбыз кебек.



Ачылдымы җырдан
«бәхет капкасы»?
Алдымда ни?
Гүя тылсым бакчасы...

Әкияти Гөл-лалә күрәм...
ут чәчәк! –
Хыялымны ул
таҗына төрәчәк!

Аh, Матурлык!
Нурдан яралган заты...
Ул – бәхеттер,
кемнең өлеше, хакы?

Үземә алсам, Матурлык,
тик микъдарың,
Мәңгелеккә
илче-сурәт итәрмен!

...Шул Гөл-лалә тик хыял, ди, –
Җирдә юк!
...Касәсеннән эчмәгән
шагыйрь дә юк!

ИРАН:
ХУМОЮН ХОССЕЙННАН ГОРМЕ САБЗИ

Ираннан күренекле аш-су остасы Хумоюн Хоссейн «Чирәм» ресторанында әллә нинди тел әйләнми торган исемнәр белән аталган бик күп ризык әзерләде: тах-чин, абгушт, фесенджан, күкү, аш-э Реште, ләвәңге, шир-беренж, фалуде, локма... Боларны күз белән татып карарга гына калды. Алжир, азәрбайҗан һәм кыстап-кыстап өстәлгән үзбәк пылавыннан гыйбарәт өч төшке аштан соң «татарстан»лыларның ашказаны, никадәр генә үгетләп карасак та, Иран кухнясы турында ишетергә дә теләмәде.

Әмма без шаккаткан карашларыбызны яшермичә, кулларны болгап та, тел шартлатып та һәм һәр халыкка аңлаешлы башка ишарәләр белән дә ашчының осталыгына сокланубызны күрсәттек.

Хумоюн тәгамнәргә соклану телен аңлый, чөнки андый телне ул туган иле Иранда инде 20 ел ишетә-күрә – нәкъ менә шулкадәр гомерен ул ашчы һөнәренә багышлаган.

– Иран кухнясы – иң борынгыларның берсе, чөнки аның тарихы Фарсы империясе заманнарыннан ук башлана! – дип аңлата баш ашчы. – Шуңа күрә безнең ризыклар дөньяда иң тәмлеләрдән. Иран – аш-су осталары һәм шагыйрьләр иле бит ул!

Проза һәм шигърияттә аш-суга дан җырлаучылардан уңдык та соң бүген!

– Хуш исле соуслар, ширбәткә катырылган җиләк-җимеш, гөлчәчәк суы, кардамон, дарчин, марципан, зәгъфран әүвәл Фарсы хөкемдарлары табынында пәйда була, ә аннары нәкъ менә фарсы кухнясы аша Европаның төрле илләрендәге корольләрнең өстәлләренә килеп ирешә! – дип дәвам итә Хумоюн һәм Иранда иң популяр сый – «горме сабзи» дип аталган ризыкны әзерләүгә керешә.

Татарча аңлатып карасак, бу сарык ите, фасоль һәм төрле кыздырылган үләннәрдән рагу кебегрәк нәрсә булып чыга. Табынга аны май һәм зәгъфран салып әзерләнгән дөге – челоу белән бирәләр.

Горме сабзи өчен,



БЕЗГӘ КИРӘК БУЛАЧАК:

- сарык ите (сөяксез) – 500 г;
- суган – 1 баш;
- кызыл фасоль – 1/2 стакан;
- шпинат (вак туралган) – 1,5 стакан;
- яшел суган (туралган) – 1 стакан;
- петрушка (туралган) – 1/2 стакан;
- сельдерей (туралган яфрагы-сабагы) – 1/4 стакан;
- утлавык үлән (пажитник) (вак туралган яфраклары) – 1/4 стакан;
- лимон (суы) – 1 данә;
- тоз – тәменчә;
- төелгән кара борыч – тәменчә;
- фарсы лаймы limoo amani (киптерелгән) – 4 данә;
- кыздырыр өчен үсемлек мае.

Сый-хөрмәтле Иран ашчысы белән саубуллашканда, үзебезнең Рәдиф Гаташ шигырен искә төшердек:

Ачылдымы җырдан «бәхет капкасы»?
Алдымда ни? Гүя тылсым бакчасы...
Әкияти Гөл-лалә күрәм... ут чәчәк! –
Хыялымны ул таҗына төрәчәк!
Аһ, Матурлык! Нурдан яралган заты...
Ул – бәхеттер, кемнең өлеше, хакы?
Үземә алсам, Матурлык, тик микъдарың,
Мәңгелеккә илче-сурәт итәрмен!
...Шул Гөл-лалә тик хыял, ди, – Җирдә юк!
...Касәсеннән эчмәгән шагыйрь дә юк!



ТУ-214 ҺАВАГА АШКЫНА

Әхмәт Шакиров

Казанда Ту-214 пассажир лайнерын җыялар. Ул илдә беренчеләрдән булып Көнбатыш «Боинг» һәм «Эйрбас»лары урынын алачак. Ту-124 өчен импортны алыштыру кирәк булмаячак, чөнки барлык деталь, узел һәм двигательләрдән алып авионикага кадәр Россиядә җитештерелгән.

Казан машиналарының сыйфаты һәм ышанычлылыгы өчен борчылмаска була: «ике йөз ундүртенчеләр» инде унбиш ел дәүләтнең беренче затларына хезмәт күрсәтүче «Россия» махсус авиаотрядында оча. Лайнерларның уңайлылыгы һәм куркынычсызлыгы буенча төп пассажирлардан дәгъва алынганы юк. «Ачык һава» модификациясендә эшләнгән Ту-214 тә НАТО дәүләтләре территорияләре өстеннән күп сәгатьлек инспекцион очышлар вакытында үзен иң яхшы яктан күрсәтә. Тавыш һәм атмосферага зарарлы матдәләр чыгару буенча халыкара чикләүләр самолетка куркыныч түгел: нормаларга туры килү сертификатлар белән расланган.

БЕРЕНЧЕ БУЛУ ФОРСАТЫ

Ни өчен мондый шәп самолетны әлегә кадәр сериялләп чыгармыйлар? Бездә очкычларны күпләп чыгаруны оештыру өчен җитештерүгә, модернизацияләүгә акча кертергә, хезмәт күрсәтү челтәрен җайга салырга кирәк була. Ә әзер Көнбатыш «Боинг» һәм «Эйрбас»ларын сатып кына аласы, һәм авиакомпанияләр шулай эшләде дә. Моннан тыш, чит ил көндәшләре аз булса да экономиялерәк (сериялләп җитештерелә торган самолетларны модернизацияләү даими алып барыла, нәтиҗә дә шуннан килеп чыга). Боларның нәрсәгә китергәнен кабатлап торуның мәгънәсе юк. Ләкин бер яманлыкның бер яхшы ягы була. Хәзер граждан авиациясеннән бөтенләй колак какмас өчен, без үзебезнең авиасәнәгатьне үстерергә тиеш.

Бу эштә Казанның Ту-214 самолетына аерым роль бирелә. Сәгатенә 850 км тизлек белән 210 пассажирны 6500 километрга кадәр йөртергә сәләтле урта магистральле пассажир лайнеры – асылда бүген үк әлеге классны чит ил очкычларын алыштыра алырлык бердәнбер самолет ул. Перспективалы һәм өметле МС-21, үзебездә эшләнгән двигатель куелган «Сухой Суперджет», Ил-114 – бу машиналар Россия авиация сәнәгатенең потенциалы турында сөйли, ләкин алар әле коммерциячел кулланышка кертелмәгән, аларның «гадәти» тормышта үзләрен ничек күрсәтәчәкләрен киләчәктә белербез.

Фото: tupolev.ru, tatar-inform.ru

Түбәндәге бурыч шуннан килеп чыга да. Авиатранспорт тармагын үстерү буенча эшләнгән комплекслы программада 2030 елга кадәр җыелырга тиешле меңнән артык һава судносының 70 е – Ту-214 дип билгеләнгән. «Ростех» дәүләт корпорациясе башлыгы Сергей Чемезов күптән түгел РФ Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустин белән очрашу вакытында шундый ун машина 2025 елга чыгарылачак, дип белдерде. Чемезов сүзләренә караганда, С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводында хәзер җитештерүне киңәйтү өчен кирәкле яңа ангарлар төзелә: «Бик зур завод булачак, елгә 10 машина җыелачак. Аларны без 2025 елда ук кулланышка тапшырырга тиешбез».

«БОИНГ»ЛАР, «ЭЙРБАС»ЛАР, УРЫН БИРЕГЕЗ!

Беренче дүрт «ике йөз ундүртенче»не төзү буенча контракт узган елның көзендә үк имзаланган иде. «Бу самолетлар безнең Татарстан авиакомпаниясе өчен, – дип аңлатты ул чакта предприятиенең генераль директоры Николай Савицких. – 2024–2025 елларга». «ЮВТ аэро» генераль директоры Петр Трубаев төгәлләштереп болай диде: «Хәзерге шартларда авиация тармагында иң яхшы юл – үзебезнең җитештерүчегә йөз тоту. Бу яхшы самолет, безнең өчен бик актуаль, шуңа күрә аны сайладык».

РФ транспорт министры Виталий Савельев сүзләренә караганда, «Аэрофлот» та үзенең авиапаркы өчен төп лайнер буларак Ту-214 очкычын күз уңында тота. Илебезнең иң абруйлы авиакомпаниясе 2030 елга кадәр Казаннан 40 самолет алырга өметләнә – әлеге сан Берләшкән авиатөзелеш корпорациясе белән имзаланган ниятләр турында килешүдә теркәлгән. Танылган чит ил машиналарында очарга күнеккән заказчының таләпләре җитди, мәгълүматлар буенча, ул «Туполев» компаниясеннән пассажирлар салонына берничә дистә үзгәреш кертүне сораган. Хәер, бу гаҗәп түгел. Ни дисәң дә, Ту-214 беренче очышын 1996 елда ук ясаган, өч дистә ел элек эшләнгән салон интерьерлары, әлбәттә, искергән: бүген башка технологияләр, уңайлылык һәм зәвык таләпләре дә бүтән.

«Ике йөз ундүртенче»нең флагман авиакомпаниягә ошап җитмәгән тагын бер үзенчәлеге шунда: экипаж әгъзаларының саны. Әгәр «Боинг» һәм «Эйрбас»ларда алар ике булса, безнең «Туполев»та өчәү – командир һәм икенче пилоттан тыш, тагын бер бортинженер бар. Бу, әлбәттә, чыгымнарны арттыра. Экипажны кыскарту җиңел түгел, җитдирәк модернизация таләп ителә. Аны тиз генә эшләп булмый, шуңа күрә беренче вакыт чыккан машиналар өч кешелек командага исәпләнәчәк. Икенче яктан, экипажда бортинженер эшләве, чит ил аэропортларында безнең машиналарга хезмәт күрсәтү тәҗрибәсе юк чакта, һичшиксез, плюс булачак. Сүз уңаеннан, 1990 нчы елларда нәкъ менә илнең төп авиакомпаниясе, командир һәм икенче пилоттан тыш, Ту-214 дә бортинженер булуны таләп иткән дә, диләр...

ПЕРСПЕКТИВА – ЕЛЫНА 20 САМОЛЕТ

Самолетлар чыгарылганда, алар даими камилләштерелә. Аларны эксплуатацияләү буенча дөньякүләм тәҗрибә шуны раслый. Иң мөһиме – очкычлар елына бер-ике генә түгел, күпләп чыгарылсын. Серияләп җитештерү – бәяләрне төшерү дә, очкычны камилләштерү мөмкинлекләре дә, көндәшлекне арттыру да. Ниһаять, мондый перспектива Ту-214 өчен дә ачыла.

– Тармак алдында Россия базарына кире кайту юлы ябылган «Боинг» һәм «Эйрбас»лар урынына илебез авиакомпанияләрен үзебезнең очкычлар белән мөмкин кадәр тизрәк тәэмин итү бурычы тора, – диде март аенда Казан авиация заводына килгәч, «Ростех» дәүләт корпорациясе генераль директоры Сергей Чемезов. – Хәзер без Ту-214 җыюны елына ун данәгә кадәр арттырабыз. Киләчәктә җитештерү елына 20 самолетка кадәр артырга мөмкин.

Ике айдан соң РФ Хөкүмәте Рәисе белән очрашуда Чемезов билгеләп үткәнчә, Ту-214 самолетын җыюны 20 гә кадәр арттыру өчен өстәмә акча кирәк булачак. Һәм, күрәсең, әлеге мәсьәлә Хөкүмәттә аңлау тапкан, чөнки Премьер-министр:

– Субсидияләү һәм кредитлаудан алып Милли иминлек фонды акчаларын өлешчә куллануга кадәр – барлык мөмкин булган вариантларны карарга кирәк булачак. Без бу эшләргә ярдәм итәчәкбез, – дип нәтиҗә ясады.

«Ике йөз ундүртенче» һава киңлекләрен яулый башлады.



* Программа РФ Президенты күрсәтмәсе буенча Хөкүмәт тарафыннан расланган.

ТАТАРСТАНДА ГЫНА

ВЕРТИКАЛЬ ОЧУ ХЫЯЛЫ

Әхмәт Шакиров

Подъездга пицца китерүче пилотсыз такси һәм робот... Иннополиста мондый хәлгә күптән гаҗәпләнмиләр: алар өчен бу гадәти. Ә менә конвертоплан – икенче мәсьәлә... IT-башкала күгендә пилотсыз аппаратлар йөк ташу белән шөгыльләнергә тиешле беренче Россия шәһәре булачак.

Бөкеләрдән интеккән мегаполиста йөк китерүче һава почтальоны ролен үз өстенә алган аппаратны KazanForum уздырылган көннәрдә «Казан Экспо»да да күрергә мөмкин иде. Формасы буенча самолетка да, вертолетка да охшаган аппарат. Канатлары самолетныкы кебек. Вертикаль пилоннарда икешәр винт – вертолетныкы. Исеме дә, уникаль сәләтләре дә шушы сыйфатлардан. Вертикаль күтәрелә, самолет кебек шактый зур тизлек белән оча, шулай ук вертикаль рәвештә, утыру өчен урынны мөстәкыйль сайлап, теләсә кайсы мәйданга төшеп утыра.

КҮКТӘГЕ ХЕЗМӘТЧЕ

Һава юлы буенча посылка һәм бандерольләр ташу конвертоплан ия сәләтләрнең берсе, ләкин бердәнбере түгел. Ул геодезия һәм топография белән шөгыльләнә ала, торбаүткәргечләрнең торышын, авыл хуҗалыгы җирләренең сыйфатын тикшерә, дистәләгән җир белгече хезмәтен алыштыра ала. Күптән түгел башкарган гаять зур хезмәтенең берсе: конвертоплан 200 млн гектардан артык җирне цифрлаштырырга ярдәм иткән. Аппарат җир өстеннән бер генә мәртәбә очып үтә – кулланылган технология җирлекнең 3D-моделен ясарга мөмкинлек бирә.

Композит материаллардан эшләнгән конвертоплан җиңел, тиз һәм маневрлы, кирәк булганда, тыныч кына киртәләрне урап үтеп, автопилотта оча, һавада берничә сәгать була ала, көчле җил һәм зур биеклектә очканда артык йөкләнешләрдән курыкмый.

Фото: robotic.innopolis.university

«Казан Экспо»да тәкъдим ителгән пилотсыз аппарат инде сериялэп чыгарыла. Иннополис стенды белән танышу вакытында бу, күрәсең, РФ Хөкүмәте Рәисенең беренче урынбасары Андрей Белоусовның игътибарын җәлеп иткән. 29 килограмм авырлыктагы аппарат 6–7 килограммлы йөк берничә йөз километр ераклыкка илтергә сәләтле. Компонентларының 70% тан артыграгы – җирле җитештерүченеке, бәясе 2,5 млн сумнан башлана.

Татарстан конвертопланы мөмкинлекләре турындагы мәгълүматны бәяләп, вице-премьер болай диде:

– Егетләр шулкадәр алга китәр дип, уйламаган да идем. Эшнең «Аэронет»*та башлануы миңа бигрәк тә ошый. Бу берничә ел элек Президент күрсәтмәсе буенча эшләп киткән Милли технология инициативасының тәүге юнәлешләренең берсе. Ул хәзер үз җимешләрен бирә.

ЭШ – ҺАВА ХӘРӘКӘТЕ КАГЫЙДӘЛӘРЕНДӘ

Кызганычка, конвертоплан нинди генә камил булмасын, аны ипи алырга кибеткә җибәреп булмый. Эш монда дроннарның санында түгел. Җитештерүче инде бүген үк аена 10 квадроплан җыя һәм чыгаруны өч мәртәбәгә арттырырга әзер – ихтыяҗ гына булсын. Әмма пилотсыз аппарат шәһәр күген үзләштерсен һәм, тирә-юньдәгеләргә куркыныч тудырмыйча, шәһәр мохитенә яраклашсын өчен, һава хәрәкәте кагыйдәләре, ягъни закон булырга тиеш. Инфраструктурасы да ачылсын иде, әйтик, конвертоплан күтәрелергә, төшәргә, сервис хезмәте алырга тиешле дронопортлар. Очышлар белән идарә итү үзәге һәм анда эшләргә операторлар кирәк...

Санап үтелгәннәрдән нәрсәләр бар соң? Иннополиста беренче дронопорт инде эшли, пилотсыз аппарат белән идарә итү чаралары эшләнгән һәм камилләштерелә, хезмәт күрсәтү җайга салынган. ТР вице-премьеры Роман Шәйхетдинов сүзләренә караганда, җитештерү куәтләре, шулай ук дөнья дәрәҗәсендәге компетенцияләр бар. Иннополис пилотсыз авиация системалары өчен конструктор, технолог, уйлап табучы, оператор һәм программистларны укытырга әзер. Ә законнар ни хәлдә?

Пилотсыз аппаратларның һавадагы хәрәкәтенә стартны эксперименталь хокукый режим бирергә тиеш. Җир өстендәге пилотсыз машиналар өчен шундый документ кабул итү үз вакытында аларны Иннополис урамнарында йөртә башларга мөмкинлек бирде. Бүген чиратта – оча торган пилотсыз аппаратлар. Татарстан пилотсыз авиация системалары (БАС) буенча эксперименталь хокукый режимны үз инициативасы белән эшләде. Документ ел башында ТР Дәүләт Советында хупланды, хәзер ул федераль дәрәҗәдә килештерелә. Кабул ителсә, Иннополис күгендә конвертопланнар очачак һәм алар, пилотсыз таксилар яки азык-төлек китерүче роботлар кебек, шәһәр пейзажының бер өлешенә әйләнәчәк.

КИЛӘЧӘКНЕ КҮЗДӘ ТОТКАН ХАБ

Күз алдына китерегез, Иннополис күгендә яхшы көйләнгән механизм төгәллеге белән, катгый билгеләнгән һава коридорлары буенча, хәрәкәт кагыйдәләрен үтәп, пилотсыз җиңел аппаратлар оча. Алар дронопортка төшә, зур булмаган йөкне ала, күтәрелә һәм, билгеләнгән урында йөкне калдыру өчен, алга таба оча. Бәлки якын киләчәктә почта товарларын нәкъ шушы система буенча ташыр дә... Һәрхәлдә, «Аэронет» аналитика үзәге» АКБО директоры Сергей Жуков: «Ихтимал, Иннополиста посылкалар китерү буенча йөк хабы ачылыр. Технология һәм норматив база үсеш ала барган саен, очышлар да куркынычсызракка әйләнәчәк. Шул вакытта инде авыррак дроннар ясап, күпмедер дәрәҗәдә юлларны да бушатырга мөмкин булачак», – диде.

IT-шәһәр белгечләренең эшләнмәләре, күргәнебезчә, аерым бер шәһәр өчен аттракцион түгел, ә тулы хокуклы сынау полигоны. Иннополис үзен җитештерү буенча да, компетенцияләр буенча да илебезнең пилотсыз авиация үзәкләренең берсе буларак җитди рәвештә күрсәтергә ниятли.

ТР вице-премьеры Роман Шәйхетдинов журналистларга аңлатканча, «сүз Иннополис шәһәре территориясендәге махсус икътисадый зона чикләрендә фәнни-җитештерү үзәге булдыру турында бара, бүген бу мәйданнарда пилотсыз очу технологияләрен эшләүче кайбер компанияләр эшли». Шул ук вакытта Иннополис БАС буенча яңа милли проектта катнашачак, өстәвенә, сүз БАС һәм аңа комплект детальләрен уйлап табу, стандартлаштыру һәм сериялэп җитештерү турында гына түгел, ә кадрлар әзерләү хакында да бара. «Иннополистагы коллегалар милли проектны формалаштыруда бик актив катнаша, проектны гамәлгә ашыруда төп катнашучыларның берсе алар булыр, дип өметләнәбез», – дип хәбәр итте Андрей Белоусов Казандагы форум көннәрендә матбугат вәкилләре белән аралашканда.

Хәрби булмаган пилотсыз аппаратлар буенча эксперимент ил өчен никадәр мөһим соң? Февраль аенда пилотсыз авиация системалары җитештерүчеләр белән уздырылган киңәшмәдә Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенең беренче урынбасары Андрей Белоусов бик төгәл әйтте: бүгенге вазгыятьтә илебездә пилотсыз авиация системаларын булдыру технологик суверенитет дәрәҗәсен арттыру юлында иң мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора. Пилотсыз авиация системаларын үстерү буенча милли проект тармакны тиз арада алга җибәрү, төп җитештерүчеләрне туплау өчен нигез булырга тиеш. Проект Россия Федерациясе Президенты күрсәтмәсе буенча эшләнә.

* *Аэронет – граждан пилотсыз авиация һәм космик системаларын эшләүче һәм эксплуатацияләүчеләрнең һөнәри берләшмәсе. Бизнесны һәм инновацияләрне үстерү өчен БАС тармагында һава законнарын камилләштерү буенча эшчәнлек алып бара, пилотсыз индустрия лидерларын берләштерүче фәнни-гамәли чаралар оештыра, дәүләт-шәхси партнерлык нигезендә финанс ярдәме өчен проектларны сайлап ала һәм үстерә.*

БӨЕК ЕЛГАЛАР ЧАТЫНДА

Россиянең дүрт легендар елгасы кушылган җирләрне күреп кайтасыгыз киләме? Бик кызык бит! Һәм тормышка ашырып булырлык та. Нократ та, Агыйдел дә Татарстандагы Чулман елгасына коя. Чулман белән Идел дә бергә кушыла. Җәяүләп үк булмаса да, бу матур җирләрне машинада бер көндә карап-урап кайту бик мөмкин эш. Киттекме?

Елга ярында ук вакыт тузаны каралткан землянка-йортлар тора, биредәге халык аларны «ватага» дип йөртә.

ЧУЛМАН КОЧАГЫНДАГЫ НОКРАТ

Мамадыш районы Грахань авылына килеп җитәрәк берничә чакрым чуерташлы юл сикәлтәләре йортлар артында гаҗәеп манзара ачылуга ук онытыла. Син – өстә, калкулыкта, ә сулга карасаң, аста – тиз агымлы киң Нократ. Нәкъ каршында исә офыкка тоташкан зәңгәрсу Чулман җәелгән, анда киң-куәтле Нократ, төссезләнеп, океандагы бик нәни инеш кадәр генә булып кала. Шунысы сәер: агрессив Чулман, Нократ агымына туп-туры диярлек барып кереп һәм аны тулысынча йотып, кисәк кенә көньякка борыла. Ул үз юлын кемдер Нократ өчен сызган ермактан дәвам итә кебек тоела...

Сукмактан су янына ук төшәбез. Монда бөтен нәрсәдән бакыйлык һәм тынычлык аңкый. Елга ярында ук вакыт тузаны каралткан землянка-йортлар тора, биредәге халык аларны «ватага» дип йөртә. Элегрәк аларда ятьмәләр һәм башка балыкчы кирәк-ярагы сакланган. Йорттагы кар базына балыкның бер өлешен төшереп куйганнар, чөнки берьюлы гына күтәреп китәрлек булмаган. Бүген елга ярындагы моңсу иске көймәләр генә кайчандыр төшемле булган кәсеп турында хәтерләтеп тора. Аларның хәтта дюралюминийдан ясалганнарының да хәле мөшкел, ә инде 70 нче еллардан ук калган, сумала сеңдерелгән агач көймәләр турында әйтәсе дә юк. Аларны күптән суга төшермиләр – хәзер андыйларны ясый да белмиләр, бик зур, килбәтсез, авыр булганга, аларның кирәге дә шул чама гына...

– Балык бар биредә, – дип җирле халык белән бәхәскә керә кунак балыкчы. – Нократ кәлчәге (чехонь) дә, Чулман корбан балыгы да җитәрлек. Әлбәттә, җитди кәсеп өчен түгел, ә менә

Фото: Әскәр Сабиров, «Татарстан» журналы архивы



һәвәскәр балыкчыларга юанырга була. Тота белергә генә кирәк...

Михаил Николаевич биргә, ике елга кушылган җиргә, еракта, Алабугадан ук килә, һәм аның балыкчы хикәятләренә ышанырга буладыр. Төп дәлил – безгә күрсәткән трофейлары: шактый зур кәлчәк һәм кечкенә генә корбан балыгы. Кызганыч, фото һәм видеога төшүдән катгый рәвештә баш тарта, чөнки «Су саклау зонасы» табличкасы янындагы тыелган урынга куелган машиналарның берсе нәкъ менә аныкы булырга тиеш...

Безнең аралашуны дәшми-нитми генә мәгърур тау күзәтә. Ул үткән гасырларның сак каланчасы кебек су өстендә биек булып калкып тора. Археологлар әйтүенчә, борынгы заманнарда биредә бу каланча гына түгел, ә тулы бер болгар бистәсе булган. Ике яктан – текә ерымнар, өченче яктан өч метрлы вал һәм тирән озын чокыр белән чолгап алынган өчпочмаклы тауда шәһәрлек урнашкан. XIX гасырда бу урында бакыр эшләнмәләр, сөякләр табылган. Аеруча мәгълүм табылдыклардан – бронза асма бизәк, аны узган гасырның 20 нче елларында тапканнар.

Казаннан ерак түгел урнашкан яр буендагы Грахань шәһәрлеге, ике елга кушылган урындагы «югары» дәрәҗәсеннән файдаланып, мөгаен, бу турыдан үткән суднолардан ясак җыйгандыр – сәүдәгәрләр биредән сиздермичә генә берничек тә узып китә алмаган бит. Россия империясе чорында да Грахань авылы хәлле яшәгән: XIX гасыр азагында биредәге пристаньнан ел саен 30 мең пот йөк төяп җибәрелгән.

Мөгаен, Граханьдагы раритет – гаять зур тегермән ташы – нәкъ менә шул бай-тук еллардан бирле сакланып калгандыр. Урам уртасында, чирәм арасында рәхәтләнеп ята бирә. Тегермән үзе күптән юк инде. Кайчандыр алты йөзләп кеше яшәгән авыл әкренләп үзе дә бетүгә таба бара – хәзер биредә нибары ике дистәләп кеше калган.

Бөтен нәрсә ага, үзгәрә. Нократ белән Чулман гына, бер кавышкач, башка аерылмый, бергә юлларын дәвам итә.

НИЧЕК БАРЫП ҖИТӘРГӘ

Казаннан М-7 юлы белән Мамадыш чатына кадәр барасың. Аннары уңга, Соколка ягына борыласың, аннан соң исә сулга борылып, Граханьга килеп җитәсең.

Нократ белән Чулман кушылган җир.

Агыйдел тамагына кадәр – 30 чакрым.

СӘЛАМ, АГЫЙДЕЛ, НИХӘЛ, ЧУЛМАН?!

Агыйдел белән Чулман кушылган җиргә барып җитү – үзе бер ребус икән. Әйләнә-тирәдәге берничә чакрым арада – тоташ су баса торган тугайлар, күлләр һәм сазлыклар. Хәтта яр буена барып җитү өчен дә бик тырышырга кирәк. Бер урында юлны куе камышлык баскан, аннары тагын ярты сәгатькә туктарга мәҗбүрбез – кып-кызыл каен җиләге тулы болынны ничек туктамый гына үтеп китәсең инде...

Карта буенча дөрес барабыз кебек. Менә ул, Агыйдел, еландай боргаланып һәм култыкларга таралып, Актаныш районының көнбатыш чигендә Чулманга коя. Әмма безне алдан ниятләгән урынга китереп җиткерү өчен бернинди юлъкүрсәткеч тә күренми. Яр буенда бер генә торак пункт та юк. Кайчандыр Чулманда Дербешкинский бистәсе булган, аннан Агыйдел белән кушылган җиргә кадәр кул сузымы кадәр генә ара калган – ул бистә күптән юк инде. Өшәр (Семиостровo) авылы булган – ул да юк...

– Ориентирларыгыз соңлаган инде. Бер илле елга, – ди безнең кебек үк юлсыз җирдә үзенең «уазигында» баручы Равил Заһитов. – 70 нче елларда, Түбән Кама сусаклагычын тутырганда, су басу зонасыннан бөтен халыкны күчерделәр, яр буендагы авылларның берсе дә калмады. Агыйделнең Чулманга кушылган урыны да элек бик ачык күренеп тора иде, шуннан соң исә әллә ничә чакрымга җәелгән суда эреп юкка чыккандай булды. Ярга кадәр барып җитә алсагыз да, ике елганың кушылуын күрүегез бик икеле.

Юк инде, без чигенергә җыенмыйбыз. Озын кунычлы итекләрне киеп, җәяүләп китәбез һәм менә тал баскан ярга килеп тә җитәбез. Таллар артында утрау һәм утраучыклар белән кискәләнгән су җәелеп ята, һәм кайдадыр бик еракта, теге якта, Удмуртиядә, биек Чулман яры шәйләнә. Аннан, биектән, Агыйделнең Чулманга коюы яхшы күренәдер, мөгаен. Биредә исә бер генә калкулык та, күзәтү мәйданчыгы да юк. Бик аяныч. Әмма күңелне төшермибез. Көчсез генә моторлы резин көймәгә утырып елгага керәбез.

Биткә салкын тамчылар чәчри, каршы искән җил алга барырга комачаулый, әмма болар каршыбызда пәйда булган искиткеч манзара тәэсирендә чүп кенә булып кала: биредә елга ике агымга бүленгән кебек, алар, кисешмичә һәм кушылмыйча, параллель бара. Берсе, ачыграк төстәгесе – Агыйдел, икенчесе, карасуырагы – Чулман. Без максатыбызга ирештек!

Гаҗәеп манзара белән туйганчы хозурланып, ярга чыгабыз. Һәм шунда гына янәшәдәге табигатькә игътибар итәбез. Янәшәдәге күлдә нәфис пар аккош йөзә, камышлар арасына соры челән яшеренгән, баш өстебездә исә, судагы балыкны күзләп, чын аристократ – ак койрыклы диңгез бөркете оча...

Без гаҗәеп урында. Биредә Агыйдел Чулманга кушыла.

НИЧЕК БАРЫП ҖИТӘРГӘ

Казаннан М-7 юлы белән Яр Чаллы һәм Минзәлә аша Уфа ягына барасың. Пучы янында сулга борыласың һәм Актанышка таба – Зәбәергә кадәр барасың. Аннары сулга – Татар Ямалысы ягына... Маршрутның азаккы өлешендә юллар бөтенләй юк.

ИДЕЛ БЕЛӘН ЧУЛМАН БӘХӘСЛӘШКӘН ҖИРДӘ

Әйләнә-тирәдә әллә ничә чакрымнарга сузылган су, су, су һәм бик еракта гына яр сызыгы

шәйләнә... Бу – әсәрләндерә торган күренеш. Ул кемнедер кыя кырыенда дәшми генә басып торырга, кемнедер сокланып кычкырырга мәҗбүр итә. Йә булмаса, хисләр ташудан, җырлап җибәрергә. Бу урынны һәркем гомерендә бер генә тапкыр булса да барып күрергә тиеш. Биредә Идел белән Чулман бергә кушыла. Без әлеге иксез-чиксез диңгез өстеннән күтәрелгән кыяда басып торабыз – атаклы Лобач тавы бу. Аны «Бурлаки на Волге» картинасына эскизлар ясаганда Репин үзе сурәтләгән, диләр... Тау түбәсендәге маякка куелган ике күрсәткеч – «Идел» һәм «Чулман» – сезнең нәкъ менә ике бөек елга кушылган җирдә басып торуыгызга дәлил булып тора. Хәер, төгәлрәк әйтсәк, аларның кушылган җире тау итәгендә түгел инде, ерактарак, диңгез эчендә.

– Әле күптән түгел генә Идел белән Чулман бөтенләй башка җирдә, Кама Тамагыннан бер биш чакрым астарак очраша иде, – дип төзәтер иде теләсә кайсы экскурсия үткәрүчене Лобач тавы, әгәр сөйләшә белсә. – Куйбышев сусаклагычын төзегәнче, ике елга арасындагы таулар тезмәсе аларга кушылырга ирек бирмәде, аннары исә, су күтәрелгәч, таш киртә аста калды...

Әлеге хәлләр моннан 66 ел элек булган, әмма аксакал Лобач тавы өчен бу кичә генә булган кебек әле. Ни дисәң дә, 136 метрлы пәһлеван әйләнә-тирәне 340 миллион ел чамасы күзәтә бит инде! Текә кыя кисемнәрендә ачылган доломит, известьташ кебек тау токымнарын өйрәнү – миллионнарча ел элек безнең Җиребезнең нинди булуын күрсәткән кыска клип карауга тиң бит ул.

Идел Чулманга коямы, әллә Чулман Иделгә кушыламы, дигән күптәнге бәхәскә җавап та тау өчен бер дә сер түгел. Чулман көндәшеннән өлкәнрәк – моңа Лобач шаһит, очрашкан урында Чулман мулрак сулы, аның юлы, елга башыннан алып Иделгә кушылганчы, озынрак... Шунлыктан «Идел Каспий диңгезенә коя...» дигән сүз дә һәркемгә билгеле хакыйкатьтән бигрәк, безнең фикерләвебезнең стереотибы гына...

Хәер, кайсының әһәмиятлерәк булуы турында бәхәснең кирәге бармы соң? Бу җәһәттән сезгә биредә борынгы бер риваятьне сөйләп күрсәтәчәкләр. Кайчандыр Обач (Лобач, дип укы) исемле хан яшәгән һәм аның Идел һәм Чулман исемле ике кызы булган икән. Алар икәү бәхәсләшкән: кайсы матуррак, сылурак, акыллырак. Моны белеп алган әтиләре ярыш оештырган... Һәм шул сәбәпле Тәңренең ачуын чыгарган: «Кызларың бәхәсләшкәнне дә тыныч кына карап тора алмыйсың икән, йөрәгең таштыр синең!» – дигән һәм Обачны кыяга әйләндергән – ул кызларының бәхәсләшкәнен мәңге карап торырга тиеш булган. Кызларын исә елгаларга әверелдергән...

Идел Чулманга коямы, әллә инде Чулман Иделгәме – мөһим түгел. Кама Тамагында кушылып, алар икәү бергә ага башлый. Бергә исә – һәрвакыт көчлерәк, җетерәк ул. Күпкә яхшырак та.

НИЧЕК БАРЫП ҖИТӘРГӘ

Казаннан М-7 юлы белән Ульяновск борылышына кадәр барасың. Аннары шул трассадан Кама Тамагы борылышына кадәр. Кама Тамагыннан – «Лобач тавы» табигать заказнигына кадәр авылара юл буйлап.

#ШӘПБЛОГЕР

ТАТАРСТАН ШӘП БЛОГЕРЛАР ҮСТЕРӘ

Балаларның пубертат чоры иң катлаулысы, һич алдан фаразлап булмый торганы дип санала, ә кайчак иң куркынычы да булырга мөмкин. «Ә менә Татарстан яшүсмерләренә куркыныч янамый!» – дип белдерә «Ялкын» журналының баш мөхәррире Илназ Фазуллин. Һәм Татарстандагы иң яхшы блогерларның актив ярдәме белән аеруча тиктормас һәм аеруча тәвәккәл яшүсмерләрне үз мәдәниятләрен һәм телләрен үсмерләр дөньясына чыгарырга, яшьтәшләре арасында алдынгы фикерле булырга өйрәтүләре турында сөйли. «Шәп блогер» медиамәктәбендә дәресләр бөтен буш вакытны ала икән, балалар, ахмаклык кылып, эленке-салынкы йөри алмый.

ШУНДЫЙ «ДВИЖУХА» БУЛГАНДА, НИНДИ КҮҢЕЛСЕЗЛӘНҮ УЛ

– Безнең балаларга боегырга вакыт юк, – ди Илназ. – «Ялкын» журналы – һәрвакыт нинди проектлар дигән сүз ул. Басма версиядән тыш, интернет челтәрендә бик бай контентыбыз бар. Берьюлы 2-3 иҗади проект алып барыла торган биш ютуб-канал эшли. Төрле социаль челтәрләрдә аларның гомуми саны дистәдән артык. «Шәп блогер» – әнә шундый проектларның берсе.

НУЛЬДӘН БАШЛАП ҺӘМ БУШЛАЙ

– Ягъни сез менә шулай, нульдән башлап, шәп блогерлар үстерәсез булып чыга? Бу эш ничек бара?

– Без үз аккаунтларын Татарстанда иң киң таралган телләрдә – татарча, русча, марича, чувашча һәм удмуртча алып баручы блогерларны бер командага җыйдык. Бу егетләр һәм кызлар «Шәп блогер» медиамәктәбендә укытучыларга әйләндe. Алар тема сайларга, контентны планлаштырырга, сценарийлар язарга, аудитория белән аралашырга, камерага эшли белергә, социаль челтәрләрнең алгоритмнарын аңларга, видео төшереп, аны монтажларга, фотога дөрес төшерергә өйрәтәчәк... Һәм болар барысы да тулысынча бушлай!

ЗУР КАЛАДАН ДА, ЕРАК РАЙОННАН ДА...

– Укучыларны кайлардан җыясыз?

– Бөтен Татарстан буйлап. Безнең төрле телдә сөйләшүче блогерлар бишлеге махсус автобуста республиканы гизә, алар мәктәпләрдә чыгыш ясый, укырга теләүчеләр исә гариза тутырып, безгә җибәрә. Без инде Чаллыда, Түбән Камада, Байлар Сабасында, Мамадыш, Арча, Балтач, Актанышта булдык... Сүз уңаеннан, медиамәктәпнең булачак укучылары яшь чиген 35 яшькә кадәр күтәрттерде.

Укулар онлайн һәм офлайн форматта узачак. Осталык дәресләрен Татарстан белгечләре һәм федераль дәрәҗәдәге спикерлар алып барачак. Этник темаларга аерым игътибар бирелә. Укучыларның һәр төркеме өчен аңлаешлы, кызыклы итеп, аларның туган телендә сөйләячәкләр. Топ-5 блогерларыбыз: Олеся Дмитриева, Илнар Идрисов, Александр Ситников, Ксения Романова, Лиана Фёдорова укуларның тәүге көненнән алып соңгы дәрескәчә егет-кызларга булышып, һәрчак янәшә барачак.

Проектны Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов хуплады, ул Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясен гамәлгә куйган иде. Комиссия башлыгы Марат Готыф улы Әхмәтов та бу эшчәнлегебезне хуплавын белдерде. Моның өчен аларга бик зур рәхмәт!

БЕРНИЧӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, КҮБРӘК

– Укулар озакламый бетәр, ә аннары нәрсә?

– Медиамәктәптә укуларның тәмамлануын билгеләп, октябрьдә зур фестиваль үткәрергә планлаштырабыз. Һәм шул вакытта Татарстан яшь, белемле, уңышлы, чик-чаманы да белгән, креатив фикерле яңа блогерларга баер, дип уйлыйм. Әгәр бу укулардан соң без аккаутларын үз туган телләрендә алып баручы берничә генә булса да блогер үстереп чыгара алсак, миссия үтәлде, дип саныйм. Ләкин мин аларның берничә генә түгел, ә күпкә күбрәк булачагына ышанам, чөнки Татарстан район-калаларындагы яшьләр медиамәктәп белән бик кызыксына!

Фото: Фирүзә Закирҗанова

ТАТ МЕДИА

ЯЗЫЛУЧЫЛАРГА СКУТЕР, ТЕЛЕВИЗОР

һӘМ БАШКА БҮЛӘКЛӘР

БҮЛӘКЛӘРНЕ УЙНАТУ: 17 АВГУСТ 2023 ЕЛ

1 ЯЗЫЛ

«ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына языл (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 ҖИБӘР

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә 2023 елның 11 августына кадәр җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз!). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ

Телевизор, газонокосилка, вертикаль пылесос һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – скутер! Бүләкләрне уйнату 2023 елның 17 августында узачак

Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru. сайтында белә аласыз. Акция 2023 елның 16 маеннан 2023 елның 20 сентябренә кадәр уздырыла. Гаризалар 11.08.2023 кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемдәгедән аерылырга мөмкин.

акыллы гамәлләр / игелекле эшләр / мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Каравон яңадан **ничек** торгызылган

Марилар **ничек** теләкләрен чынга ашыра

Балтай бабай **ничек** мордва мәдәнияте бәйрәмен оештырган

Үпкә авыруларын **ничек** белергә

ДЕНЬ РОССИИ
12 июня

ВАТАНГА МӘХӘББӘТ БӘЙРӘМНӘРЕ

Җәй – төрле халыклар үз бәйрәмнәрен үткәрә торган вакыт. Русларның Каравоны, татарларның Сабан туе, удмуртларның Гырон быдтоны, мариларның Семык бәйрәме, мордваларның Балтае, чувашларның Уявы... Һәм, әлбәттә, уртак бәйрәм – Россия көне... Татарстанның күпмилләтле халкы милли бәйрәмнәрне уздырырга, аннан соң җавап йөзеннән бер-берсенә кунакка барырга, бергә җыелып Россия көнен бәйрәм итәргә дип, тантаналарга әзерләнә, кунаклар чакыра, үткәрә һәм рәхәтләнеп ял итә белә.

Ә бу ничек була соң? Карагыз, укыгыз, бәйрәм рухын тоегыз һәм халыклар дуслыгын саклагыз!

Фото: rais.tatarstan.ru

КАРАВОН.
ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР

Татарстанда җәйге милли бәйрәмнәрне гадәттәгечә Каравон башлап җибәрде. 15 мең кунак, 186 иҗат коллективы, ярминкәләр, әйлән-бәйлән, тамашалар, бәйгеләр, уеннар...

Барысы да моннан 300 ел элек Никола Каравоны йоласы барлыкка килгәндәге кебек тоела.

Әмма аның тарихында тыюлар да, куылулар да булган, бәйрәм вакыт сынавын да үткән. Никольское авылының картлары һәм әлеге тылсымлы бәйрәмне яңадан тергезгән энтузиастлар ярдәмендә без берничә аерма санадык:

БЕРЕНЧЕСЕ
ЭЛЕК КАРАВОННЫ ӨЧ КӨН УЙНАГАННАР, ХӘЗЕР – БЕР...

«...Өч көн дәвамында кызлар, бармак очлары белән генә тотынышып, бөтен авылны әйлән-бәйлән уйнап урый. Иң матур киемнәрен кия. Шушы өч көндә «кәләшләр күргәзмәсендә» үзенә дигән кәләшкә күз атып калып булган. Хәтта мәкале дә бар: «Кыз бала каравонда үлән таптамыйча, аңа яучы җибәрергә ярамый».

Хәзер исә бер көн, әмма киң колач белән үткәрелә. Никольское Каравонына бөтен Россиядән кунаклар җыела. Дәрәҗәле кунаклар да килгән һәм килә: республиканың беренче Президенты да, икенчесе дә, мөфти дә, мәрхүм митрополит Феофан да... Бәйрәм федераль әһәмияткә ия.

Фото: Александр Ефремов

ИКЕНЧЕСЕ
ЭЛЕК ӘЙЛӘН-БӘЙЛӘНГӘ КЫЗЛАР ЧЫККАН, ХӘЗЕР – ӘБИЛӘР

Элек нигездә кияүгә чыкмаган кызлар әйлән-бәйлән уйнаган. Һәр ел саен яшьрәк кызлар үсгәлә, кияүгә чыкканнары исә төшеп кала барган... Әмма бу кагыйдә катгый булмаган: әйләнәсең килә икән – бас кына! Ирең генә каршы килмәсен...

Каравонны әбиләр коткарып калган. Бәйрәмне кайтаруда аларның ярдәме зур. Җырларын, яшь чакта уйный торган каравон йолаларын искә төшергәннәр. 1988 елда «Волжанка» фольклор ансамблендә 22 әби һәм бер бабай булган. Ансамбль хәзер «Каравон» исемен йөртә.

ӨЧЕНЧЕСЕ

ЭЛЕК КАРАВОН ЕШ КЫНА СУГЫШУ БЕЛӘН ТӘМАМЛАНГАН, ХӘЗЕР – ДУСЛЫК БЕЛӘН

«Без каравонның тыелмаган чагына да туры килдек, – дип укыйбыз Никольское авылы аксакалы А.И.Спирягинның хатирәләреннән. – Безгә ул вакытта унөч-ундүрт яшьләр иде. Кич белән йөздән артык кеше җыела. Кызлар һәм егетләр каравон уйный, өлкәннәр өйләр буйлап йөри – Никола табынлы бәйрәм бит ул. Тамак туйгач, барысы да каравонга тартыла. Төнге унбер-уникеләр тирәсендә. Тугыз тапкыр җырлап узгач, сугыша башлыйлар, бер оч икенче очка, бер авыл икенче авылга каршы күтәрелә. Барысы да булды инде».

Хәзер сугышулар юк, билгеле. Каравонга килгән төрле халык вакилләре җырлый, бии, күңел ача, бәйрәм хуҗаларын үзләренең «Каравон»ына чакыра: татарлар – Сабан туена, марилар – Семыкка, чувашлар – Уявка, удмуртлар – Гырон быдтонга, мордвалар – Валда шиняська... Халыклар дуслыгы гөрли!

КАРАВОННЫҢ ТӨП ЭТАПЛАРЫ:

1955 елда совет власте дини бәйрәмгә санап тыя.

1988 елда Сергей һәм Светлана Трусовлар традицияне торгызырга була.

1993 елда республиканың Мәдәният министрлыгы ярдәме белән Русское Никольское авылында беренче рус фольклоры фестивале үткәрелә. Анда өч фольклор коллективы катнаша.

1994 елда икенче фестивальгә җиде ансамбль килә.

2003 елда бәйрәм гомумреспублика статусын ала һәм «Россия мәдәнияте (2001–2005 еллар)» Федераль максатчан программасына кертелә.

2007 елдан башлап, бәйрәм Идел буе фольклор фестивале статусын ала, бүгенге көндә федераль масштабтагы чара булып санала.

2020 елда, пандемия вакытында, бәйрәм үткәрелми. Әмма 17 әби чиркәү каршындагы буш мәйданда, резина перчаткалар киеп, кулга-кул тотынышып, үзләренең каравонын уйный...

СЕМЫК: ҺӘММӘБЕЗ ТАТУ, БЕЗДӘ ЧЫН ДУСЛЫК!

«Татарстан» журналын һәрбер милли бәйрәмдә аның үзенә генә хас халыклар дуслыгы мохите сокландыра. 3 июньдә ТРның Әгерҗе районындагы Пелемеш авылында да мариларның Семык бәйрәмендә Татарстанда һәм күрше төбәкләрдә яшәүче төрле милләт вәкилләре очрашты.

– Мариларның Семык бәйрәме, русларның Каравоны, татарларның Сабан туе, удмуртларның Гырон быдтоны, чувашларның Уявы һәм мордваларның Валда шинясе кебек үк, халыклар арасында дуслык һәм үзара аңлашу атмосферасы тудыруга ярдәм итә, – диде мари мәдәнияте бәйрәмендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов. Ул мариларның дустанә, хезмәт сөючән, үзләренең телен, гореф-гадәтләрен, йолаларын саклаучы халык булуын искәртеп китте.

Җавап итеп, бәйрәм хуҗалары шундук үзләренең милли гореф-гадәтләрен күрсәтте: кунакларны «туй»га – мариларның туй йоласына чакырды. Туйдан соң һәркем, теләк теләп, агачка тасма бәйли ала иде. Марилар әйтүенчә, болай итеп теләгән теләк һичшиксез чынга ашачак.

Фото: Александр Ефремов

Шулай ук алар җәй башлануын да хәбәр итте, чөнки элек-электән Семык чын җәй килүен күрсәтә торган бәйрәм санала. Бу көнне мәрхүмнәрне искә алу фарыз, мул уңыш, илгә һәм гаиләгә иминлек теләргә кирәк.

– Татарстан Республикасы – күпмилләтле төбәк, биредә милли үзенчәлекләрне саклап калу, мәдәниятне, телне, гореф-гадәтләрне үстерү өчен барлык шартлар да тудырылган, – дип, мари халкының этномәдәни үзенчәлекләрен саклау һәм үстерүгә зур өлеш кертүләре өчен Татарстан җитәкчелегенә рәхмәтләрен җиткерде Мари Эл Республикасы Башлыгы Юрий Зайцев. Үзенең сүзләрен ул борынгы мари рецепты буенча әзерләнгән квас белән җөпләп куйды.

«БАЛТАЙ» – МУЛ УҢЫШ ХӘБӘРЧЕСЕ

Риваятьләргә караганда, моннан йөз еллар элек урманда яшәгән дәрвиш Балтай карт якын-тирә авылдагы балаларның күңелен күтәрергә булган. Өстенә өрәңге ботакларыннан ясалган «тун»ын кигән дә урамда аю булып кыланып йөргән... Мордва мәдәниятенең Татарстанда кадерләп сакланып калган үзенчәлекле бәйрәме – Балтай әнә шуннан башланган, диләр.

Россиядә бүген дә бу бәйрәмне күрергә мөмкин бердәнбер урын – Татарстанның Лениногорск районындагы Мордва Карамалысы. Урал таулары итәгендә урнашкан әлеге борынгы авылның матур итеп бизәлгән урман аланында ел саен, Троицадан соң бер атна үткәч, аллы-гөлле бәйрәм тамашасы уздырыла, халык гореф-гадәтләре яңартыла.

Балтай йоласы нигезендә урман хуҗасы дип саналган аюга хөрмәт күрсәтү, аңа дога кылу күренеше ята. Бу көнне бөтен авыл белән урманга барып, «аю гаиләсе»н – ата белән ана аю һәм аларның баласын киендерү, бизәү гадәткә кергән. Һәр персонажга абагадан баш киеме ясаганнар, аны чәчәкләр белән бизәгәннәр, гәүдәгә исә өрәңге ботаклары бәйләгәннәр. Бәйрәмдә борынгы мордва җырлары башкарылган. «Аюны бизәгәч», нудей дип аталган халык уен коралы көенә «урман хуҗасы»ның бар гаиләсе зур аланга чыккан. Монда «аюлар» тирәсендә әйлән-бәйлән әйләнеп, аларга мул урман сыйлары өчен рәхмәт әйткәннәр. Шунда ук кызыклы халык уеннары башланган, алар арасында иң популяры – күзләрне бәйләгән килеш «кикерок»лар (кечкенә сәс шарлар) җыю.

Аннары бар халык авылга юнәлгән. Алдан исә авылның иң чибәр кызлары баугә тагып җитәкләгән өрәңге «тун»лы «аюлар» барган, алар артыннан, җырлый-җырлый, бәйрәм итүчеләр ияргән. Аларны һәр йортта баш иеп, хөрмәтләп, ипи-тоз, куас, бәлешләр, гомумән, мордва милли кухнясы дан торган бөтен сый-нигъмәтләр белән каршы алганнар.

Бөтен авылны йөреп чыккач, бәйрәмдә катнашучылар «аюлар»ны чишендергән, аларның «туннарыннан» өрәңге ботагын тартып алып, бер-берсенә җилпергә тырышканнар. Риваятьләрдә әйтелгәнчә, никадәр күбрәк җилпесәң, ул кешегә шулкадәр күбрәк сый-муллык биреләчәк икән. «Аюлар» ныграк «ябыга» барган саен, халык куана-шатлана гына. Ә яшьләр һәм балалар бер-берсенә су сибеп уйный. Бу исә мул яңгырлар, димәк, яхшы уңыш символы булып тора. Гаҗәп, ләкин ул төндә яңгыр яумый калмый...

Быел «Балтай» бәйрәме Татарстан Республикасы Лениногорск районы хакимиятенең актив булышлыгында «Карамалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты һәм Мордва Карамалысы авыл мәдәнияты йортының «Пизёлне» фольклор ансамбле тәкъдиме белән республика дәрәҗәсендә үткәрелә. Бәйрәмдә катнашучылар һәм кунаклар исемлегендә Татарстан һәм Самара өлкәсенең фольклор коллективлары да бар.

Барысы да нәкъ моннан күп еллар элеккеге кебек булачак. Мордва милли ризыклары белән тулы өстәлләр куелган зур алан, «аюлар бизәү», аю роленә иң кыю һәм җитез кешене сайларга ярдәм итәчәк «Кикеркай» халык уены... «Аю киендерү» йоласы бәйрәмнең бер бизәге булачак, аннан соң бар халык әйлән-бәйлән әйләнеп, «Кий чиресе репеть видезь» халык җырын башкарачак... Аннан соң Балтайда катнашучылар һәм бәйрәм кунаклары авылга юл тотачак, әлбәттә, иң алдан «аю» барачак. Үзәк урамда аларны җыр-моңнар белән каршы алачаклар, кунакларны куас, милли ризыклар белән сыйлаячаклар. Бәйрәм ахырында «аю»дан ботакларны йолкып, су сибешеп күңел ачу көтә...

Балтай – үзенчәлекле рухын, кабатланмас матурлыгын һәм бары тик аңа гына хас борынгы халык гореф-гадәтләрен саклап калган, тулы мәгънәсендә, аутентик бәйрәм ул. Килегез, үкенмәссез!

Фото «Безнең Лениногорск» Лениногорск шәһәрен үстерү фондыннан алынды. РЕКЛАМА

ЕЛЕНА ВАЛЬЦЕФЕР: «БАРЫ ТИК КҮҢЕЛ ЯТКАН ЭШ БЕЛӘН ГЕНӘ ШӨГЫЛЬЛӘНҮ ЗАРУР. БАЛАЛАРДАН ӨЙРӘНГӘН ТӨП КАГЫЙДӘМ – ШУШЫ»

Остаз булу һәм балаларны нәрсәгә булса да өйрәтү өчен педагогика институтын тәмамлау бер дә мәҗбүри түгел. Беренче чиратта олы йөрәкле кеше булу һәм көн саен бу дөньяны ничек тә яхшыртырга омтылу таләп ителә. Казандагы «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбе җитәкчесе бөтен гомерен үзгәрткән очрак, балалар белән гаҗәеп мавыктыргыч эше һәм киләчәккә планнары турында сөйли.

«МИН БИК ИҖАДИ КЕШЕ ИКӘН!»

– Казанда «Ералаш» мәктәбе ачылгач, ул чакта кино индустриясеннән бөтенләй ерак торган, белемем буенча икътисадчы булган мин фәкыйрегезгә директор вазыйфасын тәкъдим иттеләр. Бәхетле очракка ничек ышанмыйсың ди инде: режиссер миңа биргән кечкенә генә укытучы роле тормышымны икегә бүлде дә куйды.

Ә инде «Ералаш» Казан базарыннан киткән вакытка мин үземне балалар киносы дөньясыннан башка күз алдына да китерә алмый торган кешегә әйләнгән идем. Һәм менә инде 12 ел буе мин үземнең хосусый «ДжуниорЛайф» кино сәнгате мәктәбен җитәклим һәм юмористик «Шкодники» киножурналының продюсеры да булып торам.

«ЭШЧӘНЛЕК ДАИРӘМ – МИНЕМ МИССИЯМ»

– Ул минем тормышымны үзгә бер эчтәлек һәм мәгънәгә генә баетып калмый, бәлки үземне файдалы һәм уңышлы итеп тою мөмкинлеген дә бирә. Әлеге эшемә көн саен бөтен күңелемне, йөрәгемне, вакытымны һәм көчемне биреп, мин искиткеч зур ләззәт алам, мәйданчыкта чын актерлар кебек бирелеп уйнаган йөзләгән баланың сөенечен һәм рәхмәтен тоям. Димәк, минем бурычым нәкъ шундый икән бит – ярдәм күрсәтү, иҗат юлына юнәлтү, талантлар ачу һәм бу дөньяны бераз гына булса да яхшырак итү.

«БАЛАЛАРДАН МИН ТОРМЫШ САБАКЛАРЫ АЛАМ»

– Мин аларны өйрәтәм, ә алар мине: үземне, йөрәгемне, интуициямне тыңларга һәм ишетергә, вак-төяккә дә куанырга һәм бу җиһандагы һәр минутның кадерен белергә өйрәтә. Минем балалардан үзләштергән төп кагыйдәм исә мондый: бәхетле булу өчен, һәрвакыт үзеңә ошаган эш белән генә шөгыльләнергә кирәк. Менә ничек гади бит!

«БАШМА-БАШ...»

– Безнең мөнәсәбәтләрдә җәмгыять тарафыннан көчләп тагылган стереотиплар юк, мин балаларга үзләрен табигый тотарга, кыланмаска рөхсәт итәм, әлбәттә, барысы да әхлак кысаларында инде. Аралашуның бу ысулы үз улымны тәрбияләү тәҗрибәсенә нигезләнә.

Балалар ялганны, икейөзлелекне тиз сизә, шунлыктан үземне алар белән ихтирамлы, ихлас тотарга тырышам. Безнең хәтта язылмаган кагыйдәбез дә бар: «Башма-баш...» – ягъни сез ничек, мин дә шулай.

«ОСТАЗЛАРЫМ – КИТАПЛАР»

– Үзем өчен күп нәрсәне фәлсәфи әдәбияттан алам, ул киңрәк фикер йөртү, гомум кабул ителгән кагыйдәләр кысасыннан чыгу, яшерен мәгънә табу мөмкинлеген бирә. Тарихка чуму, нәфис әдәбият теле белән ләззәтләнү өчен рус классикасын кабат-кабат укырга яратам. Һәм һаман саен гаҗәпләнәм: җәмгыятьтәге кимчелек-җитешсезлекләр үзгәрми, барысы да шундый ук... Интуициям дә мине күп нәрсәгә өйрәтә.

«БАРЫСЫ ДА ТОРМЫШКА АШАРЛЫК!»

– Татарстанда балалар өчен тулы метражлы уен киносын булдыру турында хыялланам. Моның өчен бездә бөтенесе дә бар бит: зур иҗат потенциалына ия тәҗрибәле команда, республикабызның искиткеч гүзәл локацияләре һәм бик талантлы нәни актерларыбыз.

Фото: Екатерина Ежова. РЕКЛАМА

«СӘЛАМӘТЛЕК – ФИЗИК, ПСИХИК ЯКТАН САУ БУЛУ УЛ»

Руфия Фазылова

Табиб. Мөгаллим. Бер караганда, бу ике һөнәр бер-берсеннән ерак кебек. Ләкин аның икесен берьюлы уңышлы алып бара торган кешеләр дә бар. Мин шалтыратканда, Равил Шамил улы Вәлиев Ульяновск өлкәсендә табибларга белем бирә иде, өч көннән исә «Казанская клиника»да авыруларны кабул итте. (Без шунда очраштык.) Кырык елдан артык стажы булган табиб-мөгаллимнең әйтер сүзе күп булып чыкты...

– Равил Шамилевич, медицинага ничек килдегез? Балачак хыялы идеме ул?

– Арчаның беренче мәктәбен тәмамлаганга быел 50 ел. Ике атна элек кенә сыйныфташлар очрашуы булды. Менә шунда сөйләштек: мәктәптә укыганда табиб булам дип йөргәнмен икән.

Әнием 1939 елда шәфкать туташлары мәктәбен тәмамлый. Шуннан соң 1941 елны фронтка китә һәм 1945 елның декабрендә генә туган ягына әйләнеп кайта. Әтисе сугышта һәлак булганга, аны медицина университетына өстенлекле шартларда укырга алалар. Ярты ел укыганнан соң әнигә

Фото: Александр Ефремов

укуын ташларга туры килә. «Мин авырыйм, кызым, авылга кайта алмыйсыңмы?» – ди әнисе. Ул исә каршы килми... «Эх, табиб була алмадым», – дип, әни гомер буе үкенеп яшәде. Күрәсең, минем әнинең хыялын да тормышка ашырасым килгәндер. Аннары, эти ягыннан дәү әтием дә минем табиб булуымны теләде.

Мәктәптә яхшы укыдым, химия-биологияне әйбәт белә идем. Беренче тапкырдан ук Казан дәүләт медицина институтына укырга кердем. Быел илле ел була, гомернең агуы, диген...

– Институтның санитария факультетына кергәнсез икән. Аннан соң исә пульмонология юнәлешен сайлагансыз...

– Язмыш үзе китерде. Институтта яхшы укыдым. Факультетның отличниклар советы председателе идем. Дүртенче курстан Казанның 15 нче хастаханәсендә эшли башладым. Шунда тәҗрибәле табиблар янында күп нәрсәгә өйрәндем: яраларны тектем, хәтта йөрәккә укол да кададым. Институтны тәмамлагач, туган ягым Арчага кайттым. Баш табиб мине үзе чакырды: эшли башлаган чагында аны әни күп нәрсәләргә өйрәткән. Әнинең югары белеме булмаса да, сугышта дүрт ел дәвамында операцияләр ясаганда ярдәм иткәнгә күрә, табиблардан артык белә иде.

Арча хастаханәсендә бер ел эшләгәннән соң, ГИДУВның туберкулез кафедрасына укырга киттем. Ул Биектау районының Каменка авылында иде. Ни өчен ул юнәлеш дигәндә, урын булды. Аннан үземә дә әлеге өлкә ошап китте. Менә шулай итеп кырык елдан артык үпкә авыруларын дәвалыйм.

– Ә мөгаллимлек эшенә ничек кереп киттегез?

– Ординатураны тәмамлагач та, ягъни 1985 елдан фтизиатрия буенча табибларны укыта башладым. Соңрак ул чакта ТР сәламәтлек саклау министры булган Камил Зыятдинов үзе фатыйха бирде дисәм дә була. ГИДУВка бөтен Советлар Союзыннан киләләр иде. Дөресен генә әйткәндә, алар белән үзем дә өйрәндем. Табиблар дәрестә сорау бирә, кайткач бөтен китапларны күтәреп, иртәгәсен ныклап җавапны өйрәнеп киләсең. Мөгаллимлек эше профессиональ яктан үсәргә бик булышты.

Беренчеләрдән булып, туберкулез белән авыручыларның психологиясен өйрәндем. 1989 елда Ленинградта әлеге темага диссертация дә якладым. Табиблык эшен дә ташламадым. 1996 елда Республика туберкулез диспансерының баш табибы итеп билгеләделәр. Хезмәт юлым озын инде...

Бүген дә Россиянең төрле шәһәрләренә барып табибларны укытам. Безнең кафедра данлыклы, абруе зур, шуның өчен дә гел чакырып торалар. География гаять киң: Камчатка, Владивосток, Бурятия, Әстерхан, Кырым, Калмыкия, Кабарда-Балкар, Төньяк Осетия, Чечня... Күрше төбәкләрне санамыйм да. Элек табиблар безгә үзләре килсә, хәзер үзебез барабыз.

– Мөгаллим кешедән сорамый булдыра алмыйм: бүгенге табибларның белем дәрәҗәсе ничек? Кешелеклелек ягыннан теге чор табибларыннан аерылалармы?

– Кызганычка, бүген табибларның белем дәрәҗәсе түбән төште. Элек без диагноз куйган вакытта гади рентген һәм томография ясый идек. УЗИлар юк иде, ләкин дөрес диагноз куйдык. Ә хәзер бер-берсенә сылтап тик утыралар.

Бер мисал: плеврит белән авыручыларга рентгеноскопия, башкасын да үзем ясый идем. Ә хәзер плеврит белән авыручы башта УЗИ, аннан компьютер томографиясенә, аннан бронхоскопиягә бара. Бүгенге көндә инструменталь методлар бик күп, алар заманча, файдалы, ләкин шуларда яхшы эшли белүчеләр сирәк.

Медицинада авыруны дәвалау стандартлары бар. Ләкин стандарт кеше юк бит, шуның өчен әлеге метод күп булса утыз процент кешегә туры килә. Чит илдә күп илләр шәхсиләштерелгән медицина кулланалар. Ә заманында стандарт дәвалауны без чит илдән алдык. Советлар Союзы вакытында бездә дә һәр авыруга шәхсән якын килү бар иде. Үз вакытында остазларыбыз безне шуңа өйрәтте. Мин дә бүген табибларга шуны бирергә тырышам.

– Равил Шамилевич, кызык фикер әйттегез: димәк, әле заманча медицина җиһазлары һәрвакытта да дөрес диагноз куя дигән сүз түгел?

– Ни кызганыч, түгел. Табиб, бөтен тикшерүләрне өйрәнеп, үзе диагноз куярга тиеш. Мисал өчен, компьютер томографиясен дискта мин үзем карыйм, рентгенны да шулай итәм. Әйе, авырулар миңа да язу белән килә. Ләкин бит бу тикшерүләрне берләштерергә, анализлап карарга кирәк. Аннары, рентгенолог ординатурада ике ел укый, функциональ

Равил Шамил улы Вәлиев, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган табибы. Бүгенге көндә Казан дәүләт медицина академиясенең фтизиатрия һәм пульмонология кафедрасы мөдире. 1989 елдан – Казанның, 1996 елдан – Татарстанның, 2014 елдан – Идел буе округының баш фтизиатры.

диагностика өлкәсендә эшләү өчен дә ике ел укыйлар. Шул вакыт эчендә генә яхшы белгеч булып җитешү кыен. Мин элек-электән әйтәм: «Яхшы табиб булу өчен, үзеңә бик күп тырышырга кирәк», – дим. Кайчак яшь табибларга: «Эх, менә минем башка флешка куеп, аннан шуны сезнең башка гына куйсак, ничек рәхәт буласы», – дим. И көлешәләр инде. Бүгенге яшьләр бит мәгълүматны шулай компьютер, интернеттан гына күчереп алырга өйрәнде. Бу бик начар, эзләнмәсәң, көн саен максатчан укымасаң, белгеч була алмыйсың. Хәер, бу табибларга гына кагылмый. Тик медицинада бу аеруча мөһим – сүз кеше гомере турында бара бит.

Тагын бер фикер әйтәсем килә: җиһаз-җайланмалар күп булу сәбәпле, хәзер кеше зарына игътибар кимеде. Табиб карый да әйтә: «Сезнең компьютер томографиясендә зыянлы бернәрсә дә юк, сез сәламәт, барыгыз, мине икенче авыру көтә», – ди. Ә авыруны чынлап та нәрсәдер борчый. Ул хәзер нәрсә эшләсен?! Авыру белән сөйләшү, аларны тыңлау юк... Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы: «Сәламәтлек – физик, психик яктан сау булу ул», – ди. Кайвакыт авыру белән җайлап сөйләшкәч, барысын да бәйнә-бәйнә аңлаткач ук, аның хәле җиңеләйгәндәй була. Ә бүгенге табиблар моны бөтенләй оныта. Хәер, аның икенче ягы да бар – бүген алар һәр авыруны караган саен ун-унбиш кәгазь тутырырга тиеш. Шуның өчен дәүләт сырхауханәләрендә эшләргә кеше калмады. Алты кеше өчен бер табиб эшли! Аның өстенә күпме тикшерү. Сөйләсәң, бу системада акылга сыймаган әйберләр күп.

– Сез – тәҗрибәле пульмонолог. Бу еллар эчендә сез ишетмәгән дә сулыш органнары авырулары барлыкка килдеме?

– Иң беренче ВИЧ авыруы турында әйтәсем килә. Ул үпкә авыруларының узуын тамырдан үзгәртә. Лекцияләрне укыганда да: «ВИЧлы кешеләрдә туберкулез, ВИЧсыз кешеләрдә туберкулез», – дип өйрәтәбез. Әле гепатит та булса, хәл тагын да катлаулана, чөнки бөтен дару бавырдан уза.

Кош гриппы, Эбола вирусы, ковид... – алар чыгып кына тора. Элек, бәлки, без аларга диагноз куя белмәгәнбездер. Ул яктан хәзер ПЦР-диагностикалар барлыкка килде, тиз күрсәтә.

Бүгенге көндә кешенең иммунитеты үзгәрде, чөнки ашый торган ризыкларыбыз файдалы түгел. Инде расланган әйбер: кибет тавыгын ярты сәгать кайнатканнан соң, шулпага кошны үстергәндә кулланылган антибиотикның илле проценты чыга. Тагын ярты сәгать кайнатсаң, йөз проценты чыгып бетә. Шуннан соң тавыкны курыкмыйча ашап була. Ләкин без бит ул шулпага токмач салабыз да аш итеп ашыйбыз. Бүген кошчылык фабрикаларында фторхинолонсыз кош-корт үстермиләр. Хәер, дуңгызга, башка хайваннарның азыкларына да шуны кушалар. Бу ветеринария таләпләреннән чыгып эшләнелә.

Тагын әле кош-корт фабрикаларында үстерү гормоннары да кулланалар. Болары да чын аллерген, иммунитет өчен зарарлы. Менә шуңа күрә дә элек колак ишетмәгән авырулар барлыкка килде. Ул авыру күзәнәкләре организмда, бәлки, элек тә булгандыр, иммунитет какшау аркасында исә, хәзер алар бик тиз үрчеп китә ала.

Бүген яман шеш белән авыручылар саны да бик күпкә артты. Сәбәбе? Элек кешеләр йогышлы чирләрдән үлгән. Күбесе картлыкка кадәр яшәмәгән. Табиблар уенын-чынын кушып еш кына: «Үзеңнең яман шешеңә кадәр яшәргә кирәк әле», – ди. Бу чир башлану организмның начар белән яхшыны аермый башлавын күрсәтә.

Психология белән шөгыльләнгәнгә күрә, күп чирләрнең башы стресс дип курыкмыйча әйтә алам. Андый вакытта кемдәдер яман шеш, кемдәдер шикәр чире, кемдәдер туберкулез башлана. Еш кына, туберкулез чире тәртипсез яшәү рәвеше алып барган кешеләрдә генә була, диген караш яши. Юк, гел алай түгел. Рентген төшкән кәгазьне карыйм да: «Сезнең шикәр чире бармы?» – дим. «Юк», – дисәләр, «Алайса, берәр якын кешегез үлдеме?» - дип сорыйм. Аптырап китәләр: «Ничек белдегез?» – диләр. «Монда барысы да язылган», – дим.

Бүгенге көндә хроник стресс хәлендә яшибез. Дөньядагы вазгыять, башка сәбәпләр кешене гел киеренкелектә тота.

– Равил Шамилевич, ковид турында да сорашмый кала алмыйм. Ул ни дәрәҗәдә безнең организмны, сәламәтлекне үзгәртте?

– Ковид сәламәтлегебезне тулысынча үзгәртте. Барыннан да бигрәк, ул безнең сәламәтлек саклау системасының нинди дәрәҗәдә булуын күрсәтте. Хәер, безнең генә түгел, ә бөтен дөньяныкын. Мондый массакүләм авыруга без әзер түгел идек. Шуның белән бәйле бик күп ялгышлыклар булды. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы бүгенге көндә яшермичә әйтә: ковидтан үлгән кешеләрнең алтмыш процентын алып калып була иде. ИВЛ аппаратына куйганнан соң, авыруларның күбесендә икенчел бактериаль пневмония башланды. Кирәкме, түгелме – бөтен кешегә антибиотик яздылар. Ә вирустан бүгенге көндә бер антибиотик та булышмый. Ковидтан гына түгел, гомумән вирустан. Сер түгел, ковидтан дәвалаганда аерым төр препаратлар белән акча да эшләделәр. Ярар, монысы бүтән тема...

Кызганычка, ковидтан соң сәламәтлек нык какшый. Әле хәзер дә шуның белән мөрәҗәгать итүчеләр күп. Үпкә, йөрәктә үзгәрешләр була, чәч коела, тын бетә, хәтер югала... Әгәр бу симптомнар һаман борчыса, табибка күренергә кирәк.

– Үпкәдә проблема бар икәнлеген ничек белергә? Ул берәр ничек сиздерәме?

– Үпкә һәм бронхлар бар. Компьютер томографиясе яман шеш, туберкулез, пневмония барлыгын күрсәтә. Ә менә бронхлардагы шул ук астманы компьютер томографиясе күрсәтми. Бүген үпкә, бронхларны тикшерү өчен бөтен төр аппаратлар да бар, проблема түгел. Табиб, авыруны бер кат тикшергәннән соң, төгәл диагноз кую өчен әнә шуларның берсенә җибәрә.

Ел саен флюорография узу мәҗбүри дияр идем. Ул күп проблемаларны булдырмаска ярдәм итә. Өстәвенә, хәзерге цифрлы флюорография аппаратлары бик кечкенә күләмдә нурланыш бирә. Кеше сәламәтлегенә өчен рөхсәт ителгән нурланыш шкаласы буенча карасаң, елга ун тапкыр флюорография ясатсаң да, зыяны булмый.

– Равил Шамилевич, Советлар Союзында туберкулез диспансерлары бик көчле эшләде. Бүген дә ул система сакландымы?

– Советлар Союзында булган система сакланды. Ләкин диспансерларның эшләре бик нык үзгәрде. Мин эшләгән Каменкадагы хастаханә бик иске, бер палатада тугызар кеше ята иде. Ә алар анда айлар буе ятарга тиеш. Бүген авыруларны андый шартларда дәваларга ярамый: хастаханәләргә карата контроль зур, берничә оешмадан рөхсәт кәгазе алырга кирәк. Шуның өчен дә диспансерларны берләштерергә, бик начарларын ябарга туры килде. Хәзерге туберкулез диспансерлары заманча, һәркайсында компьютер томографлары, башкасы бар.

Бүгенге көндә туберкулез белән көрәшүнең төп проблемасы – дәвалауны контрольдә тотып булмый. Туберкулезны озак дәваларга кирәк. Кеше дару эчеп туя, аннан кул селти. Димәк, аннан авыруга көчлерәк дарулар бирәсе була. Мәсәлән, башлангыч этапта туберкулезны тугыз айга кадәр дәваласак, көчәйсә, ике елга кадәр кирәк. Ә еллар буе кеше дару эчәме? Юк. Шуның өчен дә медицина белгече, көн саен өйләренә барып, аларны тикшереп торырга тиеш. Ә аның өчен акча каралмаган. Мин бу турыда әйтеп карадым, әмма ишетүче булмады.

– Үпкә сәламәтлеге өчен нәрсә файдалы, нәрсә зыянлы?

– Башта зыян турында әйтим. Әлбәттә, беренче урында тәмәке, вейплар тарту тора. Аларның зарары шулкадәр зур ки, ул турыдан-туры гомер озынлыгына тәэсир итә. Йөз градус эссе булган сауналар да үпкәгә зарарлы. Гадәттә без сиксән биш градустан арттырмаска киңәш итәбез.

Нәрсә файдалы дигәндә – йөрү. Яшь вакытта йөгерергә киңәш итәбез, ә менә олыгая-олыгая кешенең буыннары авырта башлый, димәк, бу киресенчә зыянлы булырга мөмкин. Көненә биш-җиде чакрым җәяү йөрү әйбәт санала. Ул йөрәк эшчәнлеге, сулыш юллары өчен бик файдалы. Шулай ук җәяү йөрү гәүдә төзлеге өчен дә яхшы.

Картайган көндә сәламәтлекне кире кайтарып булмый. Шуның өчен сәламәтлекне яшьтән сакларга кирәк. Шул очракта гына картлык бәхетле була ала.

Россия Федерациясе
Авыл хуҗалыгы министрлыгы
БӨТЕНРОССИЯ
кыр көне
2023
10-й открытый чемпионат России по пахоте 2023
«Казан Экспо»
Халыкара күргәзмәләр үзәге
6–9 июль
Татарстан Республикасы,
Лаеш районы,
Олы Кабан авылы
ЭЛЕМТӘ ӨЧЕН:
Күргәзмә адресы: Татарстан Республикасы,
Лаеш районы, Олы Кабан авылы,
Выставочная ур., 1
КҮРГӘЗМӘ ОПЕРАТОРЫ:
«Хорда» ҖЧҖ, 123056, Мәскәү ш.,
Электр тыкрыгы, 12
Катнашу сораулары буенча:
+7 (495) 240-92-26
russian-field-day.ru
info@russian-field-day.ru
Реклама, 16+

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Хәтирә Мәрдәншина
Бөек Ватан сугышы солдатларын **ничек** таба

Наталья Авдеева
үзенчәлекле балаларга **ничек** ярдәм итә

Хөсәен Ямашев
кем булган

Кармыш авылында **ничек** яшиләр

Хәтирә Мансур кызы эзләнүләр белән 16 елдан артык шөгыльләнә.



Инна Богуславская «Каравон» коллективына озын гомер тели.

Фотолар махсус проектта катнашучыларның архивыннан

Наталья Авдеева нәниләр белән дәресләр алып бара. Алар хәрәкәтне, сөйләмне аңлауны, кабул итүне үстерүгә юнәлдерелгән.

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН

ҺӘМ ЭШЛӘҮЧЕ БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп алга атлаучы, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылучы кешеләр бар. Алар юллар сала, күперләр төзи. Балаларны, аларның укытучыларын өйрәтә. Арабызда Бөек Ватан сугышы солдатларын табарга ярдәм итүчеләр дә яши. Сәламәтлек ягыннан үзенчәлекле балаларның тормышын кызыклырак итәргә булышучы фидакарь затлар да бар.

«Татарстан» үз укучыларын шундый якташларыбыз, аларның могҗизага тиң эшчәнлекләре белән таныштыруны дәвам итә.

Элеккеге тарихларны «Татарстан» журналында укыгыз: 2022 елның 10–12 нче саннары, 2023 елның 1-2 саннары.

12 нче ТАРИХ
Хәтирә Мәрдәншина ничек Бөек Ватан сугышы солдатларын кайтарырга булыша

13 нче ТАРИХ
Инна Богуславская ничек Татарстан мәгариф системасы җитәкчеләренең берничә буынын үстерә

14 нче ТАРИХ
Наталья Авдеева үзенчәлекле балаларга ничек йолдыз булырга ярдәм итә

12 НЧЕ ТАРИХ

МӘҢГЕЛЕКТӘН КАЙТКАННАР

Хәтирә Мансур кызы Мәрдәншина лаеклы ялда, әмма аның ял итәргә вакыты юк. Ул төннәр буе эзләнү сайтлары һәм форумнарында утыра һәм эзли дә эзли... Бөек Ватан сугышы кырларыннан кайтмаганнарны эзли ул. Әлегә кадәр туганнары эзләп тә таба алмаганнарны таба. Аннары солдатның туганнары белән бергә җирләнгән урыннарга бара, сугышчының исемен обелискларда, туганнар каберлекләрендә, «Хәтер китабы»нда мәңгеләштерүгә ирешә. Шул ук вакытта ул бернинди дә рәсми эзләнү оешмаларында тормый. «Бу минем шәхси карарым, тормыш рәвешем, – ди Хәтирә Мансур кызы. – Минем хезмәтем безгә яшәү бүләк иткән, шатланырга, матур гамәлләр кылырга, нәселебезне дәвам итәргә мөмкинлек биргән бабаларыбыз өчен эшли алган эшләрнең бик аз өлеше генә».

ДӨРЕС ЯЗЫЛМАГАН

– Әниемнең ике абыйсы сугыштан кайтмаган. 2008 елда олы абыйсын таптык. Үзем эзли башлаганчы, 65 ел дәвамында безгә: «Мәгълүмат юк, хәбәрсез югалган», – дип җавап бирә килделәр. Тик ул югалмаган. Ул 1943 елның мартында Курск дугасында һәлак булган. Аның исеме дөрес язылмаган булган, шуңа күрә без аны шулкадәр озак таба алмаганбыз. Мин Әхмәтшин Нашир Мөхазаловичның (писарь шулай язган) 1906 елда туган Әхмәтшин Әхмәткәшиф Мөфаздалович (Кәшиф – аны туганнары шулай дип атаган) булуын исбатладым. Һәм аның исемен туганнар каберлегендә мәңгеләштерүгә ирештем.

Ачыкланганча, әниемнең абыйсы 69 нчы укчы дивизиясенең Аерым чаңгы батальонында кызылармеец-укчы булган һәм 1943 елның 2 мартында Орел өлкәсенең Дмитровск районы Топоричный поселогы өчен сугышта үлгән.

Орел өлкәсенең Дмитровск-Орловск шәһәрендә дүрт мәртәбә аның каберендә булдым. Ул вакытта каберлектә 175 солдат җирләнгән дип санала иде. Хәзер мин тапкан мәгълүматларга таянып, каберлеккә куелган плитәгә меңнән артык исем язылды. Исемлекне шәһәр администрациясенә тапшырдым. Күз алдына китерәсезме, тагын күпме солдат «сугыштан кайтты»!

ЭЗЛӘҮДӘ ТӨП ПРОБЛЕМА

Эзләүдә төп проблема солдат турында баштан ук дөрес язылмаган мәгълүмат. Хата фами-

Фотолар: Анна Арахамия, Хәтирә Мәрдәншина архивыннан

лия, исем, атасының исеме, хәтта туган урыны язылышында китәргә мөмкин. Татарлардагы иске исемнәр, бигрәк тә авыл кешесенең исеме, еш кына башка халыкларга әйтү өчен авыррак, шуңа күрә аны теләсә кем – полкташларыннан алып дөрес яза белмәгән писарьларга кадәр – барысы да җиңелләштергән. Нәтиҗәдә кешеләр туганнарын еллар буе таба алмый, ә аның исем-фамилиясе бөтенләй башка яңгыраш алган булып чыга: Киситдинов-Кизитдинов-Низитдинов... Голезетен-Гелаземин-Гелазетен...

БЕР САПЕР ТАРИХЫ

Бер кызыклы тарих «туган урынын ачыкларга булышыгыз» дигән үтенечтән башланып китте.

ФАДЕЕВ Григорий Халилулаевич (1920–1942), Үзәк фронтның (1 нче формирование) Гаскәр тылын саклау идарәсе СССР НКВД гаскәрләренең Кызыл Байраклы 17 нче Брест чик буе отряды саперы, нацист лагерьлары тоткыны, кызылармияче.
1920 елның 15 гыйнварында Татарстанда элеккеге Шөгер районы Кәркәле-Теркмак авылында туган. Татар. Православие динендә. 1941 елның җәенә туганнары: әтисе Хәлилула Фәрфетдинов; улы туган урында яшәгән.
Совет хәрби әсиренең лагерьдагы персональ картасына (ОМҮА: Ф.58, оп. 977520, 2264) караганда, 1941 елның 18 августында Белоруссиянең Рогачев шәһәре тирәсендә әсирлеккә эләгә.
Көнбатыш Пруссиянең Торн шәһәрендә (хәзер – Польшаның Торунь шәһәре) урнашкан шталаг-20Ц (шул ук – 312) лагеренда тоткынлыкта була. Лагерь номеры – 9673.
1941 елның 22, 27 сентябрендә һәм 7 октябрендә тиф һәм паратифка каршы вакцина ясала. 1942 елның 1 апрелендә хәрби әсир Г.Х. Фадеевка «үпкә туберкулезы» диагнозы куела. 1942 елның 18 октябрендә шталаг-20Ц (шул ук – 312) лазаретында вафат була. Лагерь табибы язган язуга караганда, үлеменең сәбәбе – үпкә туберкулезы.
Хәзерге вакытта, мөгаен, аның җәсәде Польшаның Торунь шәһәре тирәсендәге Глинки бистәсендә урнашкан хәрби зираттадыр.
«Чик сакчылары Хәтер китабы»нда һәм «Татарстан Республикасы Хәтер китабы»нда исем-фамилиясе күрсәтелмәгән.

Үтенечкә, Шөгер – хәзерге вакытта Татарстанның Лениногорск районы, дип җавап бирдем. Ләкин сугышчының беркайда да исәпләнмәве миңа тынгылык бирмәде. Һәм мин «Мемориал»ның гомумиләштерелгән мәгълүмат банкы»нда мөмкин булган барлык вариантларны карарга уйладым һәм параллель рәвештә авыл Советына шалтыраттым.

Гомумиләштерелгән банкта түбәндәге мәгълүматны таба алдым:

Фамилиясе: Фәрхетдинов
Атасының исеме: Хәлиулла
Туган көне: __.__.1920
Чакырылу датасы һәм урыны: 17.01.1940, Шөгер РХК, ТАССР, Шөгер районы

Хәтирә Мәрдәншинаның эзләнү эшләре белән шөгыльләнә башлавына 16 елдан артык. Шушы еллар эчендә күпме солдатны тапкандыр – санамаган. Меңнән артык, ди героинябыз үзе. 2011 елда Россия Оборона министрлыгының «Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар һәм хәбәрсез югалганнар турында хәтерне мәңгеләштергән өчен» медале белән бүләкләнгән.

Хәрби званиесе: кызылармияче
Исемлектән чыгарылу сәбәбе: хәбәрсез югалган
Чыгарылу көне: _.12.1941
Мәгълүмат чыганагы: ОМҮА

Авыл Советында архивларны күтәрделәр һәм мондый гаилә яшәгәнен әйттеләр. Гаиләдә өч туган үскән. Ир туганнарның берсе сугышта һәлак булган, ә аның кызы исән икән. Мин ул ханымның адресын һәм телефонын таптым. Аның улы да Брест шәһәрендә хезмәт иткән һәм хәбәрсез югалган туганы турында мәгълүмат эзләгән, ләкин таба алмаган.

Менә сезгә сугышчыны табу катлаулы, ләкин мөмкин хәл булуына мисал. Туганнары гомер буе Фәрхетдиновны эзли, ә әсирлектәге сугышчы Фадеев фамилиясе белән вафат була. Ни өчен солдат исем-фамилиясен үзгәрткән? Моның турында фаразларга гына кала. Бәлки, әсирлеккә эләккәнгә, туганнары өчен борчылып, чын исемен яшерергә тырышкандыр. Ләкин әтисенең исемен һәм өй адресын дөрес итеп калдырган – менә шул мәгълүмат эз алырга ярдәм итте дә. Өстәвенә, хәрби әсирнең шәхси карточкасында фотосы да бар.

Мин бу мәгълүматларны «Татарстан Республикасы Хәтер китабы» редакциясенә тапшырдым һәм ул 27 нче, өстәмә томга керде.

Ләкин иң мөһиме: тагын бер солдат «өенә кайтты»!

МӘХӘББӘТ АҢЛАТУ

Кайвакыт солдатны табарга ярдәм иткән кешеләр миңа мәхәббәтләрен дә аңлата. Менә Абдолла Дастановтан шундый хат алдым:

«Хатирә, мин Сезне гомерем буе яратачакмын! Чөнки сез миңа бабам – Самарзаев Астанның кайда күмелгән булуын таптыгыз – әбиемнең исеме Рысбикә иде! Сезгә рәхмәтемне ничек

– Абдолла улы белән, Ленинград өлкәсенә барып, Ленинград фронтының 128 нче укчы дивизиясендә сугышкан, 1943 елның 14 гыйнварында Ленинград өлкәсенең Мгинский районы тирәсендә һәлак булган Самурзаев Дастанның каберен күреп кайтты.

житкерергә белмим! Бабамның дөрес фамилиясе Самурзаев Дастан булырга тиеш. Миңа хәзер, мөгаен, Ленинград өлкәсенә мөрәҗәгать итәргә кирәктер».

«Рәхмәт Сезгә! Барлык туганнарым шатлана һәм Сезгә рәхмәт әйтә! Сезгә Җир йөзендәге барлык изгелекләрне генә телим!»

Мондый сүзләрдән соң тагын да күбрәк эшлисе килә. Чөнки мин башкарган эш кемнәргәдер зур шатлык китерә.

Абдолла – Казахстаннан, ул журналист. Ул безнең kremnik.ru сайтында бабасын эзләгән һәм бер елдан соң гына миңа мөрәҗәгать итте. Мин аның бабасын таптым (шулай ук исеме дөрес язылмаган иде), һәм менә инде Абдулла улы белән, Ленинград өлкәсенә барып, Ленинград фронтының 128 нче укчы дивизиясендә сугышкан, 1943 елның 14 гыйнварында Ленинград өлкәсенең Мгинский районы тирәсендә һәлак булган Самурзаев Дастанның каберен күреп кайтты. Ул шунда ук дивизиянең уртак каберлегендә җирләнгән.

БАБАМ ӨЧЕН РӘХМӘТ

Ислам Кәлимуллинның туганнары белән мин 2017 елда, Вязьмага барып, күмү эшләрендә катнашып кайттым. Моңа сайттагы шундый хәбәр этәргеч бирде:

> КӘЛИМУЛЛИН Ислам Кәлимулла улы, 1917 елгы, ТАССР, Биектау районы, Коркачык авылында туган. Гәүдәсе Смоленск өлкәсендә табылган. Шәхес медальон буенча ачыкланган. Туганнарын эзлибез!
> 1946 елда әнисе эзләткән.

Миңа солдатның оныгы – Миләүшә Имамованы (Ермакова) табарга насыйп булды. Ул, сүз уңаеннан, Татарстанның атказанган артисты.

«Бабам турында хәтер Вязьма җирендә мәңгеләштерелде, – дип язды Миләүшә эзләнү сайтында. – Бабам җирләнгән туганнар каберлеге безнең өчен изге урынга әверелер. Бабам турында хәтер һәм бәһаләп бетергесез хезмәтегез өчен бик зур рәхмәт! Сезнең алда баш иябез!»

Кәлимуллин Ислам Кәлимулла улы.





БАРЫСЫН ДА ЙӨРӘГЕМ АША ҮТКӘРӘМ

Эзләнүчеләр медальон буенча табылган сугышчының туганнарын эзли. Медальонда солдатның фамилиясе һәм туган авылының исеме генә сакланып калган. Карта буенча шундый исемгә охшаш торак пунктны табам. Телефон аша берәрсе белән элемтәгә кереп булмасмы дип тырышам. «09» белешмә бирми, ләкин озак вакыт үгетләгәннән соң, оператор кызганды, күрәсең, беренче өч санны әйтте. Калганнарын очраклы рәвештә җыйсагыз гына инде, диде. Җыйдым, бер ханым җавап бирде. Хәлне аңлатам: шундый авылдан һәлак булган солдатның туганнарын эзлим, фамилиясен атыйм. «Көтегез, хәзер чакырам», – дигән җавап ишетәм. Мин күрше авылдагы тегермәнгә эләккәнмен икән, нәкъ шул чакта теге солдатка туган тиешле кеше тегермәнгә килгән! Бу могҗиза түгелмени?!

Мисаллар күп. Аларның барысын да йөрәгем аша үткәрәм.

Табылган исемнәрне принтерда бастырып чыгардым һәм «Хәтер китабы» редакциясенә илттем. Ничектер бер тапкыр санадым: бер ай эчендә 100ләп сугышчы турында мәгълүмат тупланган. Бу бер ай эчендә генә! Ә 16 елдан артык вакыт эчендә күпме булгандыр. Санамыйм да. Иң мөһиме – солдатны кайтару.

Хәер, кайвакыт табылган солдат белән кызыксынмаган, бу аларга кирәк булмаган кешеләр дә очрый. Солдат өчен рәнҗеп, атна буе елаган чакларым да бар. Мөмкинлегем булса, барлык каберлекләргә үзем барыр, күчереп күмүләрдә катнашыр идем. Әмма шатлык һәм кайгы яшьләре кушылган мизгелләр күбрәк. Кайчак шулай елашып утырабыз: бер якта – мин, таба алганыма сөенеп, икенче якта – табылучының туганнары, табылганга, солдатның каберен барып күрү мөмкинлеге өчен чиксез дулкынланудан.

Мондый уңышлы эшләрдән соң атна буе очып кына йөрисең.

ӘЛЕ КИЧӘ ГЕНӘ ТАБЫЛДЫ

Кичә генә бер сугышчы – Мәүләвиев Зиннур Мәүләви улын таптым. Ул кәгазьдә Алексей Степанович итеп күрсәтелгән, иптәшләре аны шулай атаган. Шул исем белән ул Белоруссиянең Витебск өлкәсе Сенно шәһәрендәге туганнар каберлегендә җирләнгән. Үзе ТАССРның, Чаллы районы Муз.Завод авылында туган булган. Хәзер туганнары аның кайда күмелгәнен белә һәм күрә ала.

ХАТЫН-КЫЗНЫ ТҮГЕЛ, ИР-АТНЫ ЭЗЛӘГЕЗ

Бервакыт «Одноклассники»да бер солдатның оныгы Наталья Арепьевадан хат алдым:

«Хәерле көн, Хәтирә!

Купров Шәми Камал улы.

Мин бабамны, әниемнең әтисен эзлим. Хәбәрсез югалган. Базада мин аны таптым. Аның кайда булуы турында берни хәбәр дә юк...

Бәлки, сез ярдәм итә алырсыз? Алдан ук чын күңелдән рәхмәтемне белдерәм!

Бабайдан калган бердәнбер нәрсә – аның соңгы хаты, анысын да тәрҗемә итә алмыйбыз (хат гарәп хәрефләре белән язылган – редиск.)».

Солдатның исеме Купров Шәми Камал улы була. Эзли торгач, төрле кешеләргә юлыктым, алар барысы да туган көннәре, авыллары һәм сугышка чакырылу урыннары буенча берләштерелде. Башта... хатын-кыз – Купрова Шәми Камал кызы табылды. Аннары – Купров Шәмшетдин Камалетдин улы. Шундый ук мәгълүмат белән. Ләкин бу Купровларның барысының да авыл исеме дөрес язылмаган иде. Безнең өчен бик гади булган татар авылы исеме кем өчендер әйтелеш ягыннан катлаулы булган, күрәсең: «Татарская АССР, Дрожжановский р-н, д., Тат.-Бездна, с. Татбизна».

Һәм менә бар мәгълүмат бергә җыелгач, солдат табылды! Ул югалмаган, ул һәлак булган. Украина җирендә җирләнгән.

Оныгы Наталья болай дип җавап бирде:

«Сезнең алда баш иябез!!! Сүзләр җитми, куллар калтырый... Шунысы кызганыч: хәзер Украинага барып булмый. Әниемә 85 яшь... Аңа әйтергә куркып торам, ә әйтергә кирәк.

Без чиксез бәхетле! Без хыялланырга да кыймаган могҗизаны Сез эшләдегез!»

Сүз уңаеннан, Натальяның әнисе, 85 яшьлек «сугыш чоры баласы» Маһирә Шамил кызы Матушкина, Россия Президентына әтисез үткән балачагы турында хат яза. Әтисе Купров Шәми кызы Маһирәгә 6 яшь булганда сугышка китә һәм 1943 елда хәбәрсез югала. Һәм күпме еллар аны таба алмыйлар. Бу турыда vsebudet.art сайтында болай дип язылган:

«Маһирә гомере буе хәрби ведомстволарга запрослар җибәрә: сугышчы Купровның кайда һәлак булуын һәм күмелүен табарга тели. Әмма эзләнүләр һәрчак уңышсыз тәмамлана. Хәбәрсез югалган солдатның кызы өчен Оборона министрлыгында мәгълүмат булмый, гәрчә ул Гречкодан башлап Ивановка кадәр – һәр яңа министрга мөрәҗәгать итсә дә. Маһирә министрларны җавапсызлыклары һәм битарафлыклары өчен битәрли. Ә менә узган ел әтисенең җирләнгән урынын тапкан өчен рәхмәтен белдерә – моны Казан волонтеры (Хәтирә – редиск.) эшли, аңа сугышчының кызы Маһирә Шамил кызы мөрәҗәгать иткән була. Архивта озак эзләнүләрдән соң ул шундый мәгълүматны таба.

«Исемлектән чыгарылу сәбәбе: үлем. Чыгарылу датасы: 28.11.1943. Беренчел җирләү урыны: Украина ССР, Запорожье өлкәсе, Больше-Белозерский районы, Незаможное авылы, көньяк-көнбатыштарак, 500 м, сулдан уңга 4 нче».

Маһирәнең әтисе хәбәрсез югалмаган, һәлак булган».

Күпләр солдатларны табуда Хәтирәгә Аллаһы Тәгалә ярдәм итә дип саный. Ә, бәлки, әниседер? Ул кызына хәтер сүзеннән алынган Хәтирә исемен кушкан бит...

ДӨРЕС ИСЕМ

Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 80 елга якын вакыт узган. Ләкин солдатлар әле һаман да табыла тора, аларның исемнәре кайта, билгесезлектән чыгарыла. Ләкин елдан-ел азрак. Вакыт – аяусыз. Медальон табылган очракта да, ул еш кына укырлык хәлдә булмый.

Ләкин мин эзләнүләремне дәвам итәм. Эшнең иге-чиге юк. «Мемориал» гомумиләштерелгән мәгълүмат банкы» белән хезмәттәшлек үз нәтиҗәләрен бирә, чөнки күпләр писарь җибәргән хата аркасында гына югалган булып санала.

НИЧЕК ЭЗЛӘРГӘ, КАЙДАН БАШЛАРГА:

Башта «Мемориал» гомумиләштерелгән мәгълүмат банкы» һәм www.kremnik.ru. сайтларыннан карагыз, ЗАГСның Республика архивыннан үлем турында белешмә соратып була. Әгәр анда булмаса, солдатның фронтка чакырылган яки киткән урыныннан башларга кирәк. Авыл советларына шалтыратыгыз, «Хуҗалык китаплары»н күтәрүне сорагыз. Картлардан белешегез. Кайвакыт 30–40 тапкыр шалтыратырга, шәһәрара, халыкара шалтыратулар ясарга туры килә. Ләкин ярдәм итү мөһимрәк. Миндә андый мисаллар күп. Татарстан, Россия төбәкләре, элеккеге СССР буенча эшлим.

ИСЕМ-ФАМИЛИЯНЕҢ ДӨРЕС ТҮГЕЛЛЕГЕН НИЧЕК АҢЛАРГА:

Әгәр дә эзләнү сайтларында сугышчының исеме табылмаса, охшашларны эзләп карагыз: исем-фамилияләр, туган яки фронтка чакырылган урыннар. Төрле вариантларны тикшерегез: эзләү тәрәзәсенә фамилия, исем яки беренче өч-дүрт хәрефне генә кертегез. Кешенең туган, яшәгән, укыган урыннарын, хәрби карточкада аның туганнарын карагыз. Әгәр солдат карточкасында хатыны, әти-әнисе турында, тагын шундый берәр мәгълүмат туры килә икән, бу без эзләгән кеше булачак.

– Ислам Кәлимуллинның туганнары белән Вязьмага барып, күмү эшләрендә катнашып кайттым.

13 НЧЕ ТАРИХ

МӨГАЛЛИМНӘР ОСТАЗЫ

Ксения Сёмина

Инна Богуславская бала чагыннан укытучы булырга хыяллана. Хыялы икеләтә чынга аша: Инна Григорьевна 50 еллык хезмәт дәверендә Татарстанның мәгариф системасына берничә буын җитәкче үстереп бирә.

«Зинһар өчен, миңа элеккеге кебек «син» дип дәшегез», – дип мөрәҗәгать итә Инна Григорьевнага Татарстан хакимиятенең хөрмәткә лаек бер вәкиле. Кайчандыр Казан мәктәпләренең берсендә директор булып эшләгәндә, ул Богуславская җитәкчелегендә республиканың Мәгарифне үстерү институтында квалификация күтәрү курсларын үткән. Еллар узган, әмма күренекле җитәкче бүген дә, башка бик күп актив, популяр, алдынгы җитәкчеләр кебек үк, Инна Богуславскаяны дөрес юл сайларга ярдәм иткән остаз дип саный.

БӨТЕН СЫЙНЫФ БЕЛӘН – ЧИТ ТЕЛЛӘР ФАКУЛЬТЕТЫНА!

Безнең героебыз өчен әлеге юл гади генә башланып китмәгән. «Дәваланыгыз, аннан соң килерсез», – ди кабул итү комиссиясе рәисе документларын Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына алып килгән Иннага. Рәсми кабул итү көнендә килә алмый ул – сукыр эчәк өянәге белән хастаханәгә эләгә. Әмма укырга керергә кирәк, югыйсә туган ягына – Украинага, Кировоградка кайтып китәргә туры киләчәк. Ә кайтасы килми – укырга керсен өчен, әти-әнисе мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган кызны сөйгән яры белән ярәшүдән баш тартырга мәҗбүр иткән. Сагышланып утырасы килми, алга таба яшисе, Ленин исемен йөрткән иң яхшы университетта укыйсы килә. Инна кабул итү комиссиясенә шулай дип әйтә. Документларын кабул итәләр, имтиханнар тапшырырга рөхсәт бирәләр. Һәм Инна аларны уңышлы тапшыра.

Сиңа егерме яшь кенә булганда, язмыш сынаулары вакытлыча гына булып тоела, киртәләрне сикереп чыгасың да алга атлыйсың. Провинциядән килгәнлегеңне күрсәтеп торган «г» авазын бетерергә кирәкме? Тырыша! Бер үк вакытта эшләп укыргамы? Анысына да җиңел иялләшә. Һәм менә инде дүртенче курс студенты Инна Богуславская Югары Ослан районының Шеланга авылында инглиз теле укыта.

Фотолар Инна Богуславская архивыннан

«Табигый сәләт». Инна Шеланга кибетендә тапкан басмалар арасындагы бер китап шулай дип атала. Авторы – Зинаида Михайлова Казан мәктәпләренең берсендә укытучы Гөл Җәмилева турында язган. Китапның исеме дә, героеның исеме дә Иннага таныш түгел. Ә күпмедер вакыт үтүгә, педагогика героинябызның яраткан хезмәтенә әйләнәчәк, ә Гөл Җәмилева белән алар бик күп проектларны бергә эшләячәк, җан дусларга әйләнәчәк.

Әлегә шат күңелле, көче ташып торган Инна үзенең укучыларына яңадан-яңа күнегүләр уйлап чыгара. Уеннар, рольләргә бүленеп укулар, табышмаклар, кызыклы тарихлар. Хезмәт һәм иҗатка чумып эшләгән ел сизелмичә дә узып китә. Әмма укучылар күңелендә гомерлеккә уелып кала. «Сез мине хәтерлисезме? – бик күп еллар узгач, Казанда уза торган август киңәшмәсендә бер укучысы Инна Богуславскаяга шулай дип килә. – Сез безгә Шелангада инглиз теле укыткан идегез. Ә без шуннан соң бөтен сыйныфыбыз белән чит телләр факультетына укырга керергә җыендык!»

ДИРЕКТОР ҖЫРЛАРГА ДА, БИЕРГӘ ДӘ ТИЕШ

Яшь Лермонтовка Пушкиннан соң шигъри үрләр яулау җиңел бирелми. Әмма аның сайлау мөмкинлеге булмый бит. Безнең героебыз Татарстан укытучылар белемен камилләштерү институтына эстетик тәрбия буенча методист вазифасына дәгъва иткәндә, әлеге эшкә биш кеше кандидатурасы каралуы турында әйткәч, шул исенә төшә. Өч ай буенча эшсез көтә ул бу вазифаны. Бу вакытта Казанда апасында яшәп тора. Инде туган ягына кайтып китәргә билет алам дигәндә генә, институттан хәбәр килә: аны сайлаганнар. Инна институтта эшләп калырга риза була. Чынлыкта гомер буена калырга язган икән.

Инна Богуславская – педагогика фәннәре кандидаты, доцент, РФ һәм ТРның атказанган укытучысы, ТРның халык укытучысы, ТРның мактаулы остазы.

Татарстан укытучылар белемен камилләштерү институты. Башлангыч мәктәптә тәрбия проблемалары темасына сөйләшү. 1982 ел.

«Ә сез җырлый беләсезме? Ә бии беләсезме?» – дип сорый Инна Богуславская педагоглардан. 1970 нче елларда була бу хәл. Татарстан укытучылар белемен камилләштерү институтыннан методист буларак Инна Богуславская һәм Яр Чаллының мәгариф бүлеге мөдире Хәмит Рәхмәтуллин шәһәрдә бер-бер артлы төзелгән мәктәпләргә директор вазифасына кандидатлар сайлый. «Акылдан яздыңмы әллә? Нинди җырлау ди ул? Эш болай да муеннан!» – дип пышылдый Инна Григорьевнага Хәмит Абдрахман улы. Әмма безнең героебыз нәрсә эшләгәнен белә – кеше җырлый, бии икән, димәк, аның көче ташып тора, димәк,



Иҗат эше педагогларны артистлар белән берләштерә. Инна Богуславская яраткан «Каравон» коллективына, шул исемдәге бәйрәмгә һәм бәйрәм хөрмәтенә Русское Никольское авылында (ТР, Лаеш районы) ачылган музейга уңышлар теле. 2017 ел.

Татарстан Республикасының халык укытучысы. Бүләкләү тантанасы. 2017 ел.

яшь шәһәрнең яңа мәктәпләрендәге эш күләмен дә ерып чыга алачак.

Мәгариф иҗатсыз булмый. Инна Григорьевна бөтен эшендә дә шушы принципка таяна. Гөл Хан кызы белән алар иҗат итә – Татарстан өчен педагоглар тәрбияләү буенча яңа методикалар эшли. Шул рәвешле стажировкалар барлыкка килә: тыңлаучылар лекцияләрдә ишеткән материалларын практикада ныгыта, өч көн сыйныфтан тыш эш буенча директор урынбасары булып эшли, оештыру эшләренең үзенчәлеген бөтен мәктәп җәмәгатьчелеге белән бергә өйрәнә. Элеккеге Татарстан укытучылар белемен камилләштерү институты – хәзерге Мәгарифне үстерү институтында мәгарифнең популярлыгы арта. Казан методистлары республика районнары буйлап йөри башлый. 1980 нче еллар ахырына Инна Богуславская барлык районнарны да йөреп чыга диярлек.

«МӘКТӘП – ТОРМЫШ» ТАНДЕМЫНДА

Картинаны тулаем һәм аерым детальләрдә күрә белү сәләте, вазгыятьне алдан күрүчәнлеге безнең героебызга 1980 нче елларда ук яңа программалар эшләү мөмкинлеге бирә, гәрчә андый программалар һәм алимнар турында федераль дәрәҗәдә 2020 нче елларда гына сөйли башласалар да. Мәгарифнең максаты – балага белем бирү генә түгел, ә ул белемнәрнең чын тормыштагы ролен аңлату да. Әлеге идеягә таянып, Инна Богуславская һәм Гөл Җәмилева авторлык курслары эшлиләр. Ул курсларда авторлар мәктәп белән тормыш арасын якынайталар, педагогларга тормышны мәктәпкә, мәктәпне тормышка алып керергә өйрәтәләр. Мәктәп авылда булса да, анда 45 кенә бала укыса да... Хакимият җитәкчеләре, авыл хуҗалыгы предприятиеләре директорлары, табиблар, төзүчеләр, механизаторлар – һәрбер белгеч тәҗрибәсе белән уртаклаша, экскурсия үткәрә, һөнәренең нигезләренә өйрәтә ала. 45 баланың һәркайсы ул һөнәрне тоемлый алырлык һәм үзе яшәгән урында үз урынын табарлык итеп өйрәтәләр.

Ә балаларның үз-үзен тотышындагы асоциальлек белән нишләргә? 1980 нче еллар башында әлеге мәсьәлә шактый кискен тора. Мәгарифне үстерү институтына төрле лекторлар чакырып карыйлар: әмма алар – теоретиклар. Бала наркотиклар куллана башлаганда, группировкаларга кереп киткәндә, үзе һәм башкалар өчен куркыныч тудыра торган яшәү рәвеше алып барганда нишләргә кирәген әйтә алмыйлар. Үсеп килгән җинаятьчелек белән

бәйле куркынычларны ничек урап узарга? Бәхеткә, нәкъ шул вакытта Татарстанның баш прокуроры вазифасына Кафил Әмиров билгеләнә. Инна Богуславская аны педагоглар алдында чыгыш ясарга чакыра. Прокурор ризалык биреп кенә калмый, ә мондый очрашуларда еш бирелә торган сорауларны игътибар белән өйрәнеп, аудитория белән аралашырга әзерләнеп килә. Күпьеллык хезмәттәшлек шулай башлана, нәтиҗәдә бик күп методик материал булдырыла, Татарстанда җинаятьчелек профилактикасының алдынгы сафларында торган мөгаллимнәр белән бик күп әңгәмәләр уздырыла.

КАН СОСТАВЫ ҮЗГӘ БУЛГАН КЕШЕЛӘР

«О, мин аңладым. Сез – республиканың төп тәрбиячесе», – ди Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, 1990 нчы елларда чараларның берсендә аны Инна Григорьевна белән таныштыргач. Президент белән методист аралашалар, һәм чәй вакыты җиткәч, Шәймиев Инна Григорьевна янәшәсенә утыра. Күпмедер вакыт узгач, Минтимер Шәрип улы саубуллаша башлый. Педагоглардан теләк-үтенечләре, тәкъдимнәре юкмы дип сорый. «Менеке бар, – дип, көтмәгәндә мөрәҗәгать итә Инна Григорьевна. – Өстәмә белем бирү системасында эшли торган кешеләрнең хезмәт хаклары бик аз, аларга бүләкләр дә бирелми диярлек. Ә аларның хәтта кан составына кадәр үзгә... Алар үз эшләренә мөкиббән, гомумән «өстәмә» белем бирү дигән сүзне дә яратмыйлар. Бик күп балалар өчен ул төп белемгә әйләнә. Балалар анда кызыклы җитәкче белән таныша, дуслар таба. Анда мәктәптән дә яхшырак булырга мөмкин». Һәм Шәймиев ул вакыттагы мәгариф министры Васил Гайфуллинга бүләкләр турында кайгыртырга куша.

Коучинг, менторлык, остазлык. Инна Богуславская Мәгарифне үстерү институтында унбиш, егерме ел элек шөгыльләнгән эш хәзер шулай дип атала. Мәгариф – процесс ул, аның белән идарә итәргә кирәк. Инна Григорьевна һәрбер курсны башлаганда әйтә торган шушы җөмләдән бүген республикада танылган бик күп мәгариф, дәүләт структуралары, хәтта бизнес җитәкчеләренең олы хезмәт юлы башланган. Безнең героебыз ярдәмендә берәүләр үзләренең көчле якларын ачкан, икенчеләр идеяләрен тормышка ашырырга өйрәнгән, өченчеләре бүген популяр булган социаль проектлаштыруны үзләштергән. Безнең героебыз бүген дә мәктәп директорының төп осталыгы дип аның команда җыя алуын саный. Чыннан да, республиканың һәрбер алдынгы мәктәбендә андый команда бар.

ЙОЛДЫЗЛАР КАБЫЗУЧЫ

«Богуславская картасында Татарстан өстендә – йолдызлы күк», – Татарстан журналисты София Сайганова Инна Григорьевна турында шулай дип яза. Безнең героиняның язмышына кайчандыр Кировоградның рус теле һәм әдәбияты укытучысы Антонина Лементарева, татар мөгаллиме, академик һәм шәрык белгече Мирза Мәхмүтов, прокурор Кафил Әмиров, академик Гүзәл Мөхәмммәтҗанова һәм башка кызыклы шәхесләр йогынты ясаган кебек, Инна Богуславская да бүген республика мәгариф системасының үсешен билгеле торган җәмәгать эшлеклеләре, мәктәп директорлары, методистлар, белгечләрнең язмышына үзенең лаеклы өлешен керткән.

Татьяна Ларионова, Алсу Әсәдуллина, Венера Хәйретдинова, Диләрә Кәримова, Юлия Салюкова – бу исемлекне бик озак дәвам итәргә булыр иде. 2010 елда үткәрелгән сораштыруда йөзләрчә катнашучы Инна Григорьевнаны Татарстанның «укытучылары укытучысы» дип юкка гына атамагандыр.

Безнең героинябызга 80 яшь тулып узды инде. Әмма талантлы кешегә яше комачауламый. Хәзерге вакытта Инна Григорьевна берничә мәгариф учреждениесендә фәнни консультант булып эшли.

– Мин методист белгечлеге сайлап, әлеге һөнәр буенча нәрсәгәдер өйрәнгәннән соң гына да яшәешебез әллә ничә тапкыр тамырдан үзгәреш кичерде. Тагын үзгәрәчәк әле. Әмма мин мәктәпнең тәрбия бирүнең иң яхшы традицияләрен саклап калуы, даими рәвештә иҗади үсеше яклы. Безнең укучыларыбыз уңышка ирешсен, бәхетле булсын иде дип телим, – ди Инна Богуславская. – Татарстанда бик күп әйбәт тәрбия практикалары булдырдык, аларның нәтиҗәсе мәктәп укучыларының уңышларында күренә. Бу тәҗрибәне кулланырга, таратырга кирәк. Һәм бу эштә минем хезмәтемнең дә файдалы булуы белән бәхетлемен.

Ул чакта Татарстан прокуроры Кафил Әмиров укытучылар өчен түгәрәк өстәл оештыра. 2012 ел.

ПЕДАГОГКА ӘЙЛӘНГӘН ӘНИ

Юрий Блинов

Наталья Авдеева – үзенчәлекле бала әнисе. Үз кызын аңлау һәм аңа иң яхшы үсеш шартлары тудыру өчен, ул бик озын юл үтә. 2014 елдан бирле Наталья, логопед-дефектолог булып эшләп, башка үзенчәлекле балаларга да булыша. Аның тәҗрибәсе күп кеше өчен бик файдалы булып чыга. 2020 елда ул менталь тайпылышлары булган кешеләр өчен үзенең «Пирамидка» үзәген ача, бүген анда Казанның 60лап баласы ярдәм ала.

ТЕЛЕПАТИЯГӘ НИГЕЗЛӘНГӘН СӘНГАТЬ

Ул – профессиональ педагог, бик сизгер кеше. Коңгырт-кара күзләре бу дөньяга яратып, кызыксынып һәм игътибар белән бага. Натальяның әңгәмәдәшләрен ничек бирелеп тыңлавына таң калырлык, бигрәк тә балалар белән аралашуы сокландыра.

Менталь һәм интеллектуаль тайпылышлары булган сабыйлар начар сөйләшә һәм аны начар аңлый. Бәләкәчләрнең бик кечкенә булуы да хәлне катлауландыра. Әмма Натальяның үз шәкертләре белән аралашуы һәрвакыт уңышлы булып чыга: педагог елап торган баланың күзенә карап, иңенә сак кына кагылуга һәм тынычландыра торган тонда берничә сүз әйтүгә, үзара мөнәсәбәтләр җайлана да куя. Үзара хезмәттәшлек тылсымының шаһиты булган бу мизгелләрдә педагогиканың телепатиягә нигезләнгән сәнгать булуына төшенәсең.

Балаларның үз педагогларына ышануы күренеп тора, чөнки алар үзләрен аңлаганны тоя. Үзенчәлекле балаларга кызганып түгел, бәлки һәркайсының шәхесенә зур ихтирам белән карау һәм аралашу – Натальяның төп кагыйдәсе.

– Инвалидлар кызгануга мохтаҗ түгел, алар үзләрен аңлауны һәм үзләренә булышуны гына сорый, – ди ул. – Әгәр без кызгануны аңлауга, белем һәм ярдәмгә алыштырабыз икән, барысы да яхшы булачак. Инвалидлыгы

Фотолар автордан алынды

булган кешеләр начар да, мескен дә, бәхетсез дә түгел, алар бары башка, үзгә генә. Алар да безнең кебек үк яши, әмма бераз башкарак дөньяда. Һәм әгәр без бу дөнья белән аралашканда шуны аңлап эшлибез икән, бөтен кешегә дә яшәү җиңеләер иде. Минемчә, безгә, гадәти тормыш алып баручыларга да, җиңелрәк булыр – игелек, миһербанлык күренешләре күбәер иде.

Наталья дәрестә. «Әни мәктәбе» – иң бәләкәйләр өчен оештырылган, алар кабул итү, моториканы үстерүгә, сөйләмне аңлауга юнәлтелгән.

МИҢА ТИЗ АРАДА ӨЛКӘНӘЕРГӘ ТУРЫ КИЛДЕ

Наталья ачык холыклы, әмма конкрет та – ул кешеләр белән мөнәсәбәтләрендә тиешле киртәне куя белә. Һәм бу ихтыяр көче педагогик эшчәнлек, үзәктәге балалар һәм аларның ата-аналары каршында җаваплылык тәэсирендә генә формалашмаган. Язмышындагы ике вакыйга аның бүгенге холкын формалаштырган:

– Әнием исән вакытта мин бернәрсә өчен дә җаваплылык тоймаган инфантильрәк кеше идем. Ул минем бик зур ярдәмчем булды. Мин күбәләктәй сөенеп очтым гына, чөнки теләгән бөтен нәрсәм тормышка ашырыла килде. Һәм миңа 25 яшемдә, бөтенләй көтмәгәндә, бер төн эчендә мин әнисез калдым. Барысы да кинәт булды – инсульт. Һәм менә иртәнге сәгать 5 тә әнием белән соңгы тапкыр хушлашып урамга чыккач, тормышны бөтенләй белмәвемне аңладым. Ничек яшәргә инде миңа хәзер? Кулымда биш яшьлек кызым калды. Һәм бүтән беркемем дә юк. Беркемем дә. Җирләгәндә, аннары бераз аңыма килгәнче, туганнарым нинди дер ярдәм күрсәтте билгеле. Әмма, табигый ки, күпмедер вакыттан соң алар барысы да үз тормышларын дәвам итте.

Минем исә торырга урыным да, эшем дә юк, бәләкәй кызым гына бар. Һәм миңа тиз арада өлкәнәергә туры килде. Бусы – беренче җитди вакыйга. Һәм бу 2006 елда булды.

2008 елда исә мин үсешендә үзенчәлекләр булган, ярдәмгә бик мохтаҗ кызым – Полинаны таптым. Мин бөтен психологик стадияләрне дә үттем: ачу, үпкә, язмышыма күнү. Хәзер инде, «Наташа, тагын бер кат бу юлны үтә алыр идеңме», дип сорасалар,

> – 2019 ЕЛДА ГИМНАЗИЯДӘ ДАУН СИНДРОМЛЫ БАЛАЛАРНЫ МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛӘҮ БУЕНЧА ҮЗ ПРОГРАММАМ НИГЕЗЕНДӘ ЭШЛӘГӘНДӘ, МИН АЛАРДА ДӨРЕС ЭМОЦИЯЛӘРНЕҢ БУЛМАВЫН КҮРДЕМ, ЯГЪНИ ЭМОЦИОНАЛЬ-ИХТЫЯРЫЙ ӨЛКӘГӘ ЗЫЯН КИЛГӘН, АЛАР ТӘРТИП КАГЫЙДӘЛӘРЕН ҮТӘМИ. Ә БУ БАЗАДАН БАШКА НИНДИ ДӘ БУЛСА МАТЕРИАЛНЫ ӨЙРӘНҮ ҺӘМ КАБУЛ ИТҮ МӨМКИН ТҮГЕЛ. ШУЛ УК ВАКЫТТА МИН БУ БАЛАЛАРГА НӘРСӘ ҖИТМӘВЕН ЯХШЫ АҢЛЫЙ ИДЕМ. МЕНӘ ШУЛ РӘВЕШЛЕ ҮЗӘК АЧУ ИДЕЯСЕ ТУДЫ. **ШУЛ ИДЕЯНЕ ТОРМЫШКА АШЫРУ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫЛЫКНЫ ҮЗЕМӘ АЛЫРГА ӘЗЕР БУЛУЫМНЫ АҢЛАДЫМ**.

Казан Яшь тамашачы театры сәхнәсендә спектакльдән соң (уртада – Полина, сулдан уңга: Реназ, Даня, Леня һәм Максим).

анык кына «әйе» дип тә, «юк» дип тә әйтә алмыйм. Үзенчәлекле бала әниләренә мондый сорауны бирүләрен еш ишетәм. Күпләр җиңел генә: «Әйе, мин шундый бәхетле! Мин бу юлны тагын бер кат үтәр идем. Бала - бит ул бәхет», – ди.

Юк шул. Үзенчәлекле бала тәрбияләү – бик кыен. Матди яктан да, физик яктан да, әхлакый яктан да. Бик катлаулы. Шунлыктан мондый сорауга кистереп җавап бирә алмыйм. Әмма, язмышыма туры килгән әлеге ике авыр вакыйгага карамастан, үземнең бүген һәм хәзер яшәвем, язмышымны кабул итүем һәм һәр яңа көнгә сөенүем белән горурланам.

СЫНАУЛАР КӨЧ БИРӘ

Наталья еш искә алырга ярата: бала – ата-анасының чагылышы ул. Һәм аның кызы моңа дәлил булып тора: Полинага «баш миенең органик зарарлануы» диагнозы куелган. Үз диагнозы өчен ул акыл ягыннан көчле бала. Үсеше сизелеп тора – монда әнисенең зур хезмәте күренә. Полинага да, әнисе кебек үк, язмыш сынауларына бирешмәс өчен көчле булырга туры киләчәк.

– Полина туганда үлгән иде, – дип, хәтер йомгагын сүтә Наталья. – Аны хәтта исән калдырырыга да тырышмадылар. Тугач ук, одеялга төрделәр, барысы да чыгып китте. Минем бер тапкыр бәби тапканым бар иде бит инде, аның борынын чистартырга, үпкәсе ачылсын өчен, әйләндерергә кирәклеген беләм. Әмма бәбинең бер тавышы да чыкмаганга, калдырдылар да киттеләр. Мин, билгеле инде, еладым да, кычкырдым да, карауларын, аңлатуларын, булышуларын таләп иттем...

Урынымнан тора алмыйм бит әле. Һәм менә бик күп вакыт үткәннән соң мин баламның төчкергәнен ишеттем! Әкрен генә, песи баласы кебек кенә! Мин тагын кычкырырга тотындым: «Ул төчкерә! Зинһар өчен, килегез, карагыз инде, ул төчкерә бит!» – дим. Шуннан соңгы хәлләрне акрынайтылган фильмдагы кебек хәтерлим: табиблар йөгереп килде, бәби одеялын ачтылар да тикшерергә тотындылар.

Минем ерактан күзем начар күрә, шуңа башта аңламадым да әле – үлчәүгә ниндидер кап-кара бәбине салдылар. Зәңгәр дә түгел, кара. Мин аның башы кайсы якта икәнен

дә аңламадым, әмма әкренләп тәненең кызара башлавын күрдем, ниндидер алсу таплар чыкты. Минем мондый хәлне беркайчан да күргәнем юк иде – гаҗәп бит! Нинди көчле минем кызым – төчкереп, ул үз борын тишекләрен үзе чистартты!

ТОРМЫШКА ӘЗЕРЛӘҮ КИРӘК

Үзенең үзәгендә Наташа гаилә мохитен сакларга тырыша. Кешеләр арасындагы дөрес мөнәсәбәтләрнең мөһимлеген һәм кадерен онытмаска куша. Һәр педагог һәм ата-ана үз баласын аңлый һәм кабул итә. Һәркайсы баласы куелган бурычларны үти алсын, аларны кызыксынып башкарсын, дип тырыша.

Натальяның ата-ана һәм педагогларга биргән киңәшләре тирән фикерле, нәфис сурәтле һәм җете образлы булуы белән аерылып тора. Ул эмоция һәм хисләрне шулай тапшыра ала ки, аның сүзләре, ниндидер гамәлгә этәреп, тормышка, проблемаларга караш формалаштырырга мөмкинлек бирә. Бу аралашу бигрәк тә үзенчәлекле бала тәрбияләүдә үзләрен ышанычсыз тоткан ата-аналар өчен мөһим.

Натальяның әйтүенчә, реабилитациянең уңышлы булуы – ата-ананың үз баласын кабул итүенә, ә кабул итү исә аның шәхесен аңлауга бәйле. Баланың ихтыяҗларын исәпкә алмыйча тәрбияләү дә дөрес түгел.

– Күп кенә Көнбатыш илләрендә балада социаль-көнкүреш күнекмәләрен үстерүгә зур игътибар бирелә. Анда иң мөһиме – мондый баланы мөстәкыйль яшәргә һәм гаиләсенең хәлен аңларга, проблема түгел, бәлки ярдәмче булырга өйрәтү, чөнки ата-ана картая бит, көч кими, шуңа мондый күнекмәләр бик кирәк санала.

ХӘЛКАДӘРИ ТЫРЫШУ ЗАРУР

– Бездә ата-аналар ни өчен иртә сүрелә? Чөнки алар барысы да ниндидер социаль нәтиҗәгә ирешергә омтыла – аның баласын җәмгыять танысын. Шуңа күрә алар бөтен көчләрен куеп тырыша. Бездә бит кешене берәр нәрсәгә ирешсә, әйтик, яхшы рәссам, футболчы, җырчы булса гына күрәләр, кадерли башлыйлар. Бу очракта үзенчәлекле бала да танылa ала. Ә боларның берсен дә эшли алмаганын еш кына өметсез дип саныйлар.

Ә чынлыкта исә һәр бала шәхес. Һәм, ихтимал, аның профессиональ футболчы буласы килмидер. Галерея өчен махсус картиналар язу да аңа кызык булмаска мөмкин. Биисе килсә, сәхнәдә бию мәҗбүри түгел – бию түгәрәге бар. Ягъни шөгыльләр – аның тормышының нигезе түгел, бәлки, үсеш өчен кирәкле нәрсәләр генә. Бала боларны үзенең бу дөньяда барлыгын тою өчен генә эшли. Безнең менталитетның Көнбатыш илләрендәгедән аермасы нәкъ менә шунда: алар баладан әллә нинди казанышлар көтми, аны ничек бар, шулай кабул итә.

Һәм мин ата-аналарга һәрвакыт әйтә килләм: баланы вакытында тәрбияләмәсәгез, аңа социаль-көнкүреш күнекмәләрен вакытында бирмәсәгез, олыгайган көнегездә бик авыр хәлдә калырга мөмкинсез. 7 яшьлек бала белән 30 яшьлек баланың идәндә аунавы – икесе ике хәл. Бездә һаман тәрбияләргә түгел, берәр яктан лидер ясарга омтылалар. Ә иң кирәге – аның тормышка яраклашуы өчен хәлдән килгәннең барысын да эшләү, бала үзен-үзе карый алырлык булсын.

ИЛҺАМ ЧЫГАНАГЫ – НӘТИҖӘ

Натальяда шәхеснең һөнәр белән шулкадәр яхшы ярашуы сокландыра. Аның башка мавыгулары юк: бары тик бер генә нәрсә – үзенең үзәге белән янып яши, аны өе урынына күрә, вакыты да күбрәк шунда үтә. Илһам чыганагы булган нәтиҗә дә эшендә күренә.

Үзәктә үсеш динамикасын конкрет бала буенча да, төркем буенча да күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, Ренат исемле малай (Даун синдромы) сентябрьдә бөтенләй мөстәкыйль булмый. Февральгә исә малай күзен эшли алмаган нәрсәләрне башкарырга өйрәнә, аның беренче академик уңышлары да күренә. Коррекцион педагогикада үсешнең мондый темплары шактый яхшы дип санала.

Мәктәпкә әзерлектән тыш, үзәктә балаларның психоэмоциональ адаптациясе өчен кирәкле иҗат юнәлешләре дә эшли: вокал, рәсем ясау, хореография, актерлык осталыгы. Балалар анда да үзләрен бик актив күрсәтә. Мәсәлән, актерлык осталыгы түгәрәге үзәктә 2020 елның ноябрендә оеша, ә 2021 елның сентябрендә анда катнашучылар – барысы да үзенчәлекле балалар – Казан Яшь тамашачы театрының зур сәхнәсендә чыгыш ясый. Анда барысын да өлкәннәр ярдәменнән башка үзләре башкара. Менә шундый нәтиҗәләр Натальяны илһамландыра да инде.

– Үз эшемне бик яратам, ул тормышым белән аерылгысыз бәйләнгән. Һәм мин моңа бер дә уфтанмыйм. Бер дә. Полина мин шәхес булып җитлеккәндә туды. Акыл утыра башлагач (моны башкача әйтеп булмый инде), үземнең инфантиль чорымдагы тормышымны тамырдан үзгәрттем. Кеше бу дөньяга аны танып белү, рәхәтләнеп яшәр өчен туа. Иң авыр чакларда да яхшыга өметләнергә кирәк. Гомерем эшем белән тыгыз бәйләнгән булса да, миңа бер дә кыен түгел. Бу тормышымны да, эшемне дә бик яратам. Ә иң рәхәте – моны мин ихластан әйтәм – балаларның, укучыларымның үсешләрендәге уңышларын күрү.

«ЯҢГЫР, ЯУ, ЯУ, ЯУ!»

Фәнзилә Җәүһәрова,
Татарстанның баш фольклорчысы,
филология фәннәре кандидаты

«Татарстан» журналы быел – Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында да традицияләребез, йолаларыбыз турында язуын дәвам итә. Июнь аенда җәйге йолаларны барларга булдык. Алар арасында иң киң таралганы – яңгыр теләү йоласыдыр, мөгаен. Бу өлкәдәге тәҗрибәле белгечебез әнә шулар хакында бәйнә-бәйнә сөйләде.

ЯҢГЫР ТЕЛӘҮ

– Җәйге йолалар бик борынгы. Шулар арасыннан иң еш башкарыла торганы – келәүләр, ягъни яңгыр сорау теләкләре. Аларның тарихы мәҗүси заманнарга барып тоташа. Ислам дине кабул ителгәннән соң, яшәешкә дингә хас булган текстлар, догалар килеп керә. Аннан соң ул догаларга багышлаулар, мисал өчен, Аллаһы Тәгаләдән яңгыр сорау кебек үзенчәлекләр дә килеп кушыла. Аларны без фәндә табигатькә бәйле йолалар дип әйтәбез. Бүген аның асылы – табигать көченә, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгатькә кайтып кала.

Яңгыр тели торган йолалар аерым бер урынга һәм вакытка бәйле. Яңгыр

Фото tetyushy.ru сайтыннан

яумаган вакытта, чәчкән орлыклар тишелеп, әйбәт кенә үсеп китсен өчен, нәкъ шундый йола башкарганнар. Ул инде, елның ничек килүенә карап, гадәттә июньнең икенче яртысы – июль башларына туры килгән. Ләкин аның конкрет вакыты һәм урыны булмаган. Хәзер дә шулай ул. Нигездә, һәр авылның, һәр җирлекнең үзенчәлекле (изге) урыны бар бит. Йоланы үткәрү вакытын, урынын авыл халкы үзе билгели, һәм аны ел саен традицион урында уздырырга тырышалар. Ул чишмә, инеш буе, ниндидер ерым булырга мөмкин. Иң мөһиме – анда чыгыш булсын, чөнки яңгыр теләүләр суга бәйле.

Мондый чаралар бүген дә төрле якта төрлечә уза. Бер җирдә кара тавык суялар, аннан шуны пешереп, бергәләп ашыйлар. Әйтик, Кама Тамагы, Тәтеш районнарында аны «шыйлык» диләр. Каманың аръягында да шундый йола бар.

Нократ татарларында исә чүп йоласы бар. Аның да үз традициясе: ботка яисә тавык шулпасы пешерелә. Кайбер очракта шулпа сарык итеннән әзерләнә. (Кара сарык та булырга мөмкин.) Шулай ук кара сыер суеп, шул ит белән мәҗлес ясаучы төбәкләр дә булган. Йола исә су сибешеп, бергәләп яңгыр теләү белән тәгәлләнгән. (Хәзер дә шулай шулпалар пешереп, аннан догалар укып, яңгыр сораучы авыллар, районнар бар.)

Әйткәнемчә, ислам дине кабул ителгәч, яңгыр теләү йолаларына дога укып, Аллаһка мөрәҗәгать итү гадәте дә кереп китә.

Яңгыр теләүләргә бәйле ниндидер аерым монографияләр юк. Ләкин бу турыда кызыклы гына мәкаләләр бар. Мәсәлән, XIX гасырда Казан университеты каршында оештырылган «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре» язмаларында бу турыда телгә алына. Аннары Гали Рәхимнең хезмәтләрендә дә бар, Марсель Бакиров та бу теманы шактый өйрәнде. Шулай ук Нәкый Исәнбәтнең «Балалар фольклоры» дигән китабында да берникадәр мәгълүмат бар. Флера Баязитованың эзләнүләреннән дә табарга мөмкин. Ләкин аның асылын тулысынча бәян иткән зур хезмәтләр бар дип тә, әлеге тема бөтенләй өйрәнелмәгән дип тә әйтә алмыйбыз.

Бу йолаларның асылына килсәк, әлбәттә, ул чәчкән игеннәр, үләннәр үссен өчен башкарылган. Әле бит маллар да бар, алар да нәрсәдер ашарга тиеш. Шуңа күрә яңгыр теләүнең төп максаты – елның уңышын киметтермичә, мул иген, печән алу. Шуның өчен дә аның тарихы бик борынгы.

Әлеге йола гамәлләрен башкарганнан соң яңгырларның явуы – ул факт. Мисал өчен, узган ел Саратов өлкәсенә шундый йоланы карарга бардык. Кайтып җитәргә өлгермәдек, яңгыр койды, дип шалтыраттылар. Ләкин фән ягыннан, әйтик, геофизиклар тарафыннан әлеге йолаларны бер җепкә салып өйрәнү, аңлату юк. Анда магнит кырлары үзгәрәме, әллә инде күмәкләп вибрацияле текстлар әйткәнгә, күк җисеменә нидер буламы, аңлатмасын ишеткәнем юк.

Тагын бер кызык кына хәл: шайтан таягы дигән үсемлек бар. Менә шул шайтан таягын кисеп алып, башын аска, сабагын өскә каратып, азрак суккаласаң, аннан соң да яңгыр ява дип исәпләгәннәр. Чынлап та, кайвакыт туры килә!

ХӘВЕФ-ХӘТӘР БУЛМАСЫН...

Әле кайвакыт яңгыр теләгәннән соң яңгыр туктату йолаларын да башкарганнар, чөнки бер ява башлагач, тиз генә туктамый бит әле ул. Ә бу игеннәрне черетергә мөмкин.

Җәй чәчәкле болыннары, күңелгә хуш килгән кошлар тавышы, тәмле җиләк-җимешләре белән генә түгел, яшеннәре, яңгырлары, көчле давыллары, өермәләре белән дә билгеле. Шуңа күрә элек-электән, җәй башлануга, әби-бабаларыбыз, хәвефсез җәйләр сорап, теләк теләгән. Аннан тыш төрле ырымнар да башкарганнар, шуларның берсе – өермәдән саклану. Ул төрле якта төрлечә эшләнә. Әйтик, Ульяновск якларында, кисәк башланган өермәгә карап, капка төбеннән:

«Өермә, өермә, син мине күрмә,
Мин чыбылдык астында,
Син урам уртасында», – дип кычкырганнар.

Казан артында яшәүче татарлар, көчле яшен белән бергә өермә күтәрелсә, мич төбен себерә торган пумаланы алып, ишегалдына чыкканнар һәм: «Җылы яңгырлар булсын, йомшак яңгырлар булсын, ашлыкларны бозмасын, йортларыбыз тузмасын», - дигәннәр. Тау ягы авылларында исә, бозлы яңгырлар белән өермәләр килсә, ишегалдына ипи көрәкләре, кисәү агачлары, мич капкачларын тотып атканнар.

2023 ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

ЯҢГЫР ТЕЛӘГӘНДӘ ӘЙТЕЛӘ ТОРГАН ТАКМАКЛАР:

Яңгыр, яу, яу, яу!
Тәти кашык бирермен,
Тәмле ботка бирермен.
Тәти кашык базарда,
Майлы ботка казанда.
Яңгыр, яу, яу, яу!
Ашлык уңсын ызанда,
Ботка пешсен казанда;
Алтын кашык базарда,
Көмеш кашык болытта,
Нык яварга онытма!
Яңгыр, яу, яу, яу!
Сине көтә җир, җир!
Безгә күмәч бир, бир!
Яңгыркаем, яу, яу!
Үләннәр дә күп булсын,
Сыерлар да тук булсын,
Безгә эчәргә сөт булсын!
Яңгыр, яу, яу, яу!
Иләктән, чиләктән,
Пәрәмәчтән, коймактан,
Арпадан, бодайдан,
Эшләр китәр уңайдан.
Яңгыр, яу, яу, яу!
Бакчаларда алмагач
Үсми яңгыр яумагач.
Бакчалардан ни файда,
Алма пешеп тормагач.
Яңгыр, яу, яу, яу!
Яңгыр ява, томан төшә,
Кура җиләге пешә,
Ипи, пәрәмәч пешә.
Яңгыр, яу, яу, яу!
Ипи-күмәч зур үссен,
Безгә сөенеч килсен!

Марсель Галиев – шагыйрь, язучы, фотограф, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Марсель Галиев шигърият һәм проза жанрында иҗат итә, фотога төшерү белән мавыга. Матбугатта аның беренче әсәрләре 1970 нче еллар башында басыла башлый. 1979 елда – «Еллар чалымы» исемле шигырьләр җыентыгы, ә 1980 елда ике повесте кергән «Ул чакта» дип аталган проза китабы дөнья күрә.

Әсәрләре рус, төрек, поляк, украин, үзбәк, казах, чуваш һәм башка телләргә тәрҗемә ителгән.

Марсель Галиев

ЗАТЛЫ ЧЫБЫРКЫ ХУҖАСЫ

Кояш Суыр тавына төшеп җитәргә тәртә биеклеге генә калган. Утынлыкта инде эш бетеп килә иде. Урам як капканы киң ачып, күрше Мотыйк абзый килеп керде. Гадәтенчә, протезлы аягына киез итек кигән. Кәкре башлы шомырт таягына таянып, әкрен генә безгә таба килде дә, исәнлек-саулык сорашып, бүкән өстенә утырды һәм кесәсеннән каешланып беткән янчыгын чыгарды. Тәмләп кенә тәмәке төрде.

– Кибет янында... – дип сүзен башлады ул. Мотыйк абзыйны тыңлар өчен, үзенә бер әзерлек, түземлек кирәк. Бер сүз әйтер дә, ник әйтүенә үкенгәндәй, сүзен кире йотып җибәрер. Мәгънәле генә тынып тора-тора, җөмләнең икенче яртысына күчәр. – Сөйләп тордылар, – дип, сүзен дәвам иттерде ул. – Әллә чын, – чыжылдатып тәмәке суырды, – әллә ялган. Теге... көтүче Гамис бар ие бит әле...

Әти сабыр гына «әйе» дип җөпләп куйды. Мин, түземем бетеп, йә, әйт инде җәтрәк, дип кычкырып җибәрә яздым.

– Шул... кайткан, диләр.

– Кит аннан! – Әти бүкән өстеннән сикереп үк торды. Мине көтелмәгән хәбәр ишеткәндә була торган дулкынлану биләп алды.

– Хатыны да бар, имеш.

– Кара син аны, ә! – дип, әти тел шартлатып куйды.

– Бик чибәр нәмәрсә, ди. Безнеңчә бер авыз сүз белми икән.

– Менә кеше сүзенә ышан, – диде әти. – Үлгән икән диделәр, тагын әллә ниткән имеш-мимешләр сөйләгән булдылар.

– Бик баеп кайткан, ди.

– Гелгә дип кайтты микән?

– Кайтты, ди, үтешли генә...

– Гамис та кеше булган диген, ә!

– Әйтмә инде. Әлифне таяк дип белмәгән бер малай...

Кечкенә генә хәбәр дә авылның салмак агышлы тормышын үзгәртеп җибәрә. Кешеләр сүзчәнләнеп китәләр, үз мәшәкатьләрен онытып, азга гына шул яңалык белән яшәп алалар. Көтелмәгән хәбәрне һәммә кеше беренче булып күршедән күршегә җиткерергә тырыша.

Мин, тиз-тиз генә юынып, киемнәремне алыштырдым да әллә нинди бер алгысыну белән югары очка таба ашыктым. Димәк, Гамис исән. Кече күңелле, хикмәтле бер егет булып хәтеремдә калган Гамис исән!

Аның кебек чыбыркы шартлата алучы, белмим, авылда тагын берәр кеше булдымы икән? Үзенчә иպле, килешле итеп чыбыркының сабыннан тотар иде дә, кулын өскә чөеп, баш әйләнәли иплəп кенә селтәп җибәрер иде... Бөтен тирә-юньгә таралып, күк гөмбәзеннән таеп киткән шикелле шартлау авазы яңгырый, һәм бераздан ул өзек-өзек булып киредән кайта, әйтерсең таулар, бу яңгырашны югалтырга теләмәгәндәй, чөеп-чөеп уйный-

Фото: Александр Ефремов; иллюстрация: В.Е. Маковскийның «Пастушки» картинасы

лар. Без, малайлар, һушыбыз китеп басып торабыз. Кайсыбызның авызы ачык, кемнеңдер борын астыннан «каен суы» төшеп килә, кемнеңдер тешсез авызы ерылып киткән.

Гамиснең тавышы безне дәррәү хәрәкәткә китерә.

– Йә, кайсыгыз?!

Һәркемнең беренче булып үзен сынап карыйсы килә. Ләкин каударланып сузылган куллар һавада асылынып кала. Гамис чыбыркысын артына яшерә дә, җитди булырга тырышып, күзгә карый.

– Күкәй алып килдеңме соң?

– Килдем, килдем, менә, Гамис абый, берне түгел – өчне.

– Сорамый гына урлап алдыңмы?

Аның шаяртып әйткәнен абайлап та өлгермисең.

– Юк, юк, әни үз кулы белән бирде.

– Шулай дисәң генә.

Чыбыркы кулдан кулга китә. Күкәй алып килә алмаганны да Гамис нәүмиз калдырмый, барыбер чыбыркысын биреп тора. Ләкин без беребез дә көтүче Гамис кебек итеп чыбыркы шартлатуның серенә төшенә алмыйбыз. Оста итеп шартлата белмәсәк тә, чыбыркысын тотып карау да үзе бер бәхет бит. Андый чыбыркы тагын кемдә бар! Сабына елкылдап торган кара елан кабыгы кидертелгән. Җиледән үргән каеш чыбыркының буыны саен чук асылынып тора. Шул чукларга нәни гильзалар кигезеп чүкелгән. Алтынсу шома гильзалар, чыбыркыны кулга алуга, күңелле чылтырашып куялар. Чынлап та, андый затлы чыбыркыны минем бүтән беркемдә дә күргәнем булмады.

Көтүче Гамис, чыбыркысын иңенә салса, буй җитмәс бер экият каһарманына әйләнә. Шундый чакта аның иске ботинкасы, терсәк турылары ямаулы, төсе уңган күлмәге, ямаулы чалбары да өр-яңа булып күренә.

Авылда аның әти-әнисе дә, якын туганнары да юк иде бугай. Ул түбән очта иң кырый өйдәге бер карчыкта яши иде.

Көтү карт өянкеләр күләгәсенә туплануга, без гел Гамис тирәсендә эвәрә киләбез. Гамис учак ягып җибәрә, без алып килгән йомыркаларны пешерә, һәрберебезгә өлеш чыгара, әллә нинди үләннәрдән тәмле итеп чәй кайната белә иде.

Аннары яшергән җиреннән ул кечкенә көрәген ала, һәм без, узыша-узыша, аксыргаклыкка таба йөгерәбез. Гамис, түмгәкне казып, шөпшә оясын ача, без, усалланып тузынган кортлардан качып, читтәрәк ятабыз. Бераздан ул безнең янга килә, учында – эче бал белән тулы кечкенә шарчыклар.

Аксыргаклыктан гамьсез генә таралышып барган чакта ул кинәт туктап кала, без, сагаеп, аның тирәсенә елышабыз. Гамис кош оясына тап булган икән. Тик ул сипкелле нәфис йомыркаларга кул тидертми, безне читтән-читтән генә алып китә иде. Кагылдың исә, кош, бу оясын ташлап, бүтән җиргә күченә икән.

Көтүче Гамис энә шулай бөтен нәрсәне белүче серле бер зат булып тоела иде безгә. Үги ана яфрагын өзеп ала да әле бер, әле икенче ягын битенә тидереп карый.

– Сизәсезме? – ди ул. – Бер ягы җылы, бер ягы салкын. Шуңа күрә дә үги ана яфрагы дип атаганнар аны.

Без, малайлар, аңа эчке бер соклану, беркатлы ышану белән карап торабыз. Шулчак арабыздан берәү:

– Бу яфракның нигә кирәге бар инде? – дип куя.

– Табигатьтә бер генә артык нәрсә дә юк, барысы да кирәккә яратылган.

– Черки дәме?

– Черки дә.

Тыела алмыйча, көлеп җибәрәбез. Ә ул җитди итеп:

– Әгәр черки булмаса, җәйге хозурлыкта артык рәхәт булыр иде, ә кеше дигәнең артык рәхәткә чыдый алмый, маемлый, – дип, безне ышандырырга тырыша.

Нөгеш суы, көтү тупланган урынны үткәч, икегә аерыла. Инешнең бер тармагы тегермәнгә таба китә, икенчесе, урау бөгелеш ясап, ерактагы тау тезмәләре итәген юып килә дә, тегермәнне узгач, үзенең төп ярына кайтып төшә.

Беркөнне без әнә шул икенче тармакны буарга булдык. Шау-гөр килеп кәс ташыйбыз. Кычкырышу, бәхәсләшү, узышу – кыскасы, яр буенда туктатып булмастай бер хәрәкәт купкан иде. Шулчак үзәнлекләрне тетрәтеп килгән тояк тавышы безне сагайтып җибәрде. Җайдак туп-туры безгә таба чабып килә иде. Җилбәгәй җибәргән күн җиләне кара җилкән булып ялык-йолык килә. Шомлы тавыш белән кемдер:

– Ибәтулла абзый... – дип куйды.

Ибәтулла агай халык арасында курку һәм дәһшәт салып торучы бер кеше иде. Бәйрәм саен сугышмыйча калмый иде. Салкын кыш дип тә тормый, майкадан гына кала да тотына... Хәйран таза ир-атлар да аны тыя алмыйлар иде. Без, малайлар, аңа курку һәм эчке бер соклану белән карый идек. Әгәр ул сугышмыйча калса, безнең өчен бәйрәмнең һичбер кызыгы булмый иде.

Ибәтулла абзый атын үрә бастырып туктаткан уңайга җәһәт кенә сикереп төште дә Гамисның изүеннән бөтереп тә алды. Гамисның болай да сизрәп беткән күлмәге буйдан-буйга умырылып чыкты. Без, тын алырга да куркып, төлке кергән кетәклектәге тавыклар шикелле, бер кырыйга укмаштык. Ибәтулла абзыйның тавышы әллә каян эчтән каерылып чыкты:

– Син нәрсә, малай актыгы, башыңны бетерәм бит! Иң олы сарыгымны Әмәт чишмәсенә батыргансың... – һәм ул үҗәт бер ярсу белән Гамисны сугып екты да күн итеге белән типкәли дә башлады. – Бот буе малайлар белән... Көзен суеп сатарга дигән сарыгымны... Бетерәм!..

Кан күрүгә курку онытылды бугай, без, малайлар, сүз берләшкәндәй, кайсыбыз инәлеп елый-ялвара, кайсыбыз янаулы кычкыра-кычкыра, Ибәтулла абзыйга ташландык. Ләкин нишли ала идек соң без, аның кул җиленнән үк читкә сибелдек.

– Сарык хакын барыбер чыгарам мин синнән! – Зәһәр ысылдап, Ибәтулла абзый Гамисны күтәреп җиргә бәрде дә, атына атланып, килгән кызулыгы белән чаптырып китеп тә барды.

Кинәт көн әллә нишләде: сүнеп, сүрелеп калгандай булды.

Без, кепкаларыбыз белән инештән су ташып, Гамисның яраларын юдык. Ул, терсәкләренә таянып, күтәрелә төште. Күзләрендә коточкыч газап, ятимлек рәнҗүе иде аның һәм шушы хәлгә таруына бездән оялу, тартыну да бар иде бугай. Бераздан ул хәлсез тавыш белән:

– Барыгыз, өйләрегезгә кайтыгыз, – диде. Беребез дә кузгалмадык, аны ялгызын гына калдырасыбыз килмәде.

– Китегез! – дип ачуланып кычкырып җибәргәч, без, аптырап, әкрен-әкрен генә читенә башладык һәм өйләребезгә таралыштык. Бу күңелсез хәбәрне олыларга җиткерергә кирәк иде.

Шул көннән соң Гамис бүтән күренмәде. Көтү чиратка салынды. Соңыннан төрле сүзләр булды. Берәүләр: больницага салганнар икән, диделәр. Икенчеләре: кайсыдыр шәһәрдән туганнары кайтып, үзләренә торырга алып киткәннәр икән, диделәр. Өченчеләре: читтә үлгән икән, мескен, диделәр.

Гамисның дөрләп кабынырга торган кызгылт чәче, учлап сибелгән ком бөртекләре шикелле сипкелләнгән йөзе һәм гаҗәп оста үрелгән затлы чыбыркысы гына хәтердә калды. Сизелми дә үтеп киткән ике дистә ел эчендә инеш ярында ул утырткан таллар шаулап үстеләр. Халык аны «Гамис таллыгы» дип йөртә башлады.

Һәм менә бүген көтелмәгән хәбәр: Гамис исән, Гамис авылга кайтып төшкән!

Чирәмле мәйдан уртасына урнашкан кечкенә генә кибеткә килүчеләр кичке сәгатьләрдә аеруча күбәя. Күрергә теләгән кешеңне шуннан гына эзлә. Күңелем сизенгән икән, Гамис та шунда иде. Фетр эшләпә кигән, яхшы костюмнан, плащын бөкләп беләгенә салган. Гади киемле агайлар уртасында купшылыгы күзгә бәрелеп тора. Йөзендәге җирән сипкелләре беленер-беленмәс кенә калган. Ә барыбер, ныклап карасаң, элеккеге Гамисны төсмерләп була. Гәүдәсе авыл кешеләренә ят торышта, гадәттән тыш төз, башын артка чөеп-чөеп сөйләшә. Күзләрендә элеккеге моң юк, әллә нинди салкынча, үтәли караш.

Әлбәттә, ул мине танымады. Әтинең исемен сорап кына кем булуымны чамалады. Чирәмгә чүмәшеп утырган авыл агайлары кинәнеп гәпләшәләр иде.

– Да-а, кеше булып кайткансың, Гамис энем.

– Маладис.

– Шахтада эшлим дисең инде, ә?

– Безнең братлар анда хәтсез бугай.

– Кайда хәтәр, анда татар инде.

Кызыбрак алганы, Гамисның җилкәсенә сугып, яратуын белдерә:

– Гел кайтырга уең юкмы соң?

Гамис вәкарь белән генә көлеп куя.

Шулвакыт, чытыр арбасының бөтен санын дыңгырдатып, кибет ишек төбенә җигүле ат килеп туктады.

«Ибәтулла-а», – дип куйды агайларның берсе. Ибәтулла агай, дилбегәсен үрәчәгә

урап, очын арбага ташлады да безгә таба килә башлады. Аның исемен ишетүгә үк, Гамисның яңаклары тимгел-тимгел агарып чыкты, чүгәләгән җиреннән торып басты. Агайларның да кайберләре кунакка хөрмәт йөзеннән тез шартлатып күтәрелделәр. Гамисның күзләрендә нәфрәт уты күреп, «Мин бәләкәй чакта, әнине җылатып, актык бозауны алып чыгып киткән идең бит син, имансыз», – дип, егет-җиләннәрнең элеккеге налог агентын кыйнаганы хәтеремдә калганга күрә, эшләр тирәнгәрәк китмәсен дип, мин дә төркемнең уртасынарак тартылдым.

– Кайтканыңны ишеткән идем, нихәл, энем, исән генәме? – дип, Ибәтулла агай ике куллап Гамис белән күреште, иреннәре сәер генә тартышып куйды, әллә ничек үтә дә юашланып калган иде ул. Ибәтулла агай, гәүдәгә дә бирешеп, картая төшкән инде. Тешләре иске койма кебек араланып, кыйшаеп калган. Күптән инде бәйрәмнәрдә дә сугыш чыгармый. «Сугышырга көч кирәкми аңа, беренче булып башласаң, задурлыгыңны күрсәтсәң, үзеннән-үзе китә ул, сугышырга көч кирәкми», – дип кызурак канлыларны котырткалап, читтән-читтән генә күзәткәләп йөри иде.

Туган җирдән тамыры аерылуга сәбәпче булган кешегә карата, бәлки, Гамис гомере буена рәнҗү, үч саклап йөргәндер. Ә менә бүген, кайчандыр күн пинжәк киеп, гаярь йөргән Ибәтулла абзый урынына бетәшкән картны күргәч, ул, ни кылырга һәм ни әйтергә дә белмичә, катты да калды. Аннары, кулын сузып килә башлауга, Ибәтулла агай каушап артка чигенебрәк куйды. Гамис, үз күзенә тәгаен ышанырга теләгәндәй, аның пинжәген тотып карады.

– Синең,.. Ибәтулла агай, бик шәп күн пинжәгең бар иде элек...

Ибәтулла агай, җиңел сулап, көлеп куйгандай итте, әмма күзләре аның җитди һәм сагаюлы иде.

– Әллә кайчан тузды инде ул, Гамис энем. Пинжәк ни, үзебез дә...

Гамис, кульяулык чыгарып, тирләгән маңгаен сөртте дә кинәт шундый сорау биреп куйды:

– Сарык хәзер ничә сум тора?

Сагаебрак калган агайларның берсе:

– Сарыгына карап инде ул, энем, – диде.

– Кышлау булса, җитмеш-сиксән тәңкә була.

– Шулаймы?! – Гамис кесәсеннән бер төргәк акча чыгарды һәм шыгырдаган унлыкларны санап Ибәтулла абзыйга сузды. – Теге чакта, Ибәтулла агай, минем аркада... сарыгың чишмәгә төшеп үлгән иде, мә, ал.

Ибәтулла агай тагын артка чигенеп куйды.

– Күптән булганны, энем, кузгатма инде син.

– Мин чынлап әйтәм, Ибәтулла агай.

– Синең гаеп тә булмагандыр, дуамаллык бит, үзең беләсең... Гомергә килгән кебек йөрисең дә... мал барыбер кала икән...

Гамис, һаман үҗәтләнеп, акча белән аның касыгына төртте:

– Мә, төп-төгәл җитмеш тәңкә.

– Рәнҗетмә инде, энем, ни сөйлисең... – Ибәтулла агайның тавышы еламсырап чыкты. Кулларын, кая куярга белмәгәндәй, бер артына куйды, бер кесәсенә тыкты. Гамис үзе дә уңайсыз хәлдә калган иде, әле генә тәмләп сөйләшеп утырган агайларның да йөзенә күләгә йөгерде. Гамисның ничә еллар буе таш итеп күңелендә йөрткән үченең мәгънәсе калмаган иде инде. Олыгаеп, инде чүгә башлаган агайны кыен хәлгә куюына үкенеп, ул, кулына йомарланган акчасын нишләтергә белмичә, уңайсызланып, як-ягына каранып алды да кинәт кузгалып, миңа сузды:

– Мә, дустым, бер ящик аракы алып чык, булмаса, әчик әле бер.

Әлеге киеренкелекнең болай борылыш алуына канәгать калган агайлар җиңел сулап куйдылар.

Гамис мөлдерәмә тулы кырлы стаканны беренче булып Ибәтулла агайга сузды. Тегесе, бер-ике йотуга ук тончыгып, кул аркасы белән авызын каплады. Аңа ак ипи сыныгы белән сыр кисәге суздылар.

Бер тулып, бер бушап алган стакан Гамиска әйтелгән әчкерсез рәхмәтле сүзләр астында түгәрәк буйлап йөри торды.

– Ялындырып кына тотасыз, авылдашлар, менә безнең шахтерлар!..

Баядан бирле ниндидер сүзе бар шикелле кыбырсып утырган Ибәтулла агай кыенсынып кына Гамисның иңенә кулын салды.

– Кайтканыңны ишеткәч... сарык суйган идем. Аштан олы булмасаң... Гомер буе күңелдә төер йөрде, җыйык әле шуны бер, ичмасам...

– Барабыз болай булгач, барабыз, – дип, икеләнергә урын калдырмыйча, Гамисны урап алдылар.

– Хатыныңны да алып, барыбыз бергә, – диде Ибәтулла агай карлыккан тавыш белән.

– Иртәгә миңа. Миңа, – дип шаулашты агайлар. Ибәтулла агайның өенә күчәсе мәҗлес әнә шулай чирәмлектә башланды.

– Их, авылдашлар, – диде кызарып алган Гамис, – тартуын ташлаган кешенең төшләренә тәмәке кереп йөдәткән кебек, минем дә менә ничә еллар инде чыбыркы шартлатасы килеп, кул кычытып йөрде. Кая, бирегез әле миңа чыбыркы!

– Каян табасың инде аны, энем.

– Чыбыркы түгел, көтүчесе дә юк әле аның. Өй борынча, чиратлап көтәбез.

Суыр тавы артына кояш яртылаш чумган. Авырайган кичке тузанны туздырып, тук тавышлар белән олы урамга көтү кереп килә. Авыл киченең моңлы манзарасына карап торган Гамисның шул чакта кул аркасы белән сиздермичә генә күз яшен сөртеп куйганын кем генә искәрде икән?

1976

БЕРЕНЧЕ ТАТАР РЕВОЛЮЦИОНЕРЫ ХӨСӘЕН ЯМАШЕВ

Илдус Заһидуллин

XX гасыр башында, Беренче рус инкыйлабы елларында татар элитасы сәясәт мәйданына керә, иҗтимагый хәрәкәт тә сәясиләшә. Шул чорда берничә татар большевигы, ташбасма мөмкинлекләрен киң файдаланып, мөселманнарның сәяси аңын үстерүгә зур өлеш кертә. Араларында татар большевиклары юлбашчысы Хөсәен Ямашев та була. 1912 елда Габдулла Тукай, аның якты рухына багышлап, «Хөрмәтле Хөсәен ядкәре» исемле мәрсия яза һәм аны халык бәхете өчен көрәшкән изге кеше дип атый.

УКУ ЕЛЛАРЫ

Хөсәен Ямашев 1882 елның 6 гыйнварында Казанда, Яңа Татар бистәсендә дөньяга килә. Әтисе Хәсән улы Минһаҗетдин Саратов губернасы Кузнецк өязе Кече Труя авылыннан чыккан сәүдәгәр була. 1870 елда гаилә Новоузенск шәһәреннән Казанга күченә. Әтисе улын башта кадими «Мәрҗания» мәдрәсәсенә укырга бирә, 2-3 елдан соң «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә күчерә. 7 ел белем туплагаганнан соң, алга таба муллалыкка укырга теләмичә, Хөсәен мәдрәсәдән китә. Егет башлангыч рус-татар мәктәбе мөгаллимнәре әзерли торган Казан Татар укытучылар мәктәбенә (КТУМ) керергә уйлый. Әмма аның бу карарын әтисе хупламый, рөхсәтен бирми.

Шулай да Хөсәен әтисе белән русча уку турында бәхәстә «җиңә». Ләкин бу вакытка имтиханнар тәмамлану сәбәпле, сәүдәгәргә бердәнбер ир баласын урнаштыруны үтенеп, башта КТУМ инспекторына, тискәре җавап алгач, Казан уку-укыту округы попечителе исеменә гариза язарга туры килә. Ниһаять, Хөсәенне 1897 елның 1 декабреннән иреклe, үз хисабына укучы итеп укытучылар мәктәбенә кабул итәләр. Русча начар белүе һәм укырга соңга калып керүе үзен сиздерә – егет беренче сыйныфта икенче елга утырып кала. 1 нче һәм 2 нче сыйныфларда физика түгәрәгенә яратып йөри. Ә менә ислам дине дәресләрендә, атеистик фикерләр әйтеп, еш кына мөгаллим белән сүзгә килә. 3 нче сыйныфны тәмамлагач, 5 укучы, шул исәптән Хөсәен дә, дин сабагыннан имтиханда җавап бирүдән баш тарта. Ул көз көне кабат имтихан тапшырып кына укуын дәвам итә. Хөсәен укыган төркемдә педагогик практиканы 11 укучыдан 4 есе генә «бишле» билгесенә тапшыра, шуларның берсе Ямашев була.

КТУМда рус классик әдәбияты тирәнтен укытыла. Укучылар революцион демократлар Александр Герцен, Николай Чернышевский, Николай Добролюбов һ.б.ның әсәрләрен йотлыгып укый. Рус мәдәниятенә ияреп, татар яшьләре арасына социалистлар тәгълиматы үтеп керә. Яңа тәгълимат аларның дөньяга карашын тамырдан үзгәртә, сәяси аңын үстерә. XIX йөз ахырында биредә укучылар яшерен түгәрәк оештыра. Аның белән Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Гафур Коләхмәтов, Хөсәен Ямашев, Гомәр Терегулов җитәкчелек итә. Бу түгәрәк радикаль юнәлештәге «Тәрәккый» (Прогресс) исемле газета нәшер итә. 1901 елда татар укучы яшьләренең «Шәкертлек» исемле яшерен оешмасы төзелә. Хөсәен шушы оешманың актив әгъзасы булып китә. Оешманың максаты самодержавиене бәреп төшерү, милләтне берләштерү һәм мөстәкыйльлек өчен көрәшкә туплау дип билгеләнә. 1904 елны рус-япон сугышы башлангач, «Шәкертлек» оешмасы Гаяз Исхакый җитәкчелегендәге «Хөррият» исемле

Фотолар автордан алынды

милли-радикаль юнәлешле сәяси берлек итеп үзгәртелә. Татар укучы яшьләре, Россия җәмгыятендәге сословиеләрне җимереп, демократик ирекләргә ирешеп, социаль гаделлеккә килү, эшче һәм крестьяннар тормышын яхшырту турында хыяллана.

Хөсәен 1902 елның маенда КТУМны яхшы билгеләргә тәмамлый. Чистай шәһәре сәүдәгәре Зариф Бадамшинның бердәнбер кызы Хәдичәгә өйләнә.

Егет, мәктәпкә эшкә бармыйча, революцион эшчәнлеккә бирелә. Ямашев 1903 елдан Казан шәһәре социал-демократлар оешмасына әгъза булып керә.

Казанда татарлар арасында большевиклар идеологиясен таратырлык дәрәҗәдә йогынтылы сыйнфый төркемнәрнең саны зур булмый. Беренче чиратта КТУМда укучы яшьләр мондый карашлар белән мавыга. 1904 елда бирегә яшерен марксистик түгәрәк төзеп, Хөсәен шулар арасында пропаганда алып бара.

Шулай ук КТУМда бергә укыган иптәшләре белән дә араны суытмый, алар үткәргән чараларда катнаша килә. Хөсәен Ямашев 1905 елның 23 гыйнварында сәүдәгәр Хөсәенов йортында Габдерәшит Ибраһимов рәислегендә узган шәһәрнең 50 зыялысы катнашындагы җыелышта да була. 1905 елның августында Хөсәен, татар яшьләренә кушылып, Түбән Новгородка, Россия мөселманнарының 1 нче съездына бара.

Гаяз Исхакый, ул вакытларны искә төшереп, 1905 елгы инкыйлаб тәэсирендә «Шәкертлек» оешмасы һәм «Хөррият» берлеге таралды, алардан Әхтәмов, Терегулов һәм Ямашев җитәкчелегендә – социал-демократлар, Исхакый, Туктаров һәм Мөхәммәдьяров җитәкчелегендә – социалист-революционерлар һәм Садри Максуди, Йосыф Акчура, Г. Тупчыбашев җитәкчелегендә «Иттифак әл-мөслимин» партиясе үсеп чыкты, дип яза.

БЕРЕНЧЕ РУС ИНКЫЙЛАБЫ ЕЛЛАРЫНДА КАЗАНДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Беренче рус инкыйлабы алдыннан рус либераллары, банкетлар оештырып, мәҗлесләрдә сәяси мәсьәләләр тикшерүне оештыра. Хөсәен Ямашев та 1904 ел ахырында якшәмбе көннәрендә, Алафузов заводы татар эшчеләрен «Шәрык» номерына чәй мәҗлесенә чакырып, сәяси темаларга әңгәмәләр үткәрүне җайга сала.

Бу елларда листовка иң үтемле чара санала. Хөсәен яшерен фатирларда һәм үз өендә 6 гектограф урнаштыра. Большевикларның листовкаларын, марксистик әдәбиятны тәрҗемә итеп һәм яшерен җилем басмаларда прокламация һәм брошюралар чыгарып, татар эшчеләренә тарату эше оештырыла.

Ямашев Россия социал-демократик эшчеләр партиясенең (РСДЭП) Казан комите-

№ 15

اورال

غزتەنڭ بهاسى | يللق . . . . ۴ صوم | اوچ آيللق ۱ صوم ۲۰ تين
پوچته حقى برلن | يارطى يللق ۲ " | بر آيللق " ۴۰ "

Адресъ: Оренбургъ редакція „УРАЛЪ“.

„اورال“

«Урал» газетасының беренче бите.

тында татар төркемен җитәкли. 1905 елның гыйнвар-февраль айларында Казан эшчеләренең стачка хәрәкәте башлана. Моңа прокламацияләрне ике телдә тарату да нык ярдәм итә. Аларда 8 сәгатьлек эш көнен билгеләү, эш хакын 50%ка арттыру, штрафларны бетерү, эшчеләр белән яхшы мөгамәләдә булу таләп ителә. Ямашев, нигездә, Алафузов заводында агитация алып бара. Бирегә июль аенда булган масштаблы эш ташлауны (забастовканы) оештыруда аның да көче күп керә. 16 сентябрь–16 октябрь көннәрендә университет студентлары уздырган сходкаларда катнаша. Шуларның берсендә ясаган чыгышында, татар зыялыларына мөрәҗәгать итеп, аларны революция хәрәкәтендә актив катнашырга чакыра.

1905 ел 17 октябрендә демократик ирекләр бирү турында патша манифесты чыга.
Шул уңайдан 19 октябрь көнне Ямашев, Печән базары мәйданында татар эшче, шәкерт, һөнәрче һәм приказчикларын җыеп, митинг оештыра, киләчәктә эшчеләр хокукларын яклап кораллы көрәшкә өнди. Митингта катнашучылар, Крестовниковлар заводына килеп, кызыл әләм әлә, русча һәм татарча «Марсельеза» җырлый. Ноябрьнең икенче яртысында Алафузов заводы хезмәткәрләре өченче тапкыр эш ташлагач, Ямашев татар эшчеләре өчен махсус митинглар оештыра.

Хөсәен Ямашев, русча тәрҗемәләрдән тыш, үзе дә прокламацияләр яза. Аның «Казан татарларына» исемле листовкасында патша хөкүмәтенең кешеләрне талаштырырга, милләтләр арасына дошманлык агуы салырга, революцион халыкның көчен сындырырга тырышуы фаш ителә; «Шәкертләргә» исемлесендә самодержавие шартларында чын мәгъ-

Татар яшьләренең «Шимбә» әдәби түгәрәге әгъзалары. Утырганнар (сулдан уңга): Габдрахман Мостафин, Әминә Терегулова, Рәхимбәк Маликов; басканнар: Хәдичә Ямашева, Мәдинә Терегулова, Хөсәен Ямашев. 1911 ел.

рифәт, алгарыш була алмый, дигән фикер үткәрелә.

1905 елның декабрендә полиция 39 революционерны кулга ала, 50 урында тентү уздыра. Ямашев яшәгән йортта да тентү була. Хөсәен, кулга алынудан качып, башына парик, өстенә украин крестьяны киемен киеп, сеңлесе Хәдичә кияүдә булган Самара губернасы Бөгелмә өязе Әлмәт авылындагы Якуб гаиләсенә барып сыена. Бер атна чамасы мунчада яшеренеп торганнан соң, җизнәсе табып биргән ялган паспорт белән Уфага юл ала.

«УРАЛ» ГАЗЕТАСЫ МӨХӘРРИРЕ

Ямашев меньшевикларга каршы сәяси дискуссияләрдә чыгыш ясауны Уфада да дәвам итә, шулай ук мөселманнарны Думага сайлауларда катнашмаска өндәп йөри, сәяси прокламацияләр тәрҗемә итә, РСДЭП Уфа комитетында татар-башкорт төркемен җитәкли. Уфада татарча большевистик газета чыгару өчен партия кассасыннан акча бүлеп бирелә. Әмма шәһәрдә татар шрифтлары һәм полиграфик база булмау сәбәпле, газетаны Оренбургта бастырырга карар кабул ителә. Искечә стиль белән 1907 елның 4 гыйнварыннан атнага 2–3 тапкыр нәшер ителүче, конспирация максатында сәяси юнәлеше социал-демократик дип язылмаган большевистик «Урал» газетасы оештырыла. 24 нче санга кадәр аның рәсми нәшире – Тимерша Соловьев, калган саннарыныкы – Гомәр Терегулов, ә мөхәррире Хөсәеннең хәләл җефете Хәдичә Ямашева исәпләнә. 4 битлек «Урал» 27 апрельгә кадәр басыла. Барлыгы 31 саны дөнья күрә.

Шунысын әйтергә кирәк: Оренбург 1907 елда татар дөньясында төрле сәяси юнәлештәге вакытлы матбугат үзәге булып танылы. Биредә югарыда аталган газетадан тыш, либераль рухлы «Вакыт» газетасы, сатирик, иҗтимагый-сәяси «Карчыга» журналы, ислам дине кыйммәтләрен үзәккә куйган консерватив, аталык «Дин вә мәгыйшәт» журналы чыга.

Газетаның эчтәлеген билгеләүдә төп рольне Хөсәен Ямашев һәм революцион эшчәнлеге өчен Оренбургка сөрелгән Галимҗан Сәйфетдинов уйный. Баш мәкалә, күпчелекне тәшкил иткән авторсыз язмалар, шулай ук төрле псевдонимнар куеп бастырылган хәбәрләр алар тарафыннан языла.

«Урал»ның күпчелек рубрикалары ул заман милли матбугаты өчен яңалык була: «Оренбург хәбәрләре», «Чит мәмләкәт хәбәрләре», «Тирәяк хәбәрләре», «Үз мөхәррирләребездән», «Соңгы хәбәрләр», «Дума тирәсендә», «Думага даир», «Идарәгә хатлар», «Эшчеләр хәленнән», «Шәкертләр хәле», «Партияләр хәленнән», «Думага сораулар».

Газетада яктыртылган төп темалар сәяси вакыйгалар, беренче чиратта Дәүләт Думасы белән бәйле була дисәк, дөреслеккә туры килер. Редакция татар либераллары матбугаты булган «Вакыт» һәм «Йолдыз» газеталары, татар социалистлары органы «Таң йолдызы» белән бәхәсләшә. Шул ук вакытта, «иттифакчыларга» кушылып, хакимиятнең гарәп имлясыннан кириллицага күчү планына каршы чыга. Хакимиятне халык үз кулына алгач кына, милли мәсьәләне уңай хәл итеп була, дип саный. Хатын-кызларның тигез хокуклылыгын яклап, басма «Дин вә мәгыйшәт» журналында басылган тенденциоз мәкаләләр белән бәхәскә керә, динчеләрне, милләтчеләрне тәнкыйть утына тота.

Зурлыгы буенча «Искра» газетасына охшаш «Урал» хакимияткә каршы мәкаләләр бастырган өчен ябыла. Редакция хезмәткәрләре татар, башкорт, казахларның сәяси аңын үстерү юнә-

лешендә 3 ай ярым армый-талмый эшләргә өлгерә, аннары суд җаваплылыгына тартыла. Тикшерү эше 1909 елга кадәр дәвам итә.

ИНКЫЙЛАБТАН СОҢГЫ ЕЛЛАР

Ямашев 1907 елның 9 маенда Оренбургтан Уральскига китә, аннан партия эше белән тирә-якта сәнәгать оешмалары күп булган Чиләбе шәһәренә, Чиләбедән Уфа каласына бара һәм, ниһаять, Казанга кайта.

19 сентябрьдән университетның юридик факультетына ирекле тыңлаучы булып укырга керә. Берничә лекция тыңлагач ук, Хөсәен туберкулез белән җитди авырый башлый, сәяси эшчәнлеген туктатып торырга мәҗбүр була. 1908 елның мартында иптәшләре җыйган акчага Сухумига барып дәвалана.

Казанга кайткан елны «тамгалы» Ямашевлар белән аралашучы татар зыялылары күп булмый. Яннарына, нигездә, Галиәсгар Камал, Гафур Коләхмәтов һәм Габдулла Тукай килеп йөри.

Хөсәен хатыны Хәдичәгә Котованың шәхси кызлар гимназиясендә экстерн тәртибендә имтихан бирергә әзерләнергә ярдәм итә. Хәләл җефете, 1910 елда урта белем турында таныклык алгач, ике еллык курсларда укый һәм татар хатын-кызлары арасында беренче теш табибы шәһадәтнамәсенә ия була.

Хөсәен Ямашев үзе дә 1911 елда экстерн тәртибендә шәһәрнең 1 нче ирләр гимназиясен тәмамлый. Казан университетының юридик факультетына укырга кереп, биредә студентларның марксистик түгәрәген оештыра.

Революциядән соңгы елларда илдә реакция нык көчәя, сәяси эшчәнлек алып бару кыенлаша. Бу елларда Хөсәен татар яшьләре һәм зыялылары белән еш аралаша. Аның «Шимбә» татар яшьләре әдәби түгәрәгенә йөрүчеләр белән төшкән фотосы саклана. Галимнәр аның Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Галиәсгар Камал, Ш. Мөхәммәдов иҗатларына зур йогынты ясаганлыгын ассызыклый. Әйтик, 1911 елны соңгы тапкыр Уфага баргач, Ямашев Мәҗит Гафури белән очраша. Шагыйрьнең иң уңышлы шигырьләреннән берсе дип ул «1906 елдан 1907 елга васыять» әсәрен саный, киләчәктә халык мәнфәгатьләрен алга куеп иҗат итәргә киңәш бирә.

Хөсәен Ямашев 1912 елның 13 мартында 30 яшендә вафат була. Аны җирләү демократик яшьләрнең туплану чарасына әверелә. Галиәсгар Камал бу вакыйганы тарих өчен теркәп калдыра: «Хөсәен әфәндене махсус ясалган гүзәл рәшәткәле җеназа агачына салып, өстен зәңгәр хәтфә белән төрделәр. Аның өстенә үзенең иптәшләре һәм дуслары тарафыннан тәкъдим ителгән чын чәчкәләр вә гөлләрне тезделәр. Җеназаны күтәреп чыктылар. Университет ишек алдында бөяләп торган халык дәрьясы хәрәкәткә килде. Дәрелфөнунның киң капкаларына халык сыймый, бер-берсен тыгызлап чыгалар иде. Мәйданга барып җиткәнче озатучылар дәхи дә артты. [...] Мәйданда [...], һичшиксез, ике мең кадәр кеше бар иде». Беренче татар революционерының җеназасы өстенә студентларның хокук түгәрәге идарәсе тарафыннан куелган тасмада «Ул үз халкының якты киләчәге булачагына ышану һәм өмет белән китте» дип язылган була.


"اورال" کتبخانه‌سی
ترلی ملتلرنی جبرلاو کمگه کیرک ؟
بهاسی 4 تین.
№ 4
روسچه‌دن ترجمه قیلندی
پرالیتاری.
اورنبورغ.
کریموف، حسینوف وشرکاسی‌نڭ پاراۋای
باصمه خانه‌سی
۱۹۰۷

«Урал» газетасына кушымта рәвешендә бушка таратылган «Төрле милләтләрне җәберләү кемгә кирәк?» исемле брошюра тышлыгы.

Ямашевлар гаиләсе. Сулдан уңга: Хөсәеннең әнисе Бибифатыйма Хөсәен, сеңлесе Хәдичә һәм апасы Рокыя балалары белән.

МОРДВАЧА ТӨНЬЯК ГАИЛӘ БИЗНЕСЫ

Юлия Ульянченконың бер-берсеннән бик ерак рухтагы ике гаилә бизнесы бар. Ире Дмитрий белән уртак эшләре – түшәм тарттыру белән шөгыльләнә торган «Пифагор» компаниясе, Чаллыда бик билгеле ширкәт ул. Бу төр эшмәкәрлектә әллә ни гаҗәпләнерлек нәрсә юк. Ә менә икенчесе исә күпкә кызыклырак, шуңа күрә без «Төньяк сулышы» дип аталган гаилә этномәдәни паркына юл тотабыз.

Чаллыдан ераклыгына карап фикер йөрткәндә, ул кадәр төньяк та түгел, Мальцево авылында урнашкан паркка шәһәрдән ярты сәгатьтә барып җитәсең. Әмма 28 градуслы эсседә төньяк сулышы әлегә бер дә сизелми.

СЕБЕР ҺИЧ ТӘ ЕРАК ТҮГЕЛ

– Бездә анда төньяк боланнары да, төньяк этләре дә бар, – дип сөйли Юлия Викторовна. – Кышын җигүле этләрдә дә йөрергә була. Ә җәй көне андый җәнлекләр белән аралашу үзе генә дә безнең паркка килүчеләргә, бигрәк тә балаларга әйтеп бетергесез шатлык-куаныч китерә. Кунаклар өчен без, актерлар чакырып, төрле сый-нигъмәтле, җыр биюле тематик бәйрәмнәр, мәсәлән, Болан көне уздырабыз. Яңа ел тамашалары куябыз, балаларның туган көннәрен билгеләп үтәбез. Өлкәннәр еш кына безнең этнопаркта корпоратив бәйрәмнәр уздыра. Кияү егетләре кәләшләренә оригиналь рәвештә тәкъдим ясау өчен килә...

ТӨНЬЯК БОЛАННАРЫ БЕЛӘН ҖЫЛЫ КҮРЕШҮ

Безне фермада чып-чын төньяк боланнары каршы ала, үзләрен сыйпарга теләүчеләрнең кулларына юеш борыннары белән сырпаланып, сәлам бирә алар.

– Мондый боланнар якын тирәдәге иң матурлардан саналган Ижау, Мәскәү зоопаркларында да юк, – ди хуҗабикә. – Ә менә безне үз иттеләр – инде өченче ел нәни болан белән сөендерәләр. Әле кичә генә бер болан кызы туды...

– Аларга монда эссе түгелме соң?

– Җәен, әлбәттә, эссе. Ләкин җәй Себердә дә бар, – дип аңлата Юлия. – Ә, гомумән алганда, ике йөз ел элек бу урыннар төньяк боланнары яши торган зона булган. Алар тундра, урман-тундра һәм урман боланнарына бүленә бит. Индустриальләштерү, цивилизация моннан кысрыклап чыгарганчы, биредә урман боланнары яшәгән.

– Төньяк сездә ник шундый кызыксыну уятты?

– Чөнки Төньяк дигәндә, Россия күзаллана. Без күбрәк төньяк иле. Күп кенә төньяк халыклар, мәсәлән, безнең мордвалар шул ук фин-угор кабиләләреннән чыккан. Шуңа күрә безгә алар белән аралашу бик кызык, төньяк шәһәрләрдәге партнерларыбыз белән бик җылы мөнәсәбәтләрдә эш алып барабыз. Быел, мәсәлән, Сабантуй кебек үк киң колач белән бәйрәм итәлә торган Төньяк болань көненә Салехардка бардык. Сабантуйдан аермалы буларак, ул кышын үткәрелә. Февральдән апрельгә кадәр Төньяк боланы көне авылларда, аннары районнарда, аннары Салехардта уза. Милли уеннар, ярышлар, төрле узышлар... Җәй көне бездә ат чабышы булса, йә машинада җилдерсәләр, анда снегоходларда, җигүле боланнарда узышалар. Җирле колорит сизелеп торган, бик матур һәм кызык бәйрәм!

БЭМБИМЫ, ВАЛЕРАМЫ?

– Балаларым болан сорады – бөтенесе дә әнә шуннан башланды. Әлбәттә, бэмби (Европа кәҗә-боланы) иң матуры һәм сөйкемлесе санала, ләкин төньяк

Фото: Александр Ефремов. РЕКЛАМА

Валера — чибәр болан егете ул! Яңа мөгезләрен апрельдә генә үстерә башлаган иде, инде әнә ниндиләр үсеп чыккан!

боланы да калышмый. Без төньякныкын алырга булдык. Аннары, ялгызына күңелсез булыр, дип уйладык та тагын икене алдык. Башта безгә ике ана болан алып кайттылар. Аннары менә бу чибәр болан егете Валераны китерделәр. Бераздан нәни болан балалары дөньяга килә башлады. Шулай итеп, тулы бер ферма пәйда булды, аннары инде этнопарк ясау фикере туды. Һәм менә шулай итеп бүген этнопаркыбыз бар, – ди Юлия Викторовна, тирә-юньдәге утарга, хайваннар өчен салынган корылмаларга ишарәләп. Зәңгәргә буялган бу кечкенә өйләр кыш көне ак кар фонында бик матур күренәдер. – Хәзер бездә туристлар күп. Балалы гаиләләр килә, боланнарны кулдан ягель белән сыйлыйлар, без аны елына берничә тонна әзерлибез. Киптерәбез дә, туңдырып та куябыз. Шуңа күрә безнең төньяк кунаклары табигать кушканча туклана.

РУС ТОКЫМНАРЫ

Икенче утарда, түземсезләнеп койрыкларын болгый-болгый, төньяк этләре көтеп йөри. Юлия Викторовна кечкенә капканы ачуга, этләр өере, шатланып, аның кочагына ташлана – сагынганнар!

– Якут лайкалары ул – әлеге рус токымы аздан гына юкка чыкмый калган. Болар иң яхшы этләр, – дип, горурланып сөйли хуҗабикә. Сөенечтән биеп торган хаски һәм лайкаларның бер өлешен безнең кочакка күчергәч, сүзен дәвам итә: – 2000 елда инициатива төркеме әлеге токымны торгызу белән шөгыльләнә башлый. Һәм егерме ел эчендә токым Россия генә түгел, Бөтендөнья кинологлар оешмасы тарафыннан да танылды. Ә бездә якут лайкасының иң яхшы вәкилләре яши. Менә Индиго Мәскәүдә узган «Евразия» күргәзмәсендә икенче урынны яулады. Беренче урында аның атасы иде. Ә Лара өченче булды.

Этләребез матур гына түгел, алар чанага җигелеп, тартып та йөриләр. Олы кызым Ксения җигүле этләр спорты белән шөгыльләнә, һәм бу лайкалар ярышларда даими катнашып тора. Быел безгә биш көчек – җигүле этләр спорты өчен чыгарылган төр вәкилләре килде. Җигүле этләрдә ярышу белән шөгыльләнүче кешеләр белә булыр: «менә шушысы» дигәнне сайлап алу өчен, 100 ләп этне карап-тик-

— Болар иң яхшы этләр, – ди хуҗабикә, горурланып.



шереп чыгарга кирәк. Маэмай спортка ике яшьтә генә әзер була.

Ксения быел мәктәпне тәмамлый һәм ветеринар булырга тели. Аның карарын тулысынча хуплыйм. Ул барысын да булдырачак. Инде хәзер үк хайваннарның ветеринария өлкәсенә караган мәшәкатьләрен – бер-берсен тешләсәләр, тырналсалар, прививка ясарга, бәйләргә кирәк булса, барысын да Ксения кайгырта.

КАНИС-ТЕРАПИЯ

– Без «Игелек планетасы» фонды белән бик күп эшлибез, хайваннарны ашатырга, алар белән аралашырга, кочаклашырга дип, безгә ДЦПлы балалар килә. «Чудо дети» фонды аутизм кебек тайпылышлары булган балаларны китерә. Андыйларга хайваннар белән аралашу, элемтә булдыру аеруча кирәк. Без яман шеш авырулы кешеләр җәмгыяте белән дә эшлибез. Бу кешеләрнең барысы да безгә тулысынча бушлай йөри. Без канистерапия үзәген булдырырга хыяллана быз, бу – этләр ярдәмендә дәвалау һәм тернәкләндерү дигән сүз. Бүген безнең төбәктә моның белән бер генә кеше шөгыльләнә, анда да нибары бер эт белән. Ә, мәсәлән, Америкада бу терапия ысулы шактый киң таралган. Һәм без дә монда күңел ачу урыны гына түгел, савыгу-тернәкләнү үзәге дә булуын телибез. Моның әһәмиятен балалар белән генә бәйләп карау дөрес булмас, чөнки алар үсә, ә авырулары, ни кызганыч, еш кына кала бирә.

УҢАЙ ХИС-КИЧЕРЕШЛӘР КАДЕРЕ

Әлбәттә, бизнесның икенче төрен ныграк яратам. Хәер, мин тарттырылма түшәмнәр турында да күп кызыклы нәрсәләр сөйли алам. Әмма фермабыз – зоотерапия урыны ул. Төзелеш эшләре вакытында, мәсәлән, мәрхәмәтсезлеккә дә тарыйсың, тупаслык белән дә очрашасың, төрле ызгыш-талашлы хәлләр дә була. Ә монда килеп, көрәк-тырмалар белән болан абзарын чистартырга кергәч, боланнар сине борыннары белән төрткәләргә керешә, һәм менә шулчакта зоотерапия башлана да – бу вакытта син тирә-яктагы бөтен нәрсәне онытып тора аласың. Ә дөньядан онытып тору һәркемнең хәленнән килми, күп кенә эшмәкәрләр өчен бу – зур проблема. Кафе-рестораннар, диңгездә ял итү үзеңне рухи тигезлектә тоярлык күңел тынычлыгы халәтен бирә алмый. Ә монда була. Шуңа күрә уңай хис-кичерешләрнең бәясе берничә тапкыр арта. Бу ферма бөтен гаиләбезне тулысынча тигезләде. Ирем яраткан эше белән шөгыльләнә ала – нидер шомарту, кисү, кадаклап кую кебек эшләр аңа һәрвакыт ошый иде. Мин исә кызлар белән хайваннар янында кайнашам, һәм бу – үзе бер бәхет: нинди халәттә, ниди кәефтә булуыбызга карамастан, алар безне һәрвакыт шатланып каршы ала. Әйтик, менә кәҗәләр безне үлеп ярата. Этләр, үзегез күрдегез, ихлас сөенүләрен күрсәтеп, баштанаяк ялап чыгалар. Мондый шатлык-сөенечләр бик кадерле.

УСАЛ КУСИК

Вольердан вольерга безне шундый дустанә холыклы бик зур йонлач эт озата бара.

– Кусик бу, – дип таныштыра йөнтәс алып белән хуҗабикәсе. – Кара рус терьеры. Совет заманының иң шәп токымнарыннан. Аны 40 нчы елларда чыгаралар, ә 60 нчы елларда шуның өчен безне бөтен дөнья алкышлый. Мондый токымны бүтән беркем дә чыгара алмаган. Бу токым вәкилләре шактый усал санала, ләкин безнең Кусик бөтен кешене ярата, хәер, аның үзен дә яраталар.

Бу сүзләрне дәлилләп, Кусик бөтен кешене зур, кытыршы алсу теле белән үбеп чыга. Һәм фотосессия өчен эскәмиягә менеп утыра.

– Зоотерапия порциясен кабул иттек, ахры.

– Үзебезнең рус токымнарын яратам, – дип елмая Юлия Викторовна. – Без аларны белергә, кайгыртырга тиеш, балаларыбызда да шундый мәхәббәт тәрбияләргә һәм аларның белем дәрәҗәсен күтәрергә – илебездә башка беркайда да булмаган нәрсәләр барлыгын күрсәтергә кирәк.

Менә тагын бер гаҗәеп эт – самоед лайкасы – кечкенә ак аюны хәтерләткән Лаки. Өченче ел, балалаганда, аның энисе үлде, һәм без аны имезлектән ашаттык, тартмага салып, үзебез белән бөтен җирдә йөрттек, чөнки андый көчекне ике сәгать саен ашатырга кирәк. Ул да борын-борыннан русныкы саналган токым вәкиле. Үз вакытында алар Тубыл елгасы янындагы гаять зур территориядә яшәгән, популяция саны 15 мең эткә кадәр җиткән.

Бу эт тугры дус та, аучы да, сакчы да. Европада аны бик югары бәялиләр.

Хуҗабикә, иелеп, Лакиның колагына аңлаешсыз телдә ниндидер ягымлы сүз әйтә.

– Нинди телдә бу?

ЯШЕРЕН ЭЛЬФЛАР ТЕЛЕ

– Бу яшерен тел, – дип көлә Юлия Викторовна, – мордва теле. Мин дүртенче буын мордва. Әти-әнием Башкортостанда мордва авылында яшәгән, бирегә КАМАЗ төзелешенә килгәннәр. Шуңа күрә мордвачаны мин балачактан ишетеп үстем, ба-

рысын да аңлыйм, тик камил дәрәҗәдә сөйләшә алмыйм.

Алабуга районының мордва диаспорасын җитәклим. Чаллы бүлекчәсе белән хезмәттәшлек итәбез. Мордваларны үз тирәбездә җыярга, телебез һәм гореф-гадәтләребез вакыт чоңгылына төшеп югалмасын өчен, милләттәшләребезне төрлечә кызыксындырырга тырышабыз. Андый проблема барлык халыкларга да кагыла. Безнең бурыч – гаилә телен саклап калу, ә дәүләт масштабындагы бурыч – әдәби телне саклап калу һәм туган телебездә белем алырга мөмкинлек бирү. Чөнки үз телеңдә уку, сөйләшү милләтнең кием, гореф-гадәтләр кебек үк, бер билгесе булып тора. Без бу территориядә күп мең еллар дәвамында шул гореф-гадәтләрне саклап яшәдек. Әмма халыклар арасында котылгысыз рәвештә үзара якынаю бара, катнаш никахлар арта һәм телне саклау катлаулана. Ләкин бу эш кирәк. Безнең гаиләдә моның белән эби шөгыльләнә. Мин аңа, балаларым белән мордвача гына сөйләш, дидем, һәм алар туган телләрендә сөйләшергә бик тиз өйрәнде. Балалар мордвачаны эльфлар теле дип атый һәм яшерен тел дип саный. Анда серләшү бик уңайлы. Кибеттә касса янында мордвача үзара бер-ике сүз сөйләшеп аласың – беркем дә аңламый. Ялда чакта әни һәрвакыт берәр нәрсәне мордвача шәрехләп китә – без генә аңлыйбыз. Яныма дус кызларым килгәч, әнинең колагыма гына әйтер сүзе бер икән, ул мордва теленә күчә – колакка пышылдарга да кирәкми.

Әлбәттә, үзенчәлекле тел. Мәсәлән, әни мордва телендә – авай, әти – тятяй, эби – бабай (нәкъ татарчадагы бабай кебек), ә минә бабай будей була.

ЧЫП-ЧЫН МАТРИАРХАТ

– Яшерен эльф телендә сөйләшүчеләр нindирәк халык икән?

– Классик мордва гаиләсендә һәрвакыт матриархат хөкем сөрә. Гел шулай булган. Хатын-кыз һәрвакыт баш.

– Ә ирләр моның белән ризалашамы?

– Ирләр бик уңайлы яши. Аларны хөрмәт итәләр, башка халыклардагы кебек үк, ир-ат һәм хатын-кызларның бурыч-вазыйфалары бүленгән. Әмма төп карарны хатын-кыз кабул итә. Юк, без амазонкалар түгел! Без тиешле карарны кабул итә белүче акыллы хатын-кызлар гына.

Милли төсләребез – ак һәм кызыл. Мордва хатын-кызлары кычкырып торган макияж ярата – битләрдә кызыл кершән, җете кызыл иннек, тырнакта кызыл лак...

Мордвалар борын-борыннан урман халкы булган. Христианлаштыру процессы җиңел узган, ләкин шул ук вакытта алар күпмедер мәҗүси булып калган – мордвалар табигатьне һәм табигый күренешләрен зурлый. Ягъни без христиан бәйрәмнәрен билгеләп үтәбез, Троица – иң яраткан бәйрәмебез. Тик әнием белән урманга керсәк, ул: «Исәнме, Урман ана!» – дип әйтә, аннан: «Рәхмәт, Урман ана!» – дип чыга. Табигатькә кагылышлы бөтен нәрсә мордваларда хатын-кыз җенесеннән. Урман, җир, агач... Бу – матриархат белән бәйле мәсьәлә.

УҢЫШ СЕРЕ

– Шушы этле-боланлы хуҗалыкны ничек карап-тәрбияләп тора аласыз?

– Бизнесыбызның уңыш сере – минем гаиләм. Бу – төп нигез. Эшләр ал да гөл булганда да, начар булганда да, гаиләм ярдәменнән ташламаячак. Гаиләм уңышларыма чын күңелдән шатлана, ниндидем эшем килеп чыкмаганда, булыша. Әти-әнием барлык теләкниятләремне хуплап, күтәреп алды, хәтта иң юләр булып күренгәннәрен дә. Шуңа күрә бар эшем дә уңышлы килеп чыкты. Күз алдына китереп карагыз әле, әниегез янына килеп: «Әни, мин төньяк боланнары алдым. Шуларны яшәтер өчен, синең җир кишәрлегеңне алсам ярыймы?» – дип сүз башлыйсыз. Һәр әни кеше дә мондый эштә булышырга атлыгып тормаячак. Ул миннән: «Бу сиңа нигә кирәк?» – дип сорады. Аңлатып бирдем. Нәтиҗәне үзегез күрәсез.

Бервакыт каядыр китәргә туры килде һәм әти-әниләргә этләрне ашатырга куштык. Ә алар 20 җан бит! Соңыннан алар: «Ашатырга килдек тә аптырап торабыз: кайсының ашаганын, кайсының ашамаганын ничек белербез икән соң? Кер каптыргычлары алдык та, ашаган берсенең йонына эләктерә бардык...» – дип сөйләделәр.

Менә шундый минем әти-әнием – зирәк тә, тапкыр да.

Без бизнесыбызны 2008 елда башладык. Кызым кечкенә иде әле. Әти-әни булышты. Фермада эшләнгән бөтен нәрсәгә әтинең кулы кергән, ул барысын да булдыра. Су туңдымы, этигә шалтыратам, нәрсәдер кисәргә-вакларга кирәкме – тагын әти. Хәзер әнинең дүрт оныгы бар, алар әбиләре яныннан беркайчан да китмәскә риза. Каникул вакытында анда безнең балалар гына түгел, дусларымның балалары да яши – былтыр 10 кеше тордылар. Әбидән соң алар өйләренә бик мөстәкыйль кешеләр булып кайтып китә: үзләренә бутербродлар әзерлиләр, җыештыралар, нәрсә ярагаНын, нәрсә ярамаганын беләләр. Бабалары аларны велосипедта йөрергә өйрәтә, аларга дип карбыз үстерә, җиләкләр җитешергә дә өлгерми...

Гаилә – бар нәрсәнең нигезе. Тормышымдагы бүләкләрне эшемдәге уңыш рәвешендә генә түгел, бөтен булган нәрсәләребез рәвешендә алганым өчен, шушы дөньяга, күккә, Аллаһка рәхмәтемне җиткерәм. Олы кызым 9 сыйныфтан соң каникулларында гел фермада – хайваннарны карый, дәвалый. Кече кызым һәм туганнан туган энеләрем көчекләр өчен җаваплы, нәни эт балаларына социализация кирәк. Әни белән әти – ышанычлы тылым. Иремнең әти-әнисе һәм аның абыйсы да безгә ярдәм итеп, эшебезне хуплап торалар. Без барыбыз бергә, бер-беребез өчен җаваплы – теләсә нинди бизнесның уңышы әнә шунда, дип саныйм.

Уңай хис-кичерешләр һәм истәлеккә – Кусик белән фото.

КАРМЫШ: КҮМӘК КӨЧ ТАУ КҮЧЕРӘ





Фото: Александр Ефремов

КАРМЫШ

Чирмешән районының Кармыш авылына килеп кергәч тә, каршыга очраган бер машинаны туктатып, авыл җирлеге идарәсен сорадык. Рульдәге егет, ике дә уйламыйча, кире борылды да безгә үзе артыннан барырга кушты. Әлбәттә, ул безнең Казаннан килгән журналистлар икәнлекне белмәде. Авыл җирлеге идарәсенә килеп җиткәч: «Менә ул», – дип елмайды. Әле авылның бер кешесен күрмәсәк тә, шул мизгелдә: «Биредә мондый ачык, ярдәмчел кешеләр күпме икән?» – дигән уй килде. Бик тиздән әлеге сорауга җавап та табылды.

Руфия Фазылова

БАКЧАНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ ӨМЕТЛЕ

Кармыш зур авыллар рәтендә йөрми – 126 хуҗалык бар, 291 кеше яши. Биредә чын мәгънәсендә җир кешеләре гомер итә: халыкта гына 172 савым сыеры бар, фермерларда исә мөгезле эре терлек саны 500 дән артык. Ләкин минем өчен иң шаккаткыч яңалык шул булды: авылга инвесторны кертмәгәннәр! Кыюрак кешеләр җирләрне бүлешеп, фермерлык эше белән шөгыльләнә башлаган.

Тагын бер сөенечле күренеш: биредә яшь гаиләләр күп. Шулай булгач, балалар да шактый. Кармышта төп белем бирү мәктәбе, балалар бакчасы гөрләп эшләп тора. Мәктәпне быел утыз өч бала тәмамласа, бакчага ун бала йөри икән. Белем йортында укучылар каникулга таралган, ә менә бакча эшли иде. Шуның өчен дә анда кереп, Кармыш авылының нәниләре белән танышып чыктык.

1
Тыштан караганда бакча әллә ни күзгә ташланмый, ләкин эчтән ул балкып тора.

Тыштан караганда бакча әллә ни күзгә ташланмый, ләкин эчтән ул балкып тора. 2016 елда ике катлы бинага капиталь төзекләндерү үткәрелгән. Әнә шул чагында заманча җиһазлар да кайтарылган, диварларга матур рәсемнәр ясалган, махсус пәрдәләр тектерелгән. Башкаладагы кайбер бакчаларның борынына чиертә ул.

– Нәниләрне яшь ярымнан алабыз, – ди Кармыш балалар бакчасы мөдире Гөлия Гайфуллина. – Берничә ел элек хәтта алты айлык, яше тулмаган балаларны да карадык. Әниләренә эшкә чыгарга кирәк булганда, калдыралар, аннан бергәләп үсәләр. Бездә бер генә төркем, яшькә карап бүлү юк. Элегрәк ике төркем ачарга дигән сүз булган иде, ул чорда балалар саны күп иде. Хәзер андый ихтыяҗ юк.

– Ә быел бакчага ничә бала киләчәк? – дим.

– Ике бала чыгып китте, тагын ике килә. Моңа кадәр гел уналты, унҗиде бала йөрде. Узган ел сигез баланы мәктәпкә озаттык та, әнә шулай ун гына калды. Авылда яшь гаиләләр күп, бакчаның киләчәге өметле, Алла боерса.

Әлеге бина 1982 елда салынган булган. Әйткәнемчә, ике катлы ул. Заманында аның беренче катында мәктәп ашханәсе булган. Хәзер исә беренче катта почта, авыл җирлеге идарәсе урнашкан. (Әлбәттә, ишекләр аерым).

– Конкурсларда гел катнашабыз, призлы урыннар алабыз, – диде бакча мөдире. – Балалар белән гел татарча сөйләшәбез, мәктәпкәчә әзерләү дә татарча бара. Кармыш төп белем бирү мәктәбендә дә ана телендә укыйлар. Якын-тирәдә чуваш авыллары шактый. Без исә Чирмешән районындагы татарлыкны саклый торган авылларның берсе, шуның өчен дә кунаклар еш килә.

«КИЛЕНЕМ АРТЫК ЯХШЫ»

Авылның иң матур гаиләсе белән таныштык. Вафиннар өч буын бергә яши икән. Йорттагы иң өлкән кеше Шәриза абый 90 яшен тутырган. Җәмәгате Разыя апага исә сиксән биш яшь. Икенче буын – әби белән бабайның улы Ришат, аның җәмәгате Гөлүсә һәм төпчек уллары. Шәриза бабай белән Разыя әби күптән түгел генә тимер туйларын билгеләп үткән – 65 ел бергә тату гомер итәләр икән.

– Район башлыгыбыз Рамил Тәлгать улы Айбатов, бергә озак гомер итүчеләрне җыеп, бик матур бәйрәм ясады. Шулай олылагач, күңел булды, – диде бабакай.

Шәриза абый белән Разыя апа алты бала – өч кыз, өч малай тәрбияләп үстергән. Ни кызганыч, өч улларының берсе 21 яшендә мәрхүм булган. Унбер онык, сигез оныкчыкның яраткан әби белән бабасы алар. Балалары барысы да шәһәрдә төпләнгән, ә менә бишенче уллары Ришат абый туган авылын ташлап китмәгән. Сөйгәне, шулай ук Кармыш кызы Гөлүсә белән гаилә корып, өч ул үстергәннәр.

Гаиләнең иң өлкән кешесе буларак, башта Шәриза абый белән сөйләштек. Бабакай, үсмер еллары Бөек Ватан сугышына туры килгәнгә, унөч яшеннән колхоз эшенә чыккан. Иген чәчү, җыю – ир-ат кулы кирәк булган бөтен эшне яшьтәшләре белән җигелеп тарткан.

– 1952 елда тракторга утырдым, – диде Шәриза абый. – Лаеклы ялга чыкканчы, кырык биш ел шулай рульдә булдым. Гел чылбырлы тракторда эшләдем. Җәй көне исә комбайнга утыра идем. Малайларның өчесе дә минем белән кырда үсте – комбайнчы ярдәмчесе булып йөрделәр. Безнең гаиләдә йоклап яту дигән әйбер булмады.

– Ә мәктәптә укыдыгызмы? – дим.

– Укыдык. Җиде еллык мәктәп үзебезнең Кармышта иде. Сигезенчегә Лашманга йөрделәр, бик сирәкләре генә инде. Кая, ул чагында уку кайгысы идеме? Әнә, Разыя ярты еллар чамасы Лашманда укыган, аннан барыбер мәктәпне ташлап кайткан.

– Бабай белә, – дип көлде Разыя апа. – Әйе, этидән бик гозерләп сорап, Лашман мәктәбенә бардым. 1954 ел иде ул. Эти үзе белемле кеше булгач, каршы килмәде. Лашманда бер йортка торырга кердек, ә ялларда өйгә кайта идек. Ике авыл арасы егерме чакрым, шуны җәяү атларга кирәк. Яңа елга кадәр шулай интектем дә, ташлап кайтып киттем. Аннары колхозга эшкә кердем. Әнә шулай укымыйча калынды инде.

Разыя апа егерме биш ел кайнанасы белән яшәгән. Ә килене белән утыз елдан артык гомер итә. Миңа ул бу йортның кояшы кебек тоелды: гел елмаеп тора. Ә килене турында әйткәндә, тагын да нурлана: «Киленем артык әйбәт», – дип ничә тапкыр әйткәндер.

– Сезнең яклар уңган бит, суган, яшелчә күпләп үстергәннәр. Сезгә дә тәтедеме ул? – дим Разыя апага.

– Тәтеде. Безнең бәхетсезлеккә, чөгендер чыкты. Кармышта аны 1957 елда чәчә башладылар. Мин инде анда кияүдә идем. Беренче елны һәр гаиләгә гектар ярым бүлеп бирсәләр, аннан өчәр гектар утадык. Без генә түгел, авылның бөтен хатын-кызы, бала-чагасы шуның белән чиләнде. Яшь балаларны чөгендер басуында үстердек. Җәй буе басудан кайтып кермәдек. Көзгә чөгендерләрне чистартып, машинага төяп җибәрәсең. Кар яуганчы сузыла инде ул. Әле ярый балалар кул арасына керә башлады, алар булышты. Аллага шөкер дим, безнең балалар бик тәртипле, эшкә дә, укуга да сәләтле булдылар.

Вафиннарның йорты иркен. Кайчагында бирегә утызар кеше кайта икән. Төп йортка барысы да җыела.

– Аерым йорт салу теләге булмады? – дидем безнең сөйләшүне сабыр гына тыңлап утырган Гөлүсә апага.

– Булмады. Бу йортны мин килен булып килгәч салдык. Туйдан соң Ришат белән йортның нигезен казырга чыгып киттек, ба-

2

Шәриза абый белән Разыя апа күптән түгел генә тимер туйларын билгеләп үткән.

3

– Әле хәзер дә, Аллага шөкер, кайнар ризыкка кайтып керәбез, – ди Гөлүсә Вафина.



рыбыз да бергәләп эшләдек. Ничек инде үзең яңа йортка күченеп, эти белән әнине искесендә калдырасың? Олы улларыбыз игезәк булып туды. Әни аларны бик караşты, балаларны үзем юындырмадым да. Кечкенәсен дә карап үстерде. Без эшкә чыгып китәбез, эти белән әни өйдә күз-колак. Ашарга пешкән, маллар каралган. Әле хәзер дә, Аллага шөкер, кайнар ризыкка кайтып керәбез.

...Килен, кайнаналы йортка кергәч, бу икәүнең бер-берсенә булган мөнәсәбәтләрен күзәтәсең. Кайбер очракта йә килен, йә кайнана өстен булып күренә. Вафиннар гаиләсендә исә андый әйбер тоймадым: арада ниндидер җылылык, хөрмәт барлыгы сизелә. Алар бер-берсенә охшаш та: сабырлар, шуның белән бергә икесе дә ачык, гади. Бу йорттагы ирләр өчен сөендем: акыллы хатын-кыз белән яшәү рәхәт бит!

«ТАШ КАЗАН» – СЕРЛЕ УРЫН?

Кармышта берничә тапкыр «Таш казан» дигән сүзне ишеттем. Баксаң, авылдан өч-дүрт чакрым ераклыкта әнә шундый җир бар икән. Авыл җирлеге башлыгы Рамилә Гатина безне шунда алып китте. Машина белән туры юл юк, шуның өчен Яшәүче авылы аркылы киттек. Яшәүче – Кармыш авыл җирлегенә кергән утыз хуҗалыклы авыл. «Таш казан» менә шушы ике авыл арасында икән.

Авыл җирлеге башлыгы башта Яшәүченең аксакалы, авылның мулласы Фаил абый Мортазин янына алып керде. Ник дигәндә, Фаил абый биредә туып үскән кеше. Дөрес, аннан соң Әлмәттә яшәгән, нефть өлкәсендә эшләгән. Ә лаеклы ялга чыккач, җәмәгате Фәридә апа белән Яшәүчегә күченеп кайтканнар. Бик актив кеше ул, туган авылы өчен янып тора.

– Без балачакта «Таш казан»га гел бара идек, – диде Фаил абый. – Ул ташларның астында су иде бит. Без, бала-чагалар, суга басарга курка идек. Янәсе, ул җенле урын, суында да берәр тылсым бар кебек тоела иде.

Шулай да Фаил абый берсендә шул суга аягын тыгып карарга батырчылык итә. Башта бер аягын төшерә, аннары икенчесен... Малайлар бу хәлне тын да алмыйча күзәтә.

– Бик шук идем, – дип дәвам итте Фаил абый. – Әнә шуңа да яшьтәшләремне үртәргә булдым: аякны суга төшергәч, кычкыра башладым. Барысының да коты очты.

– Суы салкын идеме шулай? – дим.

– Юк инде, болай, мәзәк ясап. Гадәти су иде ул. Шуннан соң курыкмыйча башкалар да аякларын суга тыгып карады.

«Таш казан» дигән урын Яшәүче авылына да бик якын түгел, ике чакрымнар тирәсе. Ике тау арасына урнашкан зур, үзенчәлекле бу ташларны күреп хәйран калдык. Ни кызганыч, биш ел элек биредә су кипкән. Җирле халык аның сәбәбен аңлата алмады. Ләкин ул алар өчен барыбер ниндидер бер изге, тарихи урын булып кала бирә.

– 1930 нчы елларда монда кешеләр яшәгән, – диде Фаил абый. – Совет власте муллаларга карата бик рәхимсез булган бит. Бер төркем дин әһелләре гаиләләре белән туган нигезләрен ташлап чыгып киткән. Үзара сөйләшептер инде, алар бирегә җыелган. Араларында күрше-тирә район муллары күп булган. Азрак хәл алгач, ир-атлар Себер якларына чыгып киткән. Ә балалары белән хатын-кызлар монда яшәп калган. Ир-атлар аларга бәләкәй генә өйләр салып калдырган. Ул өйләрнең нигезләре әле берничә ел элек кенә җиргә сеңеп бетте. Соңрак ир-атлар гаиләләрен кайтып алган. Менә бу ташлар шул чорларның шаһиты. Анда хәтта кайбер муллаларның исемнәре дә бар.

Чынлап та, казанны хәтерләткән әлеге дәү-дәү ташларда кеше исемнәре чокып язылган. 1930 ел дигән язу да бар. Бу җиргә туристлар да килә икән. Шуның өчен дә, авыл җирлеге тырышлыгы белән, тимер баскычлар да ясап куйганнар.

– Бәлки тора-бара бирегә тагын да күбрәк туристлар килер. Әлегә бу изге урын турында халык бик белми, – ди Кармыш авыл җирлеге башлыгы Рамилә Гатина.



4

– Без балачакта «Таш казан»га гел бара идек, – диде Фаил Мортазин.

5

Чынлап та, казанны хәтерләткән әлеге дәү-дәү ташларда кеше исемнәре чокып язылган. 1930 ел дигән язу да бар.

«ҖИРНЕ ЧИТ КЕШЕЛӘРГӘ БИРМӘДЕК»

Кармышта унбишләп гаилә фермерлык эше белән шөгыльләнә. КФХ ясаучылар, ШЯХ программасы белән эшләүчеләр дә бар. Авылның күп кешесе пай җирләрен аларга тапшырган. Шулай ук җирләрен үзләре эшкәртүче гаиләләр дә бар, андыйлар фермер булып теркәлмәгән.

Кармышның иң зур фермерларыннан берсе – Дамир Гатин. Егерме өч яшендә ул инде КФХ булып теркәлгән. Бүген утыз биш яшьлек фермерның 2 550 гектар җире, 117 баш мөгезле эре терлеге бар.

– Әтинең бертуган энесе фермерлык эшен алып бара иде, – диде Дамир. – Ул үзенә икенче эш башлады да җирләрне миңа тапшырды. Әнә шул 300 гектар җир белән эшне башладым. Аннары инде җирләр ел саен акрынлап арта торды.

– Дәүләттән берәр ярдәм алдыгызмы? – дим.

– Алгаладык. Склад, ферма биналарын грант акчасына төзекләндердек. Колхозның иске биналарын сатып алган идек. Тагын 2018 елда федераль грант кысаларында үгезләр сатып алдым.

Тәҗрибәле фермер җир эшенә күбрәк өстенлек бирә, әлбәттә. Моның өчен аның бөтен техникасы бар. Ә үгезләр үстерү вак-төяк чыгымнарны капларга китә. Иген уңышын елга бер генә аласың бит, ә маллар ел әйләнәсе акча кертә.

Иген дигәннән, бирелә шул ук хәл: узган елгы уңыш быелга кадәр амбарларда сакланган. Язын арышны килосын алты сумнан сатканнар. Дөрес, сатылган һәр килограмм ашлык өчен дәүләт ике сум акчалата субсидия кайтарган.

– Быел яхшы уңышка өмет бармы? Чирмешән районында корылык икән, – дим Дамирга.

– Өмет һаман бар инде ул. Шөкер, башка авыллар белән чагыштырганда, безнең авылда яңгырлар яугалады әле. Яхшы күңелле кешеләр яши бездә, изгелекләр дә еш эшлибез. Яңгырлар әнә шуның әҗередер.

Чынлап та, Кармышта бик ярдәмчел кешеләр яши. (Без моңа инде авылга кергәндә үк инандык). Фермерлар үзара да тату эшли: сезон вакытында бер-берсенә нык булышалар. Трактор, комбайн кирәксә дә, кемнеке буш, шуныкын алалар.

Авылда тату, ярдәмчел халык яши икәнлегенә тагын бер мисал: Кармышның ике егете бүген махсус хәрби операциядә катнаша икән. Егетләр ярдәм сорагач, авыл кешеләре дүрт көн эчендә 1 миллион сум акча җыйган. Һәм шул акчага бөтен кирәкле әйберләрне сатып алып, Донецк өлкәсенә илтеп кайтканнар.

– Авылыбызның егетләре зур йөк машиналарында еракка йөри, – дип сөйләде Дамир Гатин. – Шуларның берсе белән Украинага кадәр бардык. Хезмәттә булган егетләребез белән очрашып, кирәк-яракларны кулларына тапшырдык. Күптән түгел генә ул егетләр кайтып китте. Бөтен авылыбыз белән аларны каршы алып бәйрәм ясадык. Көн саен кунак булып йорттан-йортка йөрделәр. Аннан тагын авыл белән озатып калдык. Исән-имин йөреп кайтсыннар, алар өчен гел догада без...

Кармышны Чувашия, Мордовиянең данлыклы татар авылларына охшаттык: заманча яңа йортлар, урам тулы бала-чага, пөхтә генә сакал калдырган ир-атлар... Бүген татар авыллары ничек яшәргә тиеш дип сорасалар, Кармыштагы кебек дияр идем. Тырышлык, туган авылыңны ярату, иманлы булу, заманга яраклашу – кармышлыларның уңыш сере шунда кебек тоелды.

6 Кармышның иң зур фермерларыннан берсе – Дамир Гатин.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Бабайлар сөйләве буенча, авылыбызның тарихы XVII гасырларга барып тоташа. Чукындыру сәясәте башлангач, үз диненә хыянәт итәргә теләмичә, Чебоксардан Кармыш атлы кеше килә. Бу якларда чуваш авыллары була. Аны кызганып, ялгыз бер чуваш әбисе үз йортына кертә. Тора-бара Кармыш бабай тирә-якны өйрәнә. Ул чакта бирелә куе урман үсә. Соңрак Кармыш бабабыз гаилә кора һәм әлеге урынга килеп төпләнә. Авыл шулай үсеп киткән дигән фараз бар.

(Шәриза Вафин, авылның аксакалы)

ҖИР ЧИТЕНӘ СӘЯХӘТ (6+)

«Александр Македонский. Көнчыгышка юл» күргәзмәсендә сез бөек цивилизацияләр тарихы белән таныша алачаксыз. Дәүләт Эрмитажы тупланмасыннан экспозиция инде Санкт-Петербург, Амстердам һәм Сидней тамашачыларын таң калдырган – сез дә кушылыгыз! Барлык теләүчеләр өчен җыелма экскурсияләр һәр чәршәмбе (14.00 сәгатьтә), җомга (18.00), шимбә һәм якшәмбе (16.00) үткәрелә. Рус һәм татар телләрендәге аудиогид белән күргәзмәне көн саен карап була. Сүз уңаеннан, ул бөек патша һәм полководецның Көнчыгыш походы эзләреннән шәхсән үзе сәяхәт кылган күргәзмә кураторы тарафыннан әзерләнгән. «Македонский эзләреннән, яки Җир читенә сәяхәт» махсус интерактив программасы балаларны пәнҗешәмбе (14.00) көнне көтә – легендар полководец белән сәяхәт алар өчен мавыктыргыч маҗарага әйләнәчәк. Шулай ук «Александр Македонский» күргәзмәсе буенча бөтен гаилә белән сәяхәт итү дә мөмкин – һәр шимбә һәм якшәмбе (14.00). Барлык бу программаларга алдан язылып куярга кирәк! Телефоннар: 8 (843) 567-80-32, 8 (843) 567-80-34

18.30-23.00, «Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 нче кат, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

ҮЗГӘРЕШЛӘР ЗИЛЗИЛӘСЕНДӘ (12+)

Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» пьесасы 1910-1925 елларда Россия җәмгыятендә тектоник үзгәрешләр чорында татар буржуазиясе һәм интеллигенциясе тормышын яктырта, шул ук вакытта революцион чорның тарихи гаделсезлеге темасын күтәрә. 1926 елда сатирик комедия жанрында язылган әлеге пьеса бүген драматик характер ала, милли үзенчәлек һәм татар милләтенең үсеш юлын сайлау проблемаларына кагыла.

«Җилкәнсезләр» интерактив спектакле тамашачыларны артистлар белән бергә, чын мәгънәсендә үзгәрешләр божрасында бөтереп, революцион үзгәртеп корулар чорында алып китәчәк.

27 июнь, 13:00, 18:30

К.Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры

Казан, Горький ур., 13

Фотолар «Эрмитаж-Казан» үзәгеннән, tatar-congress.org, tatar-inform.ru



«НӘҮРҮЗ»: КАВКАЗ МОТИВЛАРЫ (12+)

XVI Халыкара «Нәүрүз» театр фестивале вакытында татарстанлылар Төркия, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстаннан һәм Россиянең 11 төбәгеннән 29 спектакль карый алачак. Быел фестиваль Төньяк Кавказ халыкларының театр сәнгате химаясендә үтәчәк. «Нәүрүз»нең махсус кунаклары – башкаланың «Школа драматического искусства» һәм Et cetera театрлары тамашачыны фестивальнең ачылу һәм ябылу көннәрендә сөендерәчәк. 5 июньдә ШДИ – «Вишнёвый сад» спектаклен, ә Et cetera театры 11 июньдә күренекле актерлар Александр Калягин һәм Владимир Симонов башкаруында «Лица» спектаклен күрсәтәчәк.

«Нәүрүз» фестивале спектакльләре барачак сәхнәләр:
Г.Камал исем. театр, К.Тинчурин исем. театр,
Г.Кариев исем. театр,
«Әкият» курчак театры,
Казан Яшь тамашачы театры,
«Моң» театры.
Спектакльләр ачык һавада да уйналачак

БӨЕК ДАЛА АЛТЫНЫ (6+)

7 июньдә Казан Кремленең Кабул итү урыннарында Көнчыгыш Казахстан тарих-төбәкне өйрәнү музее коллекциясеннән «Бөек дала алтыны» күргәзмәсе ачылачак.

Көнчыгыш Казахстан тарих-төбәкне өйрәнү музее коллекциясеннән «Бөек дала алтыны» күргәзмәсендә беренче тапкыр алтыннан ясалган тиңдәшсез бизәнү әйберләрен, борынгы сугышчыларның коралларын, курганнарны казыганда табылган кием элементларын күрергә мөмкин булачак. Экспозициядә бронза гасырыннан алып, иртә Урта гасырларга кадәр төрле чорларга караган 15 меңгә якын экспонат бар. «Археология тикшеренүләре күчмәннәр мәдәнияте комплексы барлыкка килү һәм формалашу, төрле этапларда күчмәнлек эрасы хакында белемнәрне системалаштыру һәм пропагандалау, әлеге эпохаль процесста Казахстан территориясендәге халыкларның роле турында иң мөһим мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле материал бирә», – ди тарих фәннәре докторы, профессор Зәйнолла Самашев.

7 июньнән 6 июльгә кадәр, 10.00-18.00, җомга – 11.00-20.00.
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы, Кабул итү урыннарының Күргәзмәләр залы

БАШТА – «АРАФ» (12+)

Төрек рәссамы Рәшит Алтун картиналары АКШ, Франция, Польша, башка илләрдәге күргәзмәләрдә уңыш казанган инде. Хәзер аның иҗаты белән Казанда да танышып була. Рәссамның картиналар сериясе «Араф» дип атала, бу тамашачыга ирексездән Библия мотивларын искә төшерә һәм хәзерге заман турында җитди уйланырга мәҗбүр итә. Нәкъ менә шул серия «Башта» күргәзмәсенең нигезен тәшкил итә дә инде. Картиналар югарыдан, болытлардан өстәнрәк торып язылгандай тоела, шуңа тамашачы рәссамның бу вакытта кайда булуы хакында уйлап куя. «Араф»та тылсымлы сынлы сәнгать галәме күрсәтелә. Серия картиналарында шулай ук киңлекнең (фәзаның) ниндидер бер субстанциягә әверелүен күрергә була: рәссам әйтерсең лә әлеге мизгелне туктаткан һәм киндергә төшергән кебек тоела.

7 июньнән 23 июльгә кадәр
ТР ДССМ Заманча сәнгать галереясы
Казан, Карл Маркс урамы, 57

РОМАНТИК УЕННЫҢ ИҢ ЮГАРЫ ҮРНӘГЕ

Быелгы тылсымлы май безгә купшы чәчәкләр генә түгел, ә шахмат буенча иң романтик партияне дә бүләк итте.

Зур бәйрәм Казан Кремле янындагы Меңьеллык мәйданында башланды. Шахмат фигуралары ролендә – Наполеон сугышлары чорындагы мундирлар кигән Россия хәрби-тарихи клублары әгъзалары уйнады. Бер сүз белән әйткәндә, мәйдан тулы гусар иде!

Турнирда шулай ук лафетларга урнаштырылган дүрт туп һәм атлар катнашты.

Тамашачылар өчен 1851 елда Лондонда Адольф Андерсен һәм Лионель Кизерицкий арасында уйналган «Үлемсез» партия күрсәтелде. Бу уен шунысы белән аерылып тора: җиңүгә ирешү өчен аклар җитди югалтулар кичерергә мәҗбүр була. Партия романтик шахмат уенының иң югары үрнәге дип танылa. Романтик мәктәп тарафдарлары карарны тиз кабул итте, уйлап та тормыйча, кискен һөҗүмнәргә күчте, курыкмыйча фигуралар белән хушлашты һәм җиңүгә ирешә.

Үлемсез партияне шахматчылар – халыкара спорт мастеры Илдар Низамов һәм спорт мастерлыгына кандидат Айнур Сабирҗанов кабатлады.

Романтик шахмат уеныннан һәм гусарлар белән аралашудан тыш, бәйрәм кунаклары рус партизан-шагыйре Денис Васильевич Давыдов шигырьләренә язылган романслар тыңлады һәм XIX гасырда популяр бал биюе тарихы белән таныша алды. Алар шунда ук бию адымнарын өйрәнде, теләге булганнар полонез биюен биеде.

Казанлылар һәм башкала кунаклары өчен мондый кызыклы бәйрәмне «Бородинское поле» Музей-тыюлыгы һәм ТР Милли музее оештырды.

Фото: Александр Ефремов

2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

Я люблю тебя,
Татарстан!

(русча)

Мый тыйым йӧратем,
Татарстан!

(марича)

Юрататӑп эпӗ сана,
Тутарстан!

(чувашча)

Мон яратӥсько тонэ,
Татарстаныськ!

(удмуртча)

Мин яратам сине,
Татарстан!